Мәдәни җомга

www.madanizhomga.ru

1995 елның июленнән башлап чыга

Татарстанда язылу индексы – П2355.

№ 21 (1437) 2 июнь 2023 ел

БЕЗ СОЦИАЛЬ ЧЕЛТӘРЛӘРДӘ:

madani_zhomga madanizhomga

madani_zhomga

12

Башкортстанның Кырмыскалы районындагы үзбәкләр нигез салган авылларга XVIII гасырда күпләп-күпләп актанышлылар күченә.



14

Балык Бистәсе, Мамадыш төбәген һәм күрше республикадагы Күгәрчен районын нәрсә берләштерә?

24

Мөслимнең оста кулы Нурия Бәхтегәрәева, Казанга махсус йөреп, каюлы кун сәнгате серләрен өйрәнә.

Җәйгә килеп кергән мәлләребез, Җиләс җилләр белән узышып!

БЕР ҖӨМЛӘ БЕЛӘН...

- Санкт-Петербургта татар аш-су остасы Юныс Әхмәтҗановка багышланган татар милли ашлары фестивале узды.

- Укытучылар һәм остазлар елында Татарстанда Мәгариф һәм фән министрлыгы «Татарстан мәгариф һәм фән өлкәсе отличнигы» билгесе, «Телләрне, мәдәниятләрне, традицияләрне саклау һәм үстерү өчен» күкрәк билгесе, «Яшь мөгаллим» күкрәк билгесе белән бүләкләүне гамәлгә куйды.

- Россия Хөкүмәте һәм «Россия халыклары йорты» IT-компаниясе төрле халыкларның телләрен саклау эшенә ясалма интеллект җәлеп итәчәк.

- 2024 елда Бөтенроссия авыл Сабан туе Пермь крае Барда районында үтәчәк.

- Мансур Гыйләҗев пьесасына нигезләнеп, кинорежиссер Илшат Рәхимбай төшергән «Микулай» фильмы 22 июньнән киң прокатка чыга.

- Төркиянең Конья шәһәре Милли китапханәсендә татар шагыйре Ленар Шәехнең «Аклыкны сагындым» китабын тәкъдим итү кичәсе оештырылды.

- Ташкентның А.Навои исемендәге академия театрында Үзбәкстанның халык артисты, прима-балерина, милләттәшебез Галия Измайлованың 100 еллыгына багышланган искә алу кичәсе узды.

- «Казан утлары» журналының китап киштәсе сериясендә Зиннур Хөсниярның «Әтием кайда, Суслонгер?!» китабы дөнья күрде.

- Халыклар бердәмлеге көнендә Уфада милли республикалар Язучылар берлекләренең күчмә пленумы Башкортстанда узачак.

ӘЙТКӘН СҮЗ – АТКАН УК

Әлбир КРГАНОВ, Россия мөселманнары Дини җыены рәисе, Мәскәү шәһәре, Үзәк төбәк һәм Чуашия Республикасы мөфтие:

«Көнбатышның Россияне яратмавының сәбәбе билгеле. Россия үзенең тарихи гореф-гадәтләренә тугры кала бирә. Бүгенге көндә территория өчен түгел, ә рухи кыйммәтләр, динсезлеккә каршы көрәш бара. Көнбатыш илләре күптәннән Россия һәм ислам илләре арасында коткы салмакчы булып торды. Россия ислам дошманнарының йөз еллык планнарын бозды. Иран, Пакьстан, Төркиядә иҗтимагый тормышны какшату талпынышлары юктан гына барлыкка килде дип уйлыйбызмы? Бу – кешелек, аерым алганда, ислам дөньясы өчен зур сынау».

СЫНАМЫШЛАР

2 июньдә кыяр чәчәләр ● Чыршыда күркә күп булса, кыяр уңа ● 3 июньдә яңгыр яуса, көз яңгырлы килә ● 5 июнь – кыяр чәчә торган соңгы көн ● 7 июньдә күп чык төшсә, игеннәр уңа ● Җәй көне гел томан төшсә, гөмбә күп булыр.

КОЯШ СӘГАТЕ

Бүген кояш **3 сәгать 07 минутта** чыкты, һәм ул **20 сәгать 17 минутта** офык артына күмелачәк. Көн озынлыгы – **17 сәгать 10 минут.** Алдагы җиде көн дәвамында тәүлекнең якты вакыты **13 минутка озынаячак** һәм киләсе җомгада, ягъни **9 июньдә 17 сәгать 23 минут** тәшкил итәчәк.

БЕЛЕП ТОРЫГЫЗ

3 июнь – язучы-прозаик, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Флүс Фатих улы Латыйфиның (Латыйпов) тууына 80 ел (1943–2010).

5 июнь – журналист Наил Вазыйх улы Хисамиевнең (Алан) тууына 60 ел (1963-2018);

– филология фәннәре кандидаты, журналист, Башкортстанның атказанган матбугат һәм гаммәви мәгълүмат хезмәткәре Илдар Камил улы Фазлетдиновка 45 яшь (1978).

6 июнь – Рус теле көне.

8 июнь – Бөтендөнья океаннар көне.

СӘЛАМӘТЛЕК КӨН ДӘ КИРӘК

Июньнең магнитлы авыр көннәрендә хезмәттәшләрегез, якыннарыгыз сәламәтлегенә һәм, әлбәттә, үз-үзегезгә аеруча игътибарлы булыгыз. **Бу атнада андый магнитлы көн юк.**

* * *

Гадәттә, тулы айдан айның соңгы чирегенә кадәр **(4-10 июнь)** организм кысылуга бара. Мондый көннәрдә үз-үзеңә физик йөкләмә бирү файдалы.

ҺИҖРИ БУЕНЧА 1444 ЕЛ

Бүген зөлкагдә аеның 13 нче көне

ҖАН АВАЗЫ

Рүзәл ЮСУПОВ

МӘДӘНИЯТТӘГЕ СӘЕР ЯҢАЛЫКЛАР

Кешеләр һәм дәүләтләр бер-берсеннән үзләрендә булмаган яңалыкларны, файдалы ачышларны алмашып һәм үзләштереп, цивилизациягә ирешкән. Тормыш тәртибе хәзер дә шулай. Хезмәткәр остаз тәҗрибәсен камилләштерә, предприятиеләр күршедәге яңа технологияләрне үзләштереп алга бара.

Бер-береңнең казанышларын үзләштереп камилләшү рухи мәдәниятккә дә хас. Коллективларның мәдәнияттәге казанышларын алмашуы матди уртаклашуга караганда катлаулырак. Рухи хәзинәләрен алмашу һәм үзләштерү өлкәсендә бик сак булу, күрше мәдәниятләрнең милли үзенчәлекләрен исәпкә алып эш итү зарур.

Күрше халыкның рухи хәзинәсен дөрес бәяләү кабул итеп алган мәдәниятнең үз йөзен, милли үзенчәлекләрен саклау өчен әһәмиятле. Башка халык мәдәниятенең казанышларын үзләштерү белән чамасыз мавыгу мәдәниятнең миллилек табигатенә зур зыян китерергә мөмкин. Мондый куркынычның күп гасырлар буена руслар белән тыгыз бәйләнештә торган татар халкының мәдәниятен үсешенә дә янавы ихтимал.

Татар халкының матди һәм рухи мәдәниятләре күп вакытлар рус мәдәнияте йогынтысына дучар була. Бу аның промышленность һәм авыл хуҗалыгындагы җитештерүгә, шулай ук рухи тормышта – әдәбият, тел һәм сәнгать өлкәләрендә алга китүгә уңай тәэсир итә. Татарлар тарафыннан рус мәдәнияте казанышларын үзләштерелүе процессы хәзер дә актив гамәлгә ашырыла, чөнки татар һәм рус халыклары, бер дәүләттә үзара даими рәвештә хезмәттәшлек итеп, якыннан аралашып яши.

Хәлбуки соңгы елларда икенче халык мәдәнияте казанышларыннан файдалану мәсьәләсендәге төп принципны – бер мәдәният икенче мәдәниятнең үзендә булмаган хәзинәләрен генә алып үзләштерергә тиеш, дигән принципны бозу күренешләре хөкем сөрә. Икенче мәдәният казанышын кабул итүнең төп мәгънәсе, әһәмияте дә шунда: башка мәдәният хәзинәсе, кабул итеп алган мәдәниятнең эчтәлеген тулыландырып, баетып, аның табигатенә яраклашып үзләштерелерлек булырга тиеш. Бүтән мәдәният элементларын алу шул чакта гына кабул иткән мәдәниятне камилләштерүгә, аның алга баруына ярдәм итә. Татар әдәби теле формалашу чорында рус теленнән күп санда фәнни-техник, иҗтимагый-сәяси терминнар кабул итә, шулай ук рус теле чаралары үрнәгендә ясалган лексика-фразеология һәм сурәтләү элементлары фондын киңәйтә. Бу процесс элекке Советлар Союзы халыкларының әдәби телләре үсеше өчен табигый ихтыяҗ буларак гамәлгә ашырылган.

Ләкин хәзер татарларның рухи тормышында, төрле сәбәпләр аркасында, башка мәдәният элементларын кирәксез, мода өчен генә кабул итү белән мавыгу хөкем сөрә. Бу бүтән халыкларның архитектурасы үрнәкләренә охшатып эш итүдә, кайбер мәдәният әһелләренең театр спектакльләрен, музыка әсәрләрен яңа, модерн стилендә үзгәртергә, татар халык җырларын Европаныкына яки русныкына якынайтырга тырышуларында күренә.

Мондый омтылышлар шаяру гына түгел, алар торган саен ныграк тамыр җибәрә һәм татар мәдәнияте өчен куркыныч көчкә әверелә бара. Мәсәлән, Татарстан башкаласы Казанда, Мәскәү артистларын чакырып, аларның «Үзгәреш җиле» дигән яңгыравык исемдәге татар музыкасы концертларын куйдыру идеясе кемнең башына килгән һәм моны кемнәр оештырган икән? Үзебезнең менә дигән музыка коллективларыбыз һәм халык җырларын бик яхшы башкаручы артистларыбыз бар бит. Чакырып китерелгән музыкантлар безнекеләрдән өстенрәк булса бер хәл. Юк шул, киресенчә, гастрольгә килгәннәрнең күбесе яки татарча начар белә, яки бөтенләй белми. Шуның өстенә, чын татар көйләрен тупас бозалар, чөнки алар татар халкы моңы мохитендә тәрбияләнмәгән, аның серле, сагышлы, бәгырьгә үтеп керә торган аһәңен аңламыйлар.

Татар музыкасын аңлый торган тамашачылар фикеренчә, күпчелеге белән читтән китерелеп, кыйммәткә төшкән бу артистлар чыгышының гомумән алганда уңышсыз булуы аларның беренче турнесында ук күренде. Шулай икән, аларны тагын чакырырга кирәк идеме соң? Юк бит! Икенче тапкыр да, өченче тапкыр да киләләр... Андый бозык музыкалы чыгышларны кемнәр хуплап тора, акчаны кем түли?!

Үзебезнең, җирле артистларыбызның да, кемнәргәдер охшарга тырышыпмы, кайсыдыр халыкның җырлау стиленә яраклашырга теләпме, татар халык музыкасын бозып башкаручылары байтак. Безнеңчә, халык җырларын башкаруга карата катгый таләп булырга тиеш: халык музыкасын бозарга, шул исәптән, аны камилләштерү сылтавы белән, музыкаль эшкәртәбез дип үзгәртергә беркемнең дә хакы юк.

Халык музыкасын кадерләп саклау ихтыяҗы мәсьәләсендә бөек татар композиторы Салих Сәйдәшев иҗаты һәм мөнәсәбәте яхшы үрнәк. Ул халык көйләрен бик ярата, хәттә, үзенә куркыныч янаганда да, халык җырларын саклаудан һәм яклаудан баш тартмый, татар көйләренә зыян китереп, көнбатыш музыкасы белән мавыгуга каршы чыга, чын халык җырлары рухындагы үлемсез музыка әсәрләрен, бәһалап бетергесез кыйммәтле музыкаль җәүһәрләрен иҗат итә.

Җитди ихтыяҗы булмаган, төптән уйланылмаган экспериментлар театр сәнгатенә карата да үткәрелә. Соңгы вакытларда татар театры үзенә күрә бертөрле модерн яңартылыш халәтендә. Спектакльдә уйнаучыларның гадәти булмаган стильдәге әңгәмәләре, сәхнәдә чабышып йөрүләре, ниндидер шартлы алымнар кулануы (мәсәлән, «Мөһаҗирләр» спектаклендә чәй эчәргә һәркайсы үз самоварын күтәреп чыга) кебек сәер күренешләр белән мавыгу сизелә. Нигәдер спектакльләрдәге декорацияләр көннән-көн фәкыйрьләнә бара, кайберәүләр хәтта урындык-өстәлләр куюбелән генә чикләнә. Диалог һәм монологлардан, пластик хәрәкәтләр, акробатик трюклардан торган спектакльләр дә модага керә.

Театр спектакльләренең традицион нигезләре ни өчен шулкадәр үзгәртә икән? Болай чамасыз кискен үзгәртүләр сәнгатьнең төп максаты чынбарлыкны мөмкин булганча тулы чагылдыру дигән хакыйкатькә каршы килә түгелме соң? Бәлки, театр өлкәсендәге мондый яңалыклар турында болай катгый сөйләргә кирәк тә түгелдер, әмма соңгы вакытларда сәнгатьтәге кайбер үзгәрешләр безнең холык-фигыльгә һич тә туры килми. Шуңа күрә сәнгатьнең торышы өчен җаваплы кешеләрне, җиңелчә уйланылган экспериментлар ясап, мәдәни хәзинәләрнең эчтәлеген бозмагаек, дип кисәтмичә дә ярамый.

Яңалыклар кертү белән мавыгу хәлләре уңаеннан тагын бер җитди хәлне искә алу урынлы. Республика хакимияте, Г.Камал исемендәге Татар академия театрының яңа бинасының проектын әзерләү өчен, халыкара конкурс игълан итте. Анда Мәскәүнең дә, чит илләрнең дә проект оешмалары катнашты. Конкурс комиссиясе Япония архитекторларының проектына өстенлек бирде. Японнар, «Һәркем үзе белгәнчә эшли» дигән гыйбарәдәгечә, үзләренең көнчыгыш стиленә яраклаштырып, сырлы-сырлы түбәле, сәер конструкцияле бина проектын тәкъдим иткән. Комиссия әгъзаларының бу проектны нинди дәлилләргә таянып кабул итүе һич аңлашылмый. Әмма бу бик җаваплы карарны тикшерүдә белемле белгечләрнең җитәрлек булуына һәм комиссиянең төзелеш сәнгатендәге милли үзенчәлекләрне һәм театр архитектурасындагы традицияләрне тиешенчә исәпкә алганына шигебез бар. Безне бу булачак бина татар тамашачысына ошармы, Татарстан архитекторлары бу җаваплы эштән ни өчен читтә калган, бу чарада Казанның төзелеш-архитектура университетының роле нигә юк соң, дигән сораулар борчый.

ИМИНЛЕК ГАРАНТИЯСЕ

Иминлек төшенчәсе үз эченә күпне сыйдыра. Дәүләт иминлеге турында сүз барганда, бүгенге кырыс дөньяда үз киләчәген кайгырткан илләрнең мотлак күпчелеге төп игътибарны нәкъ менә аның гарантияле хәл ителүенә бирүе бер дә гаҗәп түгел. Чөнки аннан башка гына илнең ышанычлы киләчәге була алмый. Хәлбуки, төрле дәүләтләр аның чишелешен төрлечә күрә: кемдер үзенең икътисади һәм социаль нигезен ныгытып, гарантияне халыкара хокук нормалары кысаларында, әмма ләкин үз саклану системасын камилләштереп тә булдырырга омтылса, икенчеләре инде аңа ниндидер хәрби яки сәяси блокларга берләшеп тә ирешмәкче. Ә кемдер барлык янаулардан да гарантияне үзенең атом-төш коралына ия булуында гына да күрә. Ул гына түгел, андый коралга ия бәгъзеләр әле аны башкаларга үз ихтыярын куркытып тагу ниятендә, ниндидер шантаж коралы итеп тә кулланмакчы. Мәгәр, иминлек гарантиясен көчләргә аркаланып эзләүчеләр дә юк түгел. Кыскасы, һәркем ошбу мөһим проблеманы үзенчә һәм ышанычлы итеп хәл кылырга омтыла. Җөмләдән, узган ел 24 февральдә Мәскәү дә, Украинада махсус хәрби операцияне (МХО) башларга этәргән төп сәбәпне, НАТОның көнчыгышка киңәюе фонында, илнең иминлек гарантиясен булдыру максаты белән аңлатты.

Әлбәттә, бер илнең үз иминлек гарантиясен бу рәвешле кайгыртуы, иртәме-соңмы, аның белән тыгыз мөнәсәбәттә булган башкаларныкында да уңай яки тискәре чагылыш таба. Бу җәһәттән, МХО башланып 15 ай үтүгә, аңа мөнәсәбәтле илләрнең иминлек гарантияләре белән бәйле проблемалар кабат алгы планга чыкты. Ә инде аңа этәргечне Алмания канцлеры Олаф Шольцның, Украина тирәсендәге хәлләр буенча тынычсөйләшүләр үткәрү ул низагны «туңдырып» торуны максат итмәскә тиеш, дигән сүзләре бирде кебек. Фикер Көнбатышның күп кенә илләрендә яклау тапкан. Әйтик, Бөекбритания премьер-министры Риши Сунак бу җәһәттән 22 майда, Украинага аның югалткан территорияләрен кире кайтарып бирүне күздә тотмаган, димәк, низагның вакытлыча «туңдырылып» торуына гына китерәчәк теләсә нинди «тынычлык планнары» да тамырыннан дөрес түгел, дип искәрткән. Моның белән Киевтә дә тулысынча килешкәннәр. Ә Украинадагы конфликтны «туңдырып» торуга хәтта Мәскәү дә каршы. Россия Президентының матбугат сәркатибе Дмитрий Песков узган атнада бу турыда: «Россия рассматривает возможность только завершения специальной военной операции: обеспечения своих интересов, достижения стоящих перед Россией целей или посредством специальной военной операции, или иными доступными средствами», – дип белдерде.

Инде Украина тирәсендәге вакыйгаларда сәяси активлык күрсәткән кайбер урта кул илләрнең иминлек гарантиясен ничек аңлауларына да тукталып үтик. Әйтик, Польша лидеры Анджей Дуда Wall Street Journal газетасына биргән интервьюсында, Украина-НАТО шурасы төзелүгә бүгенге әзерлекне күздә тотып, Россия Украинаның куллану срогы билгеләнмәгән (ягъни озак вакытлы) иминлек гарантиясенә ия булуын танырга тиеш, дип белдергән. Ә ул Шураның төзелүе турында альянсның 11-12 июльдә Вильнюста узачак саммитында игълан ителәчәк икән. Аның нигезенә иминлек өлкәсендә АКШ-Израиль үрнәгендә хезмәттәшлек салыныр, дип көтелә. Ә ул Украинага, НАТО әгъзасы булмаган көенчә дә (чөнки анда хәрби низаг бара), аның озак вакытлы вә тулы ярдәменә исәп тоту һәм үз иминлеген дә тәэмин итү мөмкинлеге бирә. Чөнки Киев Шура утырышын җыю хокукына ия булачак. Шул ук вакытта Украина-НАТО шурасы төзелү Киев өчен оешмага әгъза булып керүнең алшарты булып та тора. Игътибарны исә Европа Берлегендә (ЕС) Мәскәү рупоры ролен башкара торган ил – Венгрия дә җәлеп итә. Аның лидеры Виктор Орбан күптән түгел Европага хәтта Россия белән иминлек турында килешү төзү тәкъдиме белән дә чыкты. Әлбәттә, андый тәкъдимнең каян килүен чамалау кыен түгел. Шуңа да карамастан Мәскәү әле кыстаткан кебек тә итә: имеш, ул моңа МХО максатлары үтәлгәннән соң гына әзер булачак.

Хәлбуки, иминлек гарантиясенең глобаль үлчәмнәре дә бар. Моңарчы алар, халыкара хокук нормалары кысаларында, БМО механизмнары аша хәл ителеп килде. Әмма соңгылары бүген тиешенчә эшләми. Күптән түгел БМО Куркынычсызлык Шурасын һәм Бреттон-Вуд системасын (өченче дөньякүләм валюта системасы 1944 елда Бреттон-Вуд килешүе белән кертелә) реформаларга БМО җитәкчесе Антониу Гутерриш үзе чакырды. Әмма анда хокук көче түгел, ә көч хокукы өстенлек итә. Шуңа андый реформалар вакытлы чара гына була ала. Ә глобаль иминлекнең универсаль вә гарантияле чишелеше дә бар: ул – абсолют кыйммәтләр системасына күчеп, дөньякүләм дәрәҗәдә илаһият кануннары буенча яши башлау. Димәк, БМО системасының да ошбу иң югары максатларга туры китереп реформалануы лязем.

Фоат УРАЗАЙ.

Тубылда «Зәнкиев укулары»

Укытучы һәм остаз елына багышланган «Зәнкиев укулары» VII нче халыкара фәнни-практик конференциясе Тубыл шәһәренең «Синтез» сәнгать һәм мәдәният үзәгенең кече залында Тубыл шәһәренең педагогия институты оештыруында, милләтләр эшләре буенча өлкә комитеты, өлкә татар милли-мәдәни автономиясе, Тубыл шәһәре хакимияте, Тубыл шәһәре иҗтимагый Палатасы ярдәме белән узды.

Чараны «Себер гимны» белән танылган җырчы Зәкинә Арангулова ачты. Аннары кунакларны филология фәннәре докторы, профессор Гүзәл Фәйзуллина сәламләде. Милләтләр эшләре буенча өлкә комитетының баш белгече Эльмира Алиева җитәкчесе Роман Малыгинның Котлау хатын укыды. Тубыл пединститутының директор вазыйфасын башкаручы Петр Шитиков, шәһәр иҗтимагый палатасы рәисе Василий Кожедуб, өлкә татар милли-мәдәни автономиясе рәисе Ләйсән Хөрмәтуллина, Тубыл шәһәр Думасы депутаты, шәһәр автономиясе рәисе Сәет Хисмәтуллин язучыны җылы сүзләр белән искә алдылар.

Пленар утырышта филология фәннәре докторы, профессор, Казан федераль универстетының татар әдәбияты кафедрасы мөдире Флера Сәйфуллина «Якуб Зәнкиевнең иҗади эшчәнлеге XX гасырның икенче яртысындагы татар әдәбияты контекстында» дигән тема буенча чыгыш ясады.

Филология фәннәре докторы, Г.Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм сәнгать институты директорының фәнни эшләр буенча урынбасары Олег Хисамов Идел-Урал татарларының һәм Себер татарларының тел һәм этник берләшмәсе турында диалектлардан мисаллар китереп чыгыш ясады. Педагогика фәннәре кандидаты, доцент Кадрия Фәтхуллинаның «Яңартылган ФГОС шартларында туган тел укытучысының эшчәнлеге» темасына чыгышын конференциядә катнашучылар зур игътибар белән тыңлады.

Фәнни-практик конференция эше пединститутта узган тематик секцияләрдә дәвам итте. Монда башлангыч сыйныф укучылары өчен «Татар балалар әдәбияты (XX гасыр ахыры-XXI гасыр башы)» яңа чыккан хрестоматия китабының презентациясе узды.

Конференция кысаларында кунаклар өлкә халык мәгариф музеенда, шәһәрнең 15 нче мәктәбендә, милли музеенда булды. Шәһәрнең себер-татар мәдәният үзәгендә оештырылган музыкаль–әдәби кунак бүлмәсендә Я.Зәнкиевнең улы Нур, аның тормыш иптәше Сәкинә, оныгы Диләрә, туганнары, дуслары, хезмәттәшләре якты хатирәләре белән уртаклаштылар.

Римма ӨМЕТБАЕВА.

Французлар татар китаплары белән кызыксына

Парижның Көнчыгыш телләре һәм мәдәниятләре милли институтында (INALCO) татар язучыларының китаплары тәкъдим ителгән.

«ANTHOLOGIE DE LA PROSE TATARE CONTEMPORAINE» («Хәзерге татар прозасы антологиясе»; төзүчесе – Ленар Шәех) һәм Ленар Шәехнең «MON COEUR BRÛLE COMME UN FEU» («Йөрәккәем янганга») китаплары 2021 елда, ә Роза Туфитуллованың «GOULSOUM» («Гөлсем») романы 2023 елда L'Harmattan нәшриятында французча 1500әр данә булып дөнья күргән иде.

«Франциядә татар әдәбиятына кызыксыну бар, әмма алар өчен әлегә без ерак планета кебек. Татарлар турында гомуми күзаллау булса да, тарих һәм әдәбият аша танышу бик аз дәрәҗәдә. Безнең хакта күзаллауны тудыручы милләттәшебез ул – Рудольф Нуриев. Тагын халкыбыз турында белгертүнең иң үтемле мәдәни юлы – әдәбият. Укучыга бүгенге авторлар кызык, шуңа күрә әлеге проектларны башкарып чыктык», – диде Парижда зур тантанада катнашкан Ленар Шәех.

Чарада L'Harmattan нәшриятының «Рус горизонтлары» сериясе директоры Филипп Юркович, өч китапның тәрҗемәчесе Кристоф Тронтен, Сорбонна университеты профессоры Сәлим Йылмаз, Төркиянең Сәлҗук университеты мөгаллиме Алсу Шәмсутова, Россиянең Франциядәге илчелегенең фән, югары белем, инновацияләр һәм яңа технологияләр буенча киңәшчесе Игорь Носков, Парижда белем алуларын дәвам итүче милләттәшләребез Илшат Сәетов һәм Гүзәл Сабирова һ.б. катнашкан.

Тантананы әдәбият галиме, язучы, Көнчыгыш телләре һәм мәдәниятләре милли институтында төрек теле һәм әдәбияты буенча доцент, «Хәзерге татар прозасы антологиясе» һәм Роза Туфитуллованың «Гөлсем» китабына кереш сүз язган Тимур Мухидин алып барган. Ленар Шәех татар әдәбиятының үткәне һәм бүгенгесе турында сөйләп, татар мәдәнияте белән таныштырган.

«Парижга сәфәр искиткеч матур тәэсирләр калдырды. Өч сәгатьтән артык татар әдәбияты турында барган сөйләшү французларның кызыксындырган сораулары күплеген күрсәтте», – диде Л. Шәех.

Алсу Шәмсутова француз язучыларының әсәрләрен дә татар теленә тәрҗемә итү кирәклеген, бу гамәлнең ике милләт арасындагы әдәби-мәдәни багланышларны тагын да үстерәчәген әйтте.

Аның тәкъдиме белән 1901–1906 елларда Парижның Сорбонна университетында белем алган, 1920 елларда биредә төрки халыклар тарихы буенча лекцияләр укыган, 1924 елдан Мостафа Кәмал Ататөреккә ярдәмгә чакырылган танылган татар җәмәгать эшлеклесе Садри Максуди искә алынган.

Сорбонна университетында лингвистлар Клод Ажеж һәм Роберт Мартиннан белем алган профессор Сәлим Йылмаз уку йортында кунакларга экскурсия үткәргән һәм лекция укыган.

Зилә МӨБӘРӘКШИНА

1 нче биттә – спортсөяр балаларның җәйге ял мизгеле. Фото: pxhere.com

Госман Коръәне кайтты

Уфада узган «Китап-бәйрәм» халыкара китап ярминкәсенең тантаналы ачылышын Башкортстан Республикасы башлыгы Радий Хәбиров яңалык җиткерүдән башлады – Ташкентта Хәзрәт Имам комплексында саклана торган, иң борынгы Коръән китапларының берсе булып саналган Госман Коръәненең бердәнбер кулъязма копиясе Уфага кайткан.

Шуннан соң мәйданга тантаналы төстә изге китапны керттеләр.

«Бу вакыйга – күпмедер дәрәҗәдә изге китапның өенә кайтуы!» – дип шәрехләде бу тантананы алып баручы танылган журналист Дмитрий Дибров.

Р.Хәбиров Госман Коръәненең ни өчен Башкортстанда булырга тиешлеген аңлатты. «20 гасыр башыннан 1923 елга кадәр Госманлы Коръәне бездә сакланган, соңыннан Үзбәкстанга тапшырылган. Ниһаять, Үзбәкстанның булышлыгы белән, алтын хәрефләр белән язылган бердәнбер копия яңадан безгә кайтты», – диде ул.

Госман Коръәненең күчермәсе Башкорстанның милли музеена тапшырылды. Бераздан ул күчмә халыкларның Евразия музеена күчереләчәк.

Алсу ИСМӘГЫЙЛЕВА.
Автор фотосы.

Болгар чоры ядкәре

Болгар ислам академиясе һәм Татарстанның Фәннәр академиясе Сөләйман бине Дауд әс-Саксининың «Бакчаларның гүзәллеге һәм сырхау күңелләрнең юанычы» китабын бастырып чыгарды.

Әлеге китап Идел Болгары чорыннан табылган әсәрләр арасында иң кыйммәтлесе һәм борынгысы санала. Шиһабетдин Мәрҗани үз вакытында бу китапны Истанбулдагы китапханәгә бүләк итеп тапшырган. Берничә ел элек татар галимнәре аны табып алып кайткан иде.

«Бакчаларның гүзәллеге һәм сырхау күңелләрнең юанычы» китабы гарәп теленнән тәрҗемә ителде. Беренче томда кулъязманың фотолары урын алган һәм әсәр чыганак телендә – гарәпчә бастырылган. Икенче томда исә русчага, өченче томда татарчага тәрҗемә ясалган.

Сөләйман бине Дауд (әс-Сувари) әс-Саксини – XII гасырда яшәп иҗат иткән галим. Аның хезмәтләре урта гасыр дин белгечләре арасында данлыклы әсәрләрдән саналган. Сувари һәм Саксини тәхәллүсләренә караганда, ул Болгар шәһәрләрендә яшәгән.

Китапны «Россия мөселманнарының илаһият мирасы» V Халыкара Болгар форумында тәкъдим иттеләр. Җыентыклар форумда катнашучы галимнәргә таратылды. Дөньяның иң күренекле дин белгечләре һәм профессорлары китапны югары бәяләде.

Ләйсән ФӘТХИ.

Хезмәте белән хөрмәт казанды ул

КФУның Г.Тукай исемендәге Милли мәдәният һәм мәгариф югары мәктәбендә галимә, филология фәннәре докторы, профессор Флёра Сафиуллинаның тууына 85 ел тулуга багышланган кичә булды. Анда галимәнең хезмәттәшләре, шәкертләре, фикердәшләре, студентлар катнашты.

Кичәне гомуми тел белеме һәм тюркология кафедрасы профессоры Әлфия Йосыпова алып барды. «Яраткан остазыбыз арабыздан бик иртә китеп барды. Ләкин без аны онытмыйбыз, һәрвакыт искә алабыз, сагынабыз. Флёра Садриевна татар галимнәренең беренчеләрдән булып чит ил галимнәре, тюркологлар белән элемтә урнаштырды. Шуларның берсе – Эге университеты профессоры Мостафа Өнәр», – дип искә алды галимә.

«Флёра Садриевнаның тормыш юлы барыбыз өчен дә үрнәк. Барлык гомерен ул яшьләр белән эшләүгә багышлады. Аның 500 ләп хезмәте, 10 нан артык фән кандидатлары, докторлары бар. Флёра апаның хезмәтләре – зур-зур монографияләр, сүзлекләр, үзөйрәткечләр h.б. Ул бик күп вакытын эшкә, фәнгә багышлады. Аерым фәнни институт кадәр эш башкарды, безгә зур мирас калдырды», – диде КФУның Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты директоры Рәдиф Җамалетдинов.

КФУ доценты Кадрия Фәтхуллова әйтүенчә, Флёра Сафиуллинаның эше дәвам итә, буыннан-буынга тапшырыла. «1990 елларда рус телле балаларга татар теле укытыла башлагач, Флёра Сафиуллина махсус программалар төзүдә җитәкчелек итте. Укытучыларның белемен күтәрү курсларында даими рәвештә лекцияләр укыды, тәҗрибәсе белән уртаклашты. Төрле илләрдән килгән студентларны татарча сөйләшергә өйрәтте», – диде ул.

Гомуми тел белеме һәм тюркология кафедрасы доцентлары Фирүзә Сибгаева, Гүзәл Нәбиуллина, Раушания Нурмөхәммәтова галимәнең югары уку йортлары студентлары өчен күпсанлы дәреслекләр авторы булуын билгеләп узды: «Мәктәп һәм укытучылар белән тыгыз бәйләнештә яшәде. Шуңа күрә татар һәм рус телле балалар өчен дәреслекләр, методик әсбаплар төзүдә катнашты, актив эшчәнлек алып барды».

Татарстанның Мәгариф һәм фән министрлыгының милли бүлек мөдире Энже Гыйззәтуллина дәүләт теле буларак татар телен мәктәпләрдә барлык укучыларга укыту өлкәсендәге эшчәнлеге турында сөйләде. «Флёра Сафиуллина барлык укучыларга татар телен өйрәтүнең нигезләрен салучылар рәтендә торды. Бүгенге көндә дә татар теле укытучылары сөйләмендә «Сафиуллина дәреслекләре» дигән сүз һаман да бар», – диде ул.

«1990 елларда татар телен балаларны төркемнәргә бүлеп укыттылар. Мәктәпләргә татар теле укытучылары җитмәде. Татар телен бераз белгән башка фән укытучылары да татар теле укыта башлады. Ә аларның үзләренә татар телен өйрәнү өчен дәреслек кирәк булды. Шуңа күрә Флёра Садриевна белән бергә авторлыкта эшләгән галимнәргә рәхмәт. Бик күп сүзлекләр, методик әсбаплар, тел белемен гади итеп аңлата торган китаплар чыгардылар», – диде Энже Гыйззәтуллина.

«Ак калфак» Бөтендөнья татар хатын-кызлары иҗтимагый оешмасы рәисе Кадрия Идрисова үзен Флёра Сафиуллинаның дөньяви шәкерте дип атады. «Ике авылда без аның белән фольклор экспедициядә булдык. Өч көндә ул миңа кеше булып калырга өйрәтте», – диде ул.

Зилә МӨБӘРӘКШИНА.

Касыймлыларның данлыклы якташы

Рязань өлкәсенең Касыйм шәһәрендә А.М.Ишемабаев исемендәге V төбәкара ачык этнография һәм туган якны өйрәнү укулары узды. Совет дәүләт эшлеклесе, шушы якта туып-үскән Фикрәт Табиевнең юбилеена багышланган чара Үзәк китапханәдә булды. Оештыручылар – Касыйм шәһәренең татар милли-мәдәни автономиясе, Рязань педагогия колледжы филиалы, Л.А.Малюгин исемендәге үзәк китапханә. Катнашучылар арасында төбәк һәм муниципаль башкарма хакимият, фәнни берләшмә һәм иҗтимагый оешма вәкилләре, язучылар, журналистлар бар иде.

Танылган дипломат, 1979-1986 елларда СССРның Әфганстандагы гадәттән тыш һәм тулы вәкаләтле илчесе Фикрәт Табиев Рязань өлкәсенең Ермишинский районындагы Әҗе (Азеево) авылында туган. Табиев турында «Вести ФМ» радиостанциясе алып баручысы, педагогика фәннәре кандидаты Марат Сәфәров «Кабулдагы миссия. Фикрәт Табиевнең 1979-1986 елларда Әфганстанда дипломати эшчәнлек турында истәлекләре» темасына чыгыш ясады.

Җыен ачылышында Касыйм шәһәр округы башлыгы Иван Бахилов калада ике мәдәният, ике дин җәмгыяте оешу турында сөйләде. «Без биш йөз ел дәвамында милләтара, конфессияара конфликтларсыз яшибез... Әлеге укулар – бу процессны һәм хезмәттәшлеге безне үстерергә өстәмә стимул», – дип белдерде ул.

РФ мөселманнары Диния нәзарәте рәисе мөфти шәех Равил Гайнетдиннең сәламләү сүзләрен нәзарәтнең Эчке эшләр департаменты җитәкчесе Наил Шакиров укыды.

Күп кенә чыгышлар Рязань өлкәсенең татар топонимикасына, татар авыллары һәм аларның халкы тарихына, Бөек Ватан сугышында катнашкан төрле милләтләрдән булган кешеләргә багышланды. Катнашучылар хәзерге көндә һәм тарихи ретроспективада төбәктә милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләрне үстерү мәсьәләләре турында фикер алыштылар.

● 2023 елның I кварталында Кытай Россиядән нефтьне башкалардан кыйммәтрәк бәягә – баррелен 71,7 долларга сатып алган (ә G-7 оешмасы Россия нефте өчен бәяне баррелен 60 доллардан арттырмаска куша). Кытай иң күп күләмдә сатып алучы да – ул тәүлегенә уртача 1,68 миллион баррель, Һиндстан 1,41 миллион баррель, Төркия исә нибары 110 мең баррель нефть сатып ала. Әлеге сәүдә Венгрия өчен дә бик файдалы – «Дуслык» нефтьүткәргече аша аңа кара алтын баррелен уртача 45 доллардан гына сатыла.

● Сүгенү сүзләрен куллану организмда бәхет гормоннары – эндорфиннар эшләнүгә булыша, алар исә организмга авыртуны баса торган дару кебек тәэсир итә.

Әстерханга сәфәр

Әстерхан – дөнья буйлап сибелгән татар халкының борынгыдан төпләнеп яшәгән җирләре. Монда XIV гасыр урталарында татар дәүләте – Әстерхан ханлыгы оешкан булган. Алар терлекчелек, яшелчә, карбыз, кавын, иген үстерү, балык тоту һ.б. белән шөгыльләнгән. Алтын Урда таркалганнан соң, татар ханлыклары бер-бер артлы рус дәүләте басымы астына эләгә. 1556 елда Әстерхан ханлыгы да шушы язмышка дучар була. Татар дигән исем астында тупланып яшәгән халкыбыз башка милләтләр белән кушыла башлый.

Май аеның соңгы көннәре – Әстерханның Җәмәле (Три протока) авылында XIII Бөтенроссия авыл Сабан туе узган көннәрдә Бөтендөнья татар конгрессы делегациясе белән бергә шушы якларга юл алдык. Әстерхан белән танышуны 210 ел элек салынган Ак мәчеттән башладык. Безне Аллаһ йортының тарихы белән аның имамы Мөслим хәзрәт Юнысов таныштырды.

Аны элекке морза Нурали Урусов мәхәлләсе дип йөртелгән урында Бохара дворы татары, беренче гильдия сәүдәгәре Даут Измайлов төзеткән. Анда аңарчы ук агач мәчет булуы теркәлгән. Яңа таш мәчеттә 1889 елның августыннан Ш.Мәрҗанинең укучысы – ногай мулласы Абдул-Мәжит Абдуллин имам булып хезмәт итә. Бу тирәлек хәзер Татар бистәсе дип йөртелә. Совет хакимлеге елларында Ак мәчетне дә ябалар, манарасын кисеп төшерәләр. Бина төрле елларда күн галантереясы цехы, балалар бакчасы, тегү цехы, икмәк пешерү урыны, фанера фабрикасы булып хезмәт итә. Мәчет бинасына бик нык зыян килә, аны зурдан кубып ремонтлау сорала. Аллаһ йортын 1992 елда мөселманнарга кайтаралар. 2008 елда Әстерханга 450 ел тулуны билгеләп үткән вакытта Казан хакиме И.Метшин мәчетне реставрацияләү өчен акча бирә. Мөслим хәзрәт Юнысов, 1997 елда Казанда Мөхәммәдия мәдрәсәсен тәмамлап кайткач, шушы мәчеттә эшли башлый. Ул елларда әле мәчетнең манарасы да, михрабы да булмый. Гомумән алганда, Әстерхан шәһәренең үзендә 12 мәчет бар, аларның барысын да татарлар салган, төзелешләрдә Бохарадан килүчеләр дә катнашкан. Бер мәчет шигыйларныкы. Мәдрәсәләре дә бар. Анда 100 дән артык кеше укый. Мәчеткә гыйбадәт кылырга йөрүчеләр күп. «Җомга намазларына хәтта керә торган коридорлар да тула. Ә инде дини бәйрәмнәребез көннәрендә ике меңгә якын кеше җыела. Әмма алар арасында татарлар аз, милләтәшләребез инде телләрен онытып бара. 20-30 яшьлекләр нигездә барысы да үзара русча гына аралаша», – ди Мөслим хәзрәт. Мәчетнең имам-хатыйбы Илһам хәзрәт Измайлов та татар милләтеннән.

Әстерхан өлкәсендә төрле елларда күренекле татар язучылары һәм җәмәгать эшлеклеләре булып киткән. Әйтик, 1910 елда «Идел» газетасы редакциясенә шагыйрь Сәгыйть Рәмиев эшкә чакырыла. Соңрак ул икенче нәшриятка эшкә күчә. 1911 нче елда Сәгыйть Рәмиев чакыруы белән Әстерханга Г.Тукай килә, «Люкс» кунакханәсенә туктала, соңрак дусты Сәгыйтьтә кунак була. Шагыйрь бу якларга саулыгын ныгыту нияте белән юл алса да, биредә яшәүче милләттәшләребезнең рухи һәм мәдәни тормышына кушылып китә, шигърият сөючеләр белән аралаша. Әйтик, Татар бистәсендә Г.Тукайның иҗатына багышланган очрашу була. Шагыйрь биредә үз заманының танылган табибе Нариман Нариманов белән очраша. Ул аңа киңәшләр бирә. Кымыз белән исә Калмык Базары дигән авылда дәвалана. Тукай Әстерханда 29 апрельдән 6 июньгә кадәр була. Кымыз белән дәвалану аңа булышадыр, саулыгы да яхшырып киткәндәй тоела.

Бүген инде Әстерханның 74 нче мәктәбе һәм аның янындагы матур, җыйнак бакча Г.Тукай исемен йөртә. Шунда ук Тукайның һәйкәле дә куелган. Бөтендөнья татар конгрессы делегациясе шагыйрь һәйкәленә чәчәкләр салды.

Әстерханда шагыйрь Һади Такташ та булган. Татар бистәсендәге Көнчыгыш клубында аның белән очрашу оештыралар. Ул төн буе сәхнәдән үзенең шигырьләрен сөйли.

1933 елда Әстерхан якларына Муса Җәлил килә. Ул шәһәр белән таныша, беренче районара алдынгы балыкчылар корылтаенда катнаша, делегатлар белән аралаша, балык промыселларына бара. Төбәкнең Киләче (Килинчи) авылына «Яшькын» журналы редакторы Шакир Фәтхуллин белән бергә килә. Җәлил ул вакытларда колхоз рәисе Ибраһим Мәхмүдов йортында туктала һәм 11 көн яши. Шагыйрьнең бу якларда булуы төбәкнең мәдәни тормышына зур вакыйга булып кереп калган, аңа кагылышлы истәлекле ядкәрләр бүген дә саклана, диләр. Еллар узгач, Ибраһим аганың онычы Наил Бәширов «Җәлилнең Киләче җәе эзләреннән» дигән документаль очерк язган. Ул анда Салиха әбисенең Җәлил йоклаган тимер караватка берәүне дә якын җибәрмәве, хәтта үзе дә утырмавы турында яза.

Җәлил Киләче авылында урып-җыюда да катнаша, аннары колхозчыларның хезмәтен үзенең «Җиһан» поэмасында чагылдыра. Әстерханлылар патриот-шагыйрьнең эзләрен бүген дә кадерләп саклый. Шәһәрнең үзендә аның исемендәге урам бар, ә инде Әстерхан дәүләт университеты каршындагы бакчада Җәлилгә һәйкәл куелган. Университет бинасында Әстерхан ягы иҗатчыларына багышлап уздырылган конференциядән соң Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты җитәкчесе Данис Шакиров җитәкчелегендәге делегация һәйкәлгә чәчәкләр куйды.

Конференция барышында искәртелеп үткәнчә, Әстерхан өлкәсендә бүген 17 татар авылы исәпләнә. Һәр авылның тарихы үзенчәлекле. Татарлар төрле елларда төрле төбәкләрдән килеп урнашкан. Һәр авылда үзенең нәселе, төбәге белән кызыксынган бер-ике булса да кеше бар.

Гыйльми җыенда бу як тарихчысы Серур Мифтяева белән таныштык. Ул Әстерхан өлкәсенең Канга авылында гомуми белем бирү мәктәбендә татар теле укыта. Директор Елена Усманова тырышлыгы белән мәктәптә атнага бер сәгать татар теле дәресләре кертелгән. Моннан тыш атнага ике тапкыр өстәмә дәресләр дә алып барыла икән. «Балалар дәрескә бик теләп йөри, «Илһамият», «Тукайга мәхәббәт илә», «Татар сүзе» кебек зур конкурсларда катнашалар», – дип сөйләде Серур ханым. Ул үзе Әстерхан җирендә тәүге татар шагыйрәләренең берсе – Газизә Сәмитова (1862-1929) иҗатын таныту, шигырьләрне төрле телләргә тәрҗемә итү буенча эш алып бара.

Бу көнне Әстерхан өлкәсенең Иске Канга (Старокучергановка) авылында Татарстан сәнгать осталары һәм коллективлары катнашында зур концерт булды. Халыкны Татарстан Премьер-министры урынбасары, Милли Шура рәисе Васил Шәйхразыев һәм өлкәнең вице-губернаторы Павел Паутов сәламләде, татар мәдәнияте үсешенә өлеш керткән өлкә активистларына Рәхмәт хатлары тапшырды. Татарстан Дәүләт җыр һәм бию ансамбле, «Казан» бию ансамбле, «Агыйдел» дәүләт җыр һәм бию ансамбле, ТР халык артистлары Рөстәм Асаев, Алинә Шәрипҗанова, Рөстәм Закиров, Зәйнәп Фәрхетдинова, Гөлзада Сафиуллина һ.б. башкаруындагы җыр-биюләрне карарга исә өлкәнең барлык татар авылларыннан килгәннәр иде.

Милли киемнәрдән мәйданда басып торган ансамбль – Әстерхан өлкәсенең Линейное авылыннан килгән һәм алты ел дәвамында Рәфкать Әбделмәнов җитәкчелегендә иҗат итүче «Шатлык» фольклор ансамбле икән. Коллектив 50 ел дәвамында «Авылдашлар» исеме белән сәнгать эшчәнлеген алып барган, яңартылып җибәрелүенә алты ел. Затлы милли киемнәре Казанда тегелсә, финанслар белән район җитәкчелеге ярдәм иткән. Рәфкать әфәнде татар теленең юкка чыга баруы, балаларның телне, гореф-гадәтләребезне, тарихыбызны белмәвенә нык борчыла. Соңгы елларда өлкәдә татар телендәге газеталар да чыкмый башлаган. Милләттәшләребезнең кимүенең төп сәбәбе – башка халыклар белән кушылу. Ә инде милләттәшләребезнең үзләренең олуг шәхесләрен зурлап, исемнәрен мәңгеләштерүе, бу якларда аларны башка халыкларның да яхшы белүе җанга сары май булып ятты.

Сөембикә КАШАПОВА.
Автор фотолары.

«Сердәш»кә җан өргән Ринат

Чаллыда Татарстанның атказанган мәдәният эшлеклесе, талантлы композитор Ринат Гобәйдуллинны искә алу кичәсе узды

Мин килеп җиткәндә, халык җыела башлаган иде инде. Бакча эшләре вакытында, өстәвенә, җомга көнне оештырылган чарага халык «Энергетик» мәдәният сараен тутырып килмәс, дип хәвефләнгән булганнар. Башлап килүчеләр дә – өлкән буын һәм Ринат Гобәйдуллин истәлегенә ел саен оештырылучы фестивальдә җиңүчеләрнең якыннары. Чара исә Р.Гобәйдуллин истәлегенә багышланган VI төбәкара «Сердәш» фестивале җиңүчеләре концерты һәм аларны бүләкләү форматында узды. Ринат абый үзе исән булса, туган авылыннан килгән җыр коллективы кызларын да, район үзешчәннәрен дә, саф татарча җырлаучы 4-5 яшьлек сабыйларны да яратып калыр иде.

Якты урамнары,
Чәчәк бураннары,
Тальян моңы китә еракка...
Чаллы сиреньнәре,
Айлы ак төннәре
Сөю бүләк итте йөрәккә...

Ринат Гобәйдуллин исемен ишетү белән, күңелгә иң беренче шушы җыр килә. Хәтер кичәсе дә гашыйклар җыры, Чаллы гимнына әверелгән «Чаллы сиреньнәре» белән башланды. Экран аша өздереп үзе җырлады ул аны. Сәхнәдә сирень чәчкәләре тоткан абый-апалар вальс әйләнде.

Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Ринат абый белән иңне-иңгә куеп озак еллар эшләгән сәнгать остасы Гөлзада Рзаева сүзләренчә, сирень ул – Чаллы шәһәре һәм аның тарихы белән турыдан-туры бәйле чәчәк.

«Чаллыбызның барлыкка килүенә 3 елдан соң 400 ел булачак. Аның документлары архивларда саклана. Бу җирлектә Чаллы булган. Аның Яңа шәһәр дип яңарышы «Камгэсэнергострой» оешмасы килеп, төзелеш башлангач булды. Ә бирегә һәрбер агач өйнең каршында бакчасы бар иде. Ә ул бакчаларда гөрләп сирень чәчкәләре үсте. Ринат Гобәйдуллин талантлы шагыйрь Мирһади Разовның шигырен мәнә шул Чаллы рухын чагылдырган бик матур бер җырга әверелдерде. Ринатның һәр җыры яхшы, ләкин монысын халык аеруча яратып кабул итте.

Ринатыбызны без онытмыйбыз, аның хөрмәтенә менә шундый матур кичәләр оештырабыз», – диде ул.

Г.Рзаева алдагы кичтә өзеп кайткан бер кочак сиреньне сәхнә почмагына, вазага утыртып куйган иде. Аның башларны әйләндерерлек хуш исе алдагы рәтләргә кадәр килеп житте, үземне язгы бакчада утырган кебек тойдым.

Ринат абый 6 ел арабызда юк инде. Ләкин аның «Күңелеңә авыр алма», «Бир кулыңны, гүзәлем», «Күчмә кошлар», «Мәк чәчәкләре», «Адашкан мәхәббәт», «Күз карашың китми күңелдән», «Сандугач кайткан таллыкка», «Яшьлек кыңгыраулары» кебек балачакта тыңлап үскән җырлары күңелдә яши. Ринат абый – 200дән артык җыр авторы, шулай ук төрле шәһәр театрларының спектакльләренә музыка иҗат иткән кеше. Алай гына да түгел, Ринат абый – «Сердәш» анасамбленә нигез салган һәм аның алыштыргысыз җитәкчесе булган шәхес.

Ринат абый – җыр-моңга гашыйк нәселдән. Аның әнисе бик матур җырлый торган булган, ләкә, бик яшьли, фаҗигале төстә үлеп киткән. Әтисе Шәрип тә яшь чакларында тальян тарткалый, ләкин бу шөгылен, тормыш мәшәкатьләре басканга, онытып тора. «Ичмасам син уйнарсың әле, улым», – дип, 5 яшьлек Ринатка гармун бүләк итә. Ринат менә шулай кечкенә чакта ук гармунда уйнарга өйрәнә, матур итеп җырлый.

Туган авылы Ютазы районының Иске Урыссу урта мәктәбен тәмамлаганнан соң, музыкага һәвәс егет Лениногорскиның музыка-педагогика училищесына юл тота. Хезмәт юлын Питрәчтә музыка укытучысы буларак башлый. Ә 1976 елда Чаллыга килеп 18 нче мәктәптә музыка укыта башлый. 1977 елда «Гренада» паркындагы «пятачок»та талантлы татар яшьләрен җыеп, «Сердәш» ансамблен туплый. Шул ук елны әлеге ансамбль беренче тапкыр сәхнәгә чыга. Ринат оештырган «Сердәш» ансамбле Татарстанда беренче «яшь йолдызлар мәктәбе» буларак танылла. Иҗади эшчәнлеге дәверендә Ринат абый – зур сәхнәгә бер төркем талантлы артистлар плеядасын үстереп чыгарган шәхес. Композитор тырышлыгы белән Габидулла Хөрмәтуллин, Эльмира Сөләйманова, Резеда Шәрәфиева, Инзилә Сәлимова, Равил Галиев, Айгөл – Ришат Шәйхетдиновлар һәм башка җырчылар зур сәхнәгә аяк басты.

Май аенда – Ринат абыйның туган көне. Ул ел саен гомер бәйрәмен үзе җырчы дәрәҗәсенә җиткергән шәкертләре, иҗатташ дуслары, тугры тамашачысы белән үткәрә торган булган. Үзенең вафатыннан соң да шәкертләре шушы аның истәлегенә оештырылган фестивальгә килеп, Ринат абыйның популяр җырларын башкарып, остазлары турында берничә җылы сүз әйтә. Ринат абый белән берлектә иҗат икән шагыйрьләрдән залда Галиәхмәт Шаһине генә күрдем. Кичәдә Ринат абыйның кызы Алсу Садриева да бар иде. Алсу ханым үзләренең гаиләдә 3 бала үсүләрен әйтте. Төпчек уллары якыннарын хәсрәт утына салып, яшь чагында фаҗигале рәвештә бу тормыштан китеп барган. Ринат абыйның олы улы гаиләсе белән Мәскәү шәһәрендә гомер итә. Алсу ханым Чаллының 77 нче гимназиясендә укытучы булып эшли. Әниләре дә хәзерге көндә исән-сау.

Алсу ханым әтисенең искиткеч бала җанлы булуын искә алды. Сөйләгәндә күз яшьләре менә түгеләм-түгеләм дип торды. Алсу ханым йөз-кыяфәте белән дә әтисенә бик охшаган.

«Әти безнең өчен һәрвакыт үрнәк булды. Бик мәрхәмәтле, гел елмаеп кына торучан кеше иде. Киңәшләрен кызганмады. Безнең күңелләрдә әти әле һаман да исән кебек. Без аны гел үзебезнең янәшәбездә хис итәбез. Ул бик тә оныкларын яратты. Буш вакыты булган саен минем балаларым янына йөгереп килә иде. Без балаларын да шундый зур мәхәббәт белән яратты ул. Мондый чаралар оештырылып, әтинең җырларын тыңлагач, әтинең үзен күргән кебек булам», – диде ул.

– Әтиегезнең дөньяга чыкмаган җырлары калдымы?

– Бик күп. Без аларны әтине искә алып, гел тыңлап торабыз һәм җырларга теләгән кешеләр булса, бик рәхәтләнеп бирәбез. Әтинең җырлары үзенчәлекле. Ул һәрбер җырына күңелен салган. Аның җырлары бер-берсенә охшамаган, алар төрле, шундый күңелгә керә торган...

Хуш, инде «Сердәш» фестиваленә күчик. Ринат Гобәйдуллин истәлегенә оештырылган төбәкара «Сердәш» фестивале быел 6 нчы тапкыр үткәрелә. Бәйгенең оештыручысы, «Энергетик» мәдәният сарае директоры урынбасары Рөстәм Фәттахов әйтүенчә, бәйгедә 20 дән артык коллектив, 50 дән артык солист катнашкан. Катнашучыларның иң кечкенәсенә – 4, иң өлкәненә 70 яшь. Җиңүчеләрне «Р.Гобәйдуллин репертуарындагы җырлар», «Халык җыры», «Вокал», «Автор җыры» номинацияләрендә билгеләгәннәр.

Җиңүчеләр арасында нәкъ менә Ринат абыйның җырларына тукталган авторлар бармак белән генә санарлык булып чыкты. Рөстәм Фәттаховтан: «Ни өчен фестивальне оештырганда Ринат абыйның җырларын гына башкару шарты куелмый?» – дип кызыксындым.

«Әлбәттә, фестивальдә Ринат абыйның җырлары күбрәк яңгыравын теләр идек, ләкин башка номинацияләрне дә кертмичә булдыра алмыйбыз. Бу – катнашучылар саны тагын да зуррак булсын, Р.Гобәйдуллинның исемен, аның истәлегенә шундый фестиваль үткәрелүен башка район-шәһәрләрдә дә белсеннәр, дигән максат белән эшләнелә», – диде ул.

Фестивальнең географиясе быел да киң: бирегә Чаллы, Әлмәт, Түбән Кама, Казан шәһәрләре, Саба, Тукай, Зәй, Ютазы, Мамадыш h.б. районнардан килгән коллективлар һәм җырчылар бар иде.

Ринат Гобәйдуллинның туган авылы Иске Урыссудан ерак араларны якын итеп килгән «Дулкын» һәм «Ялкын» ансамбльләре чыгышлары яратып кабул ителде. Алар арасында Ринат абыйның апасының кызы да бар иде.

Бәйгенең Гран-прием Зәйнең «Адымнар» татар мәдәнияте клубына йөрүчеләр яулады. Клубның җитәкчесе – Фәннүр Миннекаев.

Ринат абый – үзеннән соң матур эз калдырып киткән шәхес. Алдагы елларда бу чара тагын да зуррак масштабларда, үзе сәхнәгә чыгарган шәкертләре, Ринат абыйның җырларын башкаручы танылган артистлар һәм иҗат әһелләре катнашында узар, дип ышанасы килә.

Гөлназ ХӘБИБУЛЛИНА.

intertat.tatar

Зимфира ИСЛАМОВА

Йөгем кайчак кузгата да алмыйм, Үзе мине тарта юл буйлап...

АВЫР ЧАКТА АЛЛАҺ КИРӘК

Раббым, диеп, килеп егыласың,
Бер таяныр ноктаң калмаса...
И син, бәндә, дингә якын барма,
Сүзләреңдә тора алмасаң.

Хәсрәтләрдә күпләр өмет итә:
Аллаһ, җәлләп, сонар ярдәмен.
Бу заманда әллә иман нуры
Кредит булып безгә кердеме?..

Авыр чакта дога-сүрәләрне
Укып утырганның көнозын,
Кайгы үткәч, изге китапларын
Әкрен генә каплыйдыр тузан...

Акча, диеп, эш-мәшәкать белән
Фани дөнья баса башына.
Дога кылу, шөкер итү кая
Раббыбызның биргән ашына?..

Үзе тапкан байлык, үз малы бит!
Әлхәм сүрәләре онтыла.
Тик кыенлык тугач, Аллаһыдан
Курку үрмәлидер котына.

Ничек мөэмин була аласың син,
Боргаланып җирдә яшә дә.
Иманыңа кайтсаң, хаин булма –
Догаларың укы сәҗдәдә!

БӘЙЛӘНЕШ ӨЗЕЛГӘН

Бәйләнеш өзелгән үткәнгә –
Ишекләр йозакка ябылган.
Тетелеп уелган йөрәккә
Чачаклы ямаулык табылган.

Хатирә дәфтәре битеннән
Ант сүзен яшьләрем юдырган:
Син иден кояштай җылыткан,
Син булдың котыптай туңдырган.

Хәбәрсез югалган сөюне
Кызганып сыгыла талларым.
Гөлләр дә элекке түгелләр –
Сарыга буялган аллары.

Коела саргайган таҗлары,
Укылмый ертылган хатлардай.
Гаепләр өяргә хакым юк,
Сүз тапмыйм, кемнедер аклардай.

Кем кемне рәнҗетеп елаткан,
Хәятнең шатлыгын кем йоткан?
Ә вакыт җилләре ваемсыз –
Үпкәләр булган күк гел юктан...

* * *

Әниемнең кулы кулларымда,
Былбыл кунды йөрәк кылына.
Күңел елгам тулып ташкан иде,
Язгы судай кайтты ярына.

Әниемнең кулы кулларымда,
Куанычлар күчте җаныма.
Бу мизгелләр очып кайтыр әле
Сандугачлар булып таңыма.

Әниемнең кулы кулларымда:
Мин – иң көчле бу Җир шарында!
Сәгадәттә генә яшә, әни,
Сөртеп ташлап язмыш зарын да…

Әниемнең кулы кулларымда,
Исем китми дөнья малына.
Бары әни яннарында шулай
Кайгылардан җаным арына.

ҖИЛ ТЫНАР

Үзәге нык яфрак өзелми ул,
Уңнан вә сулдан йолкыса да
Усал җил.
Шул яфраклар халәтендә бүген
И мөкатдәс анам теле –
Туган тел!..

Бүген җилнең әллә бар максаты
Яфракларны җирдә тапауда? –
Котыра...
Тел ул – тамыр, тере күзәнәк ул.
Кем кизәнә аңа, үзе
Оттыра.

Һәр тере җан ия туган телгә.
Үз телендә сайрый кошлар да –
Соклангыч!
Чишмә җырлый бары үз телендә,
Күңелендә үз моңнары
Туплангач.

Җил ул тынар, ярсып арыр да бер;
Болыт капкаларын ачып, ай
Күренер.
Исән калган яфрак даирәсе
Үз телендәге сөйләмгә
Төренер.

Тоям, аңлыйм: яшел килеш яфрак
Өзелергә һич тә теләми
Агачтан!
Телебезне каерып йолкымагыз!
Чишмә үлмәс, таш астында
Калгач та!

ИНДЕ БЕЗНЕ КӨТМИ

Ничә еллар яшәлмәгән туган йортның
Бусагасын атлап кердем... тоям үзем:
Һәр почмакка сеңеп калган сабый күзем
Томырылып карап тора – таныймикән?..

Таныса да, үз итмидер ятим нигез.
Аһ, булмыйдыр язмышларда бәхет тигез!
Кыска юрган-бәхетемне өскә тартсам,
Ачык калып, өши ике аяк йөзе...

Миңа гына кыска микән юрган-бәхет?
(Кемнәрдер ул туган җирдә корган тәхет –
Китүләрнең әчесен дә татымаган.
Нигез тере. Тәрәзәләр ватылмаган.)

Хәтер елый: үз нигезем, туган йортым
Якты йолдыз күңелемнең түрләрендә.
«Китмәс идем!» дигән ачы үкенүләр
Ярала ник гомернең тик үрләрендә?..
Яраланган җәнлек бүген туган йортым:
Каны түгел, җаны тама түшәмнәрдән.
Ишелгән мич... баз сайгагы каерылган...
Дәвалауны көтми бездән (үшәннәрдән).

Килеп кергәч, бер җылылык җанга иңде:
Абыемның, газиз әткәм, әнкәемнең
Рухы йортны саклап монда йөри кебек...
Табын җәйми, чәй дә эчми китәм кире.
Кыек авыз – күпне күргән ишек калды
Әллә елап... әллә көлеп...

ЙӨГЕМ ҮЗЕМНЕ ТАРТА

Үз юлым, дип, барган булам инде...
(Кемдер дәшкән иде бу юлга)
Җиңеллекне вәгъдә итмәсә дә,
Гыйззәтле йөк сонды ул кулга.

Мин ышандым аңа юл башында,
Гөлләр чәчтем адым аралаш.
Хозурлыкны тоеп атлаганда,
Инде килеп, имеш, син адаш...
Сулгарак та бер каерыр идем.
(Әнә читтә тигез сукмак бар!)
Ярамыйдыр инде, азга калгач,
Бер сайланган юлдан чыгулар.

Арыдыммы... өметсезлек шәмен
Токандырды күңел яңадан.
Эзләремә тузан кунар инде –
Пәри туе кайный һавада.

Әкрен атлыйм хәзер – көч чамалы,
Гомер аты ала чыгымлап.
Йөгем кайчак кузгата да алмыйм,
Үзе мине тарта юл буйлап.

КӨЧЛЕ АТНЫ ҖИГӘЛӘР

Үзе хәлсез, үзе кире
Атны бик еш җикмиләр.
Килеп чыккан мөһим эшне
Күндәм атка йөклиләр.

Давылга ул каршы атлый,
Качмый, эзләп күләгә.
Эшләгән көчле атларга
Чыбыркы да эләгә.

Басып кына торган атның
Бер гаебен тапмыйлар.
Ә эшчән ат ялгышсамы?!
Бар уңышын таплыйлар.

Көчле атны сайлыйлар шул
Буразналар ярырга.
Камчы өстә биеп тора:
Тиеш түгел арырга!

Ике ат та, язганынча,
Гомер юлын үтәләр.
Ә Яшәүне тик көчлеләр
Алгарышкы илтәләр.

СИН БИРГӘН ЧӘЧКӘЛӘР

Нәкъ бүген хәтергә төштең син:
Бер кочак чәчкәләр китердең.
Йөрәгем тургайга әйләнеп,
Күңелне канатлы иттердең.

Күкләрнең капусы ачылды,
Нур яуды меңләгән төрләрдән.
Наз тулы таҗларны сыйпагач,
Моңлы җыр агылды гөлләрдән.
Тик шундый оялчан идем лә –
Сүзләрем өзелде телемдә.
Син киткәч борылып янымнан,
Күзем ә яшьләрем эленде.

Моннан соң гомерем буена
Никадәр гөлбәйләм бирделәр.
Кадерле мизгелләр булгандыр...
Тик алар башкача иделәр.

Иң купшы, иң нәфис гөлдән дә
Күңелгә дәрьялар тулмады,
Яшьлегем таңында син биргән
Кырдагы чәчкәләр булмады.

СУГЫШ

Сугыш – тугыз башлы аждаһа ул,
Кеше тәне белән туена.
Җәен булсын, язын, кышын булсын –
Кеше каны белән коена.
Сугыш. Һәр хәрефе утлы күмер –
Бәгырьләргә төшеп көйдерә.
Өрлек кебек таза егетләрне
Әрдәнәләр итеп өйдерә.

Сугыш!.. мәңге туймас ач карыны,
Җелекләргә чаклы суыра.
Өзеп алган һәр яшь гомер өчен
Меңәрләгән җанны куыра.

Сугыш яшәү белән үлем чиген
Миналарга ялгап беркеткән.
Үз Ватанын яклап көрәшкәндә
Ир-егетләр тиңдәш бөркеткә!

Сугыш бертуганнар итеп куя
Яуда янәшә атлаганны,
Һәрбер солдат фәрештәдәй күрә
Үзен калкандай саклаганны.

Сугыш утка тота газиз Җирне,
Хәрабәләр ясый шәһәрдән.
Гаепләләр яначак тәмугта
Аналардан яуган каһәрдән.

ЯЛГЫЗ КОШ

Ялгыз гына бер кош оча
Тау өстеннән.
Таралышып беткән ишен
Ул көтсенме?!

Бергә чакта башка кошлар
Чит иткәнме,
Әллә үзе аерылып
Ул киткәнме?

Очышының биеклеген
Беркем күрми.
Аның оста кош икәнен
Сөйләп йөрми.

Ялгызлыкны яратканнар
Дан эзләми,
Эш-гамәлем күрсеннәр дип,
Һич безләми.

Тик һаман да биеклеккә
Ул омтыла.
Оча алмас хәлгә җиткәч,
Бер онтыла...

Тукай районы.

Татарстанның халык шагыйре Ркаил Зәйдулланың Татарстан Язучылар берлеген җитәкләвенә 2 ел тулды. Татарстан Дәүләт Советы депутаты булуына 4 ел булып килә. Чираттагы әңгәмәбез аның Язучылар берлеге рәислегенә алынганда әйтелгән планнарының үтәлешен барлаудан башланды. Әмма аның белән генә тукталып калмадык, бүгенге язучыларга кагылышлы вәзгыять турында да сөйләштек. Хәзерге вакытта Язучылар берлеге бинасында ремонт бара. Шуңа да сүз ремонт темасыннан башланды.

Безнең иң зур бәла –

– Капиталь ремонт инде бу. Мин аны сорап Президентка кердем. Түбәдән шаулап су үтә иде. Нигезне дә ныгыталар. Чөнки стенада ярыклар да пәйда булган. Подвалда чүп-чар арасыннан томалап калдырылган бүлмә дә таптылар әле...

– Скелетлар чыкмастыр шәт?

– Мин дә шикләнгән идем. Заманында бина Чека кулында да була бит... Тик эченә кереп булмады аның. Аны арчып чыгару өчен бик күп чыгымнар, җылыту системасын алыштырырга кирәк. Акча юк... Әле бу тәзәтү-сипләүнең очына чыгып булырмы? Төзелеш материаллары коточкыч кыйбатланды. Ярый әле түбәсен ябып өлгердек, подвалы эшләнеп бетте. Бинаның үзен эчтәнтыштан рәткә китерәсе бар.

Бинаны сәүдәгәр хуҗа мәңгелеккә дип салган булган. Совет вакытында, ремонтлый-ремонтлый, вентиляция шахталарын томалаганнар.

– Алга таба подвалны кулланып булачакмы?

– Андагы ике бүлмәне тоташтырдык, араларын арка белән генә бүлеп куйдык. Яшьләргә бирер идем, янып йөрүчеләр булса... Юк бит... үзең ясый алмыйсың яшь язучыларны... Бәлки, бильярд бүлмәсе эшләргәдер? Элек Союзда бильярд өстәле бар иде, үзем дә уйнап йөрдем, каядыр «аякланган». Элек бит Союзга язучылар күп килә иде, яза торганнары да күп иде. Хәзер члennнар күп, яза торганнары аз. Без берлек хозурында «Язучы» дигән китап нәшрияты ачмакчы булабыз. Бәлки, нәшрият шунда булыр. Төрлечә планнар корабыз инде...

– Ремонт башлангач, ни дә булса эшләдем, дигән горурлык хисе барлыкка килгәндер бит?

– Менә Парижда Роза Туфитуллованың «Гөлсем» романы французча басылып чыкты. Аңарчы Анкарада төрекчә чыккан иде. Әдәбиятыбыз өчен горурландым. Ә ремонт... Ул да мөһим, ләкин беренчел түгел.

– Ркаил, син рәислеккә килгәндәге программаңның 18 пунктын да карап чыгабызмы?

– Йөз процент үтәп булмый инде аны. 2 елда шактые үтәлде сыман... Әле тагын 2 ел запаста бар. Мин әйткәннәрнең 30 проценты эшләнсә дә – зур казаныш. Язучылар берлеге милли мәнфәгатебезне яклау өчен мөнбәр булырга тиеш! Менә монысы һәрвакытта исемдә.

– Ул мөнбәрдә син берүзең генә бугай..

– Юк инде, нишләп алай дисең? Безнең мобиль төркемнәр оештырып, очрашулар ясап тору планы бар, аны Татарстан Рәисенә дә күрсәттем. Һәм ул үтәлә дә. Халык белән очрашмаган көнебез сирәк. Язучылар айлар дәвамында Казан, Чаллы, Әлмәттәге балалар бакчаларына очрашуга йөрде. Алар өчен Марат Әхмәтов ярдәмендә беркадәр матди стимул да булдырдык. Бу эш киләчәктә дә дәвам итми калмас. Әле Чистайда очрашу үткәрергә җыенабыз. Ул бит революциягә кадәр татар мәдәниятенең үзәге булган. Фатих Кәрими, Исхакый, Фуад Туктаровлар укыган атаклы мәдрәсә эшләгән. Фатих Әмирхан абыйсының «Әмирхания» мәдрәсәсе...

– Бая «яшьләр» дип сүз башлаган идек...

– Янып торган егетләр юк! Булсалар, күтәреп алыр идек. Яшьләрнең килүе турыдан-туры мәктәп белән бәйле бит ул... Хәзер әдәбиятка, өлкәнәйгәч, тәҗрибә туплап киләләр. Нидер югалган була, әйтик, дәрт, фидаилык... Кызлар күп яза, арада сәләтлеләре дә бар.

– Син әдәбиятка килгәндә хәлләр башкача идеме?

– Ул чакта да чәчрәп торган талантлар аз иде инде. Алар күп була да алмыйдыр... Артык өлкәнәйдем бугай, еш кына уйланып ятам, нәтиҗәләр ясыйм – мине мәктәптә укыганда ук күреп алганнар, иркәләп үстергәннәр. Мин заманында аның кадерен дә белмәгәнмен. Миңа булышканнар икән, мин дә башкаларга булышырга тиеш. Ләкин рәис булгач, тагын бер нәрсә күзгә ташлана башлады: картая-картая, кешенең нәфесе дә үсә икән. Барысының да түгел, әлбәттә. Бәлки, материалист булудандыр бу...

– Бу – яшь арту белән киләме икән, әллә андый кеше яшь чакта да шундый сөмсез булганмы?

– Хәер, картлыкка-яшьлеккә дә карамыйдыр инде бу мәрәкә. Кешенең холкына, иманына бәйледер. Алтыдагы – алтмышта, диләр бит. Яшьрәк чакта кеше үз-үзен контрольдә ныграк тота ала, яшерә белә. Картая төшкәч, ачыла. Картайгач, гомумән, бөтен сыйфатлар ачыла.

– Синең өчен, алай булмаска кирәк, дигән бер мисал инде бу.

– Мин – бөтенләй бүтән камырдан бугай... Өздереп әйтергә ярамый, әлбәттә. Кешенең әллә нинди эверелешләрен хәтерли тарих. Хәзер дә күзәтеп торабыз. Бигрәк тә күз уңындагы кешеләрне…

– Программаңны барлауны дәвам итик. Тәрҗемә үзәге буенча эшең әйбәт бара кебек.

– Үзем канәгать, тик әллә кая сикереп булмый. Тәрҗемә мәсьәләсендә азәрбайҗаннар, кыргыз, казах, үзбәкләр белән сөйләшәм. Үзешчән итеп түгел, дәүләт белән дәүләт аралашып төзелсен иде дә андый килешүләр. Бигрәк тә төрки илләргә барганда, Татарстан делегациясе составында язучылар да булсын иде. Республикалар белән мөнәсәбәтләр булдыруны элеккеге кимәленә җиткереп булырмы, белмим, дөнья нык үзгәрде, ләкин без бу юнәлештә эшлибез. Мин Үзбәкстанда, Азәрбайҗанда булдым, күп төрки язучылар белән очраштым. Азәрбайҗанда татар хикәяләре антологиясе нәшер ителде. Башка илләрдә дә чыгарырбыз, дигән ышаныч бар.

– Төрки республикалар татар язучыларын Россия контекстында кабул итәме?

– Төрки халыклар безне зур тарихы булган мөстәкыйль халык итеп кабул итә, чөнки аларның язмышында татарның роле зур булган. Мәгърифәт, нәшрият, әдәбият ягыннан бик зур йогынты ясаганбыз. Ләкин үткәннәр белән мактану гына ерак алып бармас, безгә бүген дә көчле булырга кирәк. Көчле әдәбият! Менә нәрсә һәр халыкның күңеленә юл ача. Шуңа иң әүвәл көчле, заманча әдәбият тудырырга, аннары Шәрыкта да, Гарәбтә дә шул әдәбиятны таратырга. Төп максатларымның берсе шул. Татарны дөнья онытмасын!

Әле яшь шагыйрь вакытымда, 1990 елда, Үзбәкстанда бер конференциядә иң беренче итеп миңа сүз биргәннәр иде: бу бит – минем хакка түгел, татарга хөрмәт йөзеннән. Хәзер беренчеләрдән булып мөстәкыйль дәүләт вәкилләре сөйли. Бәйсез булсаң, әдәбиятыңа карап тормыйлар. Дөрес, фестивальләрдә кемнең кем икәне ачыклана, әлбәттә. Шуңа күрә безгә башкалардан аерылып торган көчле әдәбият кирәк. Башны югары тоту өчен!

Тәрҗемә буенча эшебез күренә – Төркиядә, Мәскәүдә, Азәрбайҗанда исән-сау татар язучыларының XXI гасырда иҗат иткән хикәяләр антологиясе чыкты. Төркиядәге «Һәҗә» журналында яшь шагыйрьләрнең шигырьләре басылды. Күз уңында булмаган, читтәрәк кала торган шагыйрьләр дә керде. Мәсәлән, Чаллыдан Айрат Суфиянов, Сирень Якупова, Факил Сафинны шагыйрь дип белүчеләр сирәк, ә шәп шагыйрьләр бит!

Бәлки, тагын да төшеп калучылар булгандыр. Габделнур Сәлимне тәкъдим иткән идем, Фатих Кутлу аны тәрҗемә итә алмады. Шулкадәр метафора белән яза торган шагыйрь. Аңлатып бирү өчен үзен табып булмый… Олы шагыйрьләр арасында сәер кешеләр күп... Габделнур инде ул яшь чакта ук француз сюрреалистлары кебек язды. Аннары, Чаллыга киткәч, кришнаит та булып алды. Әзләнә торгач, яңадан исламга кайтты. Соңгы шигырьләре арасында төрлесе бар. Борынгы төрки шәкелне дә яңартты, дини дидактикага да мөрәҗәгать итте. Шагыйрь һәрвакыт эзләнергә тиеш.

– Теге пунктларның берсендә «Әдәби фонд кирәк» дигән идең. Баш тарттыңмы ул фикердән?

– Өстәмә бюрократик мәшәкатьләр китереп чыгара. Элек аның механизмы бар: китаплар чыккач, Әдәби фондка акча күчә иде. Хәзер андый чыганаклар юк. Акча табу өчен иганәчеләр эзләргә мәҗбүр булабыз. Акча бирәм, диючe булса, Союзның үз исәп-хисап счеты бар. Бирәм дип атлыгып торучылар гына юк. Депутатлык әйбәт инде бер караганда, әллә кемнәр белән сөйләшеп була. Хәтта алай гына да түгел, берәү: «Союзга ярдәм кирәкмиме?» – дип сорады. «Һәрвакыт ярдәм кирәк», – дидем. Андыйлар да бар, дисәм, андый кеше берәү генә булды. Хәзер бит вәзгыять тә катлаулы, шулай да, сорагач, гадәттә, каршы килмиләр. Мин бит үземә сорамыйм, безнең ул акчаны кайда ничек тоздырганлыкка мәгълүмат ачык. Өлкәннәргә, авыруларга һәрдаим ярдәм итәргә тырышабыз.

– Теге пунктларда грантлар мәсьәләсе турында да әйткән идең...

– Без бер грант оттык та бит әле. РФ Президенты грантын. Ул акчага китапларны цифрлаштырырга аппаратура алдык. Фронтовик язучыларның әсәрләрен электрон вариантка күчердек. Грантлар күп икән бит ул, белешеп торырга гына кирәк. Ләкин алган очракта да мәшәкате бихисап, туктаусыз исәп-хисап язасы. Анысы да табигыйдыр, акча әрәм-шәрәм ителергә тиеш түгел...

– Сүз арасында нәшрият ачу турында әйтеп куйдың...

– Бюрократик киртәләр күп. Махсус шуның белән генә шөгыльләнүче дә юк. Минем исемә төшкәндә, эш кызуланып китә... Нәшрият ачу эше соңгы этапта хәзер, барлык рөхсәтләр алынып бетте. Аның бит әле эшләп китүе дә кирәк. Хәзер җүнле-башлы редакторларга кытлык... Китап чыгару өчен заказлар булуы кирәк.

– Тагын яшьләргә күчик әле. Барлык рәисләр дә «яшьләр белән эшләргә кирәк» дип гел тәкрарлады. Эш башлар алдыннан син дә әйттең. Хәзер ул турыда бик сүз кузгатмыйсың... Яшьләр белән эшләп буламы, аларга сез кирәкме?

– Бик үк кирәк тә түгел бу-

куркаклык!

гай... Син «авырткан җиргә» кагылырга маһир инде. Катырак та әйтим әле: яшьләр, гомумән, безне санга сукмый – шундый тәэсир кала. Без, мөгаен, аларга «нафталинлы» булып күренәбездер. Бер тапкыр Тукай клубында Йолдыз Миңнуллина җитәкчелегендә яшьләрнең иҗат кичәсен оештырган иде. Хатыйп Миңнегулов белән янәшә утырдык, ул – университеттагы остазым. Яшьләр үз язганнарын укыганда берни аңламый, югыйсә, бөтен борынгы шәрык, төрки шигъриятен айкап чыккан кеше! Мин дә мондый опусларны төшенмим. Нәрсә әйтергә тели? Кафия юк, вәзен юк, сүз байлыгы юк дәрәҗәсендә... Шигырьнең бит аның үз музыкасы була, шигырь буш булса да, музыкасы бар икән, тәэсир итә. Монда ул да юк! Мин бит яшьләрнең кәгазьгә басылган шигырьләрен дә укып барам, яки бик примитив, яки бернәрсә аңламыйм. Яңа поэзия шулай буладыр, дип уйласаң, мин алай ук надан кеше түгел бит инде. Экзистенциализм, диләр инде алар аны, фәлән-төгән, диләр. Нинди генә талантлы булсаң да, шигырь ул ничә мең ел элек формальлашкан һәм камилләшә барган. Син үз ритмыңны тотарга тиеш. Колагына аю баскан кеше музыка уйнарга өйрәнә алмый, аның композитор булып китүен күз алдына да китереп булмый. Хәер, хәзер нота белмәгәннәр дә көй чыгара, сүз тәмен тоймаганнар нидер яза...

– Бу – татар шигъриятенең киләчәгеме, әллә мавыгу гынамы?

– Андыйга китсә, киләчәк юк, дигән сүз инде. Аларның күбесе кызлар әле. Араларында бер-ике үсмер егет тә бар иде, алары кызларга караганда да аңлаешсыз. Ул кызлар кияүгә чыгып үз ояларын корыр, бала үстерер, бәлки, әдәбиятка мәхәббәтләре дә бардыр. Анысы да мөһим. Балаларына, бәлки, шул мәхәббәтне тапшыра алыр. Бала үстерү – хатын-кыз өчен иң зур вазыйфа бит. Артисткалар, хәтта шагыйрәләр арасында да, иҗатка бирелеп, кияүгә чыкмыйча калганнар бар. Нәтиҗәдә, шигырь дә калмый, бала да юк...

– Балалы кеше бәхетлеме, баласызымы – анысын белгән юк. 18 пункт буенча дәвам итәбез. Язучыларның иҗат кичәләрен зур залларда уздырырга кирәк, дигән идең. Синекен һәм Разил Вәлиевнекен Камал театры сәхнәсендә уздырдыгыз...

– Кеше әдәбиятта үз сүзен әйткән икән, аның юбилеен билгеләп үтәргә тырышабыз. Рифат Җамал, Марат Кәбиров, Ләис Зөлкарнәй, Илфак Ибраһимовның, Рабит Батулланың, мәрхүм Зөлфәтнең иҗат кичәләрен зур залларда уздырдык. Равил Фәйзуллин юбилее да Камалда булачак. Ринат Мөхәммәдиев, Тәлгат Галиуллинныкын Тинчуринда дип торабыз. Зал сораганда, язучыларның рәсми дәрәҗәләренә, дәүләт бүләкләренә дә карыйлар бит. Без андый рәсмилеккә артык игътибар итмәсәк тә, дәрәҗәле исемнәргә Мәдәният министрлыгы нык игътибар итә. Акчаны шуның аша алабыз. Фәлән-фәлән лауреаты дип саный башлыйлар... Югыйсә, язучының дәрәҗәсен медальләре түгел, исеме күрсәтә. Түрәләр шуңа игътибар иткәнгә күрә, язучылар төрле медальләр, премияләр алырга омтыла да инде.

– Син рәис булып килгәндә, яшьләрне Мәскәүгә, Әдәбият институтына җибәреп йөргән идең. Укыйлармы инде син керткән егетләр-кызлар?

– Өч кеше укый иде, ләкин шушы көннәрдә генә Рамазан Рәхимҗановны армиягә алдылар. Төркемгә 5-6 кеше җыярга дигәннәр иде, җыеп булмады. Кайсының урыс әдәбиятыннан баллы җитмәде, кайберсенең ата-анасы риза булмады.

– Баланы Мәскәүдә укыту бик җиңел түгелдер, әти-әнине дә аңларга була. Укыганнарына Татарстан матди яктан булышамы?

– Юк. Кузгатырга кирәк әле ул теманы. Аларның кураторы – Мәскәүдә Алия Кәримова бит. Ул аларны, сәләтле генә, ди. Язучы булмасалар, тәрҗемәче чыгарга мөмкин. Хәзергеләр бит Тукай белән Җәлилдән башка язучыларны да белми. «Безне укытмадылар», – ди дә вәссәлам! Татар әдәбиятын өйрәнмәгәннәр, русча укыганнар. Шундый аянычлы хәлдә без. Ике кеше генә аз, бик аз. Башкортлар, бурятлар зур төркем булып укый.

– Калын-калын романнар язса да, дәүләт булышмаса, татар язучысы тамагын туйдыра алмыйдыр ул.

– Стивен Кинг кебек язучылар Америкада да сирәк. Ә гомумән алганда, дәүләт булышмаса, әдәбиятчы бер илдә дә җан асрый алмый. Төркиядә, мәсәлән, грантлар күп. Язучыга да әдәби әсәр язып акча эшләү өчен китабыңны күпләп сатып алулары кирәк. Ә бездә күпме кеше татарча укый белә? Күпме кеше китап сатып ала? Әлбәттә, юллар бар. Мәсәлән, аяктан егарлык детектив язасың икән, ул тәрҗемәдә дә тарала ала. Ләкин кайда андый әсәр? Бүген бездә сәхнә әсәре язып кына тамак туйдырып була. Әгәр театр куйса. Ә болай бөтен дөньяда шулай – әдәби әсәрләр язган кешеләр гадәттә укыта, редакцияләрдә эшли, фәнни эш белән шөгыльләнә. Минемчә, бу да – табигый хәл. Иҗат бит ул – күңел таләбе. Аның өчен түләсәләр – әйбәт, түләмәсәләр дә язабыз. Чит илләрдә мөһаҗир хәлендәге Исхакыйлар кебек сагыну-сагыш кичереп яшәргә язмасын.

– Камал театрында «Көл»не карадыңмы?

– Карадым. Ошады.

– Чираттагы соравым: язучылар цензурадан интегәме?

– Безнең иң зур бәла: язучының үзендә цензура утыра – куркаклыкта бөтен хикмәт. Цензура, әлбәттә, бар. Мин сүз дә әйтмим: милләтара дуслыкны бозу, әхлаксызлыкны пропагандалау мәсьәләләрендә цензура кирәк... Сүз уңаеннан, «зәңгәр»ләрне пропагандалауга каршы закон турындагы документка кул куйдырдылар әле Дәүләт Советында.

Цензурага килгәндә, бар инде ул, әмма персональ цензорлар юк. Күптән түгел Рүзәл Мөхәммәтшин белән мине Камал театрының Сәнгать советына алдылар. Ул күпмедер цензура ролен дә үтәргә тиештер, бәлки. Без нинди цензорлар инде?!

Сүз дә юк, цензура ныгый барачак. Совет заманында бик әшәке иде ул. Күпләрне интектерде. Мин шәхсән аның зыянын күрергә өлгермәдем. 1984 елда чыккан беренче китабымнан гына ике юл шигырьне сызып ташлаганнар иде. Аны да редактор сызгандыр әле. Хәер, ул да шул ук цензор вазыйфаларын башкаручы иде. Чөнки минем актив иҗат чорым 90нчы елларга туры килде. Хәзер шул вакытта язганнарымны укысам, чәч үрә тора...

– Рәхәт вакытка эләгеп калгансың...

– Без – совет кешеләре – өйрәнгән бит: эзоп теленә күчәрбез. Совет чорында шулай яза идек, нәрсә әйтүеңне бөтен кеше белә, бәйләнеп тә булмый. Шигырьдә маңгайга бәреп әйтү – ул талантсызлык билгесе. Турыдан-туры маңгайга бәреп әйтелгән митинг шигырьләре дә бар миндә. Сәхнәдән укырга алар да кирәк. Әмма аларның шигъри кыйммәте юк дәрәҗәсендә. Шигырь метафораларга төренергә тиеш.

– Элек халык укымышлырак иде кебек. Хәзер халык маңгайга бәреп әйтмәсәң аңламый да башлады бугай. Ә син, эзоп теле, дисең...

– Халыкны шигырь аңларга өйрәтергә кирәк. Япониядә баланы кече яшьтән үк мәктәптә шигырь аңларга өйрәтәләр. Кытайда түрә булырга теләгәннәргә шигырь яздырып караганнар. Иранда хәзер дә парламентта шигырь белән сөйләшәләр икән, шаккатып кайткан иде берәү. Ул бит – сурәтле фикер йөртә белү билгесе! Хәзер бездә шигырь аңлаучылар сирәк. Башлангыч белемең булмаса, классик музыканы аңлап булмый бит, син аның кыйммәтен аңламыйсың, димәк, эстетик ләззәт тә алырга хәлеңнән килми, бер күзәнәкле җыр тыңлап канәгатьләнәсең.

– Союздагы бөтен язучы бертөрле уйларга тиешме?

– Язучының һәр вакыйгага үз мөстәкыйль фикере булырга тиеш. Ләкин аналитик акылга ия кешеләр язучылар арасында да сирәк.

– Сезне пропагандада куллану файдалы була аламы? Татар язучысын халык тыңлармы икән?

– Нишләп тыңламасын?! Сүзеңне җиткерә белсәң, тыңлыйлар. Очрашуларда еш чыгыш ясыйбыз. Шунысы да бар, татар язучысы глобаль вакыйгалар турында сөйләүгә яки язуга караганда, үз милли проблемаларыбыз турында гәпләшүне мәслихәтрәк күрә. Нишлисең, һәркемнең үз күлмәге үзенә якынрак. Үзеңнеке үзәктә булуы табигый. Менә соңгы халык санын алуда 600 мең милләттәшебез кимегән. Уйлап баксаң, бу бит – коточкыч! Һәм бернинди демографик законнарга сыймый. Сәбәбе нидә? Мондый тизлек белән кимесәк, безгә бит халык буларак якын киләчәктә юкка чыгу яный. Бу турыда оран салырга кирәкме?

Барыбызны да тыңлыйлар, дип әйтеп булмый, әлбәттә. Соңгы елларда Союзга «көтү-көтү» дисәм, итәгатьле булмас инде... «өер-өер» дисәм дә... күпләп кеше алдылар. Язучылар берлегенә керүне язучы булдым дип хаталанучылар бар. 55 тә берлеккә керә, 5 елдан юбилеен үткәрүне, премия бирүне таләп итә башлый. Андыйлар язучының дәрәҗәсен төшерә. Язучылар берлегенә кешене бик нык сайлап алырга кирәк: әдәби процесста да катнашсын, халык алдында чыгыш та ясый алсын. Берәр бәхәсле китап чыкса, рецензия язучы да юк бит хәзер. Әллә укымыйлар, әллә фикерләрен туплап яза белмиләр. Гаҗәп! Бәлки, мин артык таләпчәндер... Кырын караучылар күп, сизелә ул...

– Татарстан Язучылар берлеген Россия Язучылар союзына кушып кую мәсьәләсендә сезне тынычлыкта калдырдылармы инде?

– Былтыр Махачкалага – Язучылар берлегенең киңәйтелгән идарә утырышына кунак итеп чакырганнар иде. Шунда чыгыш ясаганда, Берлеккә Татарстан дәүләтенең ярдәме, грантлар турында сөйләдем дә, залдан берсе: «Возьми нас к себе!» – дип кычкырды. Шуннан соң Россия Язучылар берлегенә кушылу турында сүз булмады. Алар үзләре очын-очка ялгап тереклек итүчеләр бит. Разил Вәлиев әйтмешли, ике ярлының берләшүеннән беркем дә отмый. Без – «самодостаточный» милләт. Аннары, минемчә, без Россия Язучылар союзына бүтән иҗат берлекләре алдында мактану өчен генә кирәк. Янәсе, менә безгә татар язучылары да кушылды. Шуны да әйтәсем килә: кайсыдыр оешмага кушылу минем вәкаләткә керми, әлеге мәсьәләне язучыларның корылтае гына хәл итә ала. Ниһаять, Россия Язучылар берлегенең идарәсе өлешчә максатына ирешә: бездә үзләренең «Татарстанское отделение»ләрен ачтылар. Анда бик үк танылмаган 12 русча язучы бар бугай. Безнең берлектән анда Ренат Харис белән Ленар Шәех әгъза булып тора.

– Бүгенге вәзгыятькә беркемгә дә зыян китерми торган итеп бәя бирә аласыңмы?

– Төрле чорларны күрдек, мондыйны күргән юк иде әле.

Рузилә МӨХӘММӘТОВА,
intertat.tatar

МОСТАФА

Аяз ГЫЙЛӘҖЕВ

(Дәвамы. Башы 20 нче санда).

Дөрес, сурәттә Мостафаны аеру чамалы, астындагы язуын укып кына сурәт иясенең кем икәнен аерасың. Астына эре-эре хәрефләр белән: «Совет властен яклап Колчакка каршы сугышкан комсомол активы Мостафа Батыршин», – дип язганнар. Мостафа почтадан өч газит юнәтеп кайтып, чебен чуарлап төсен җуйган көзге артына кыстырды. Кыстырды да идән уртасына басып көзгедәге шәүләсенә озак кына багып торды. Торып-торып көзгене бозган дәүдәү тапларны җиң очы белән ышкырга тотынды. Авызы ачылды. «Көзгене яңартырга бик вакыт икән!» – дигән сүзләрен ишетеп, Халисә иренә гаҗәпсенеп һәм куркып карады.

Мостафа комсомол утырышларында авызына су кабып утырса да, аны күздән ычкындырмадылар, күрше Ишморза авылы кулакларын сөргәндә, «шаһит булырсың!» дип аны да чакырдылар. Таң яралып кына килә иде, караңгылык белән яктылык тартыша, һич ачылып китә алмый көн, көтүгә чыгарга ашыккан сыерлар мөгрәшә, кое чыгырлары әрнеп чыелдый, каядыр ашыккан аяк тавышлары ишетелеп куя. «Мин нишләрмен анда?», – дип сорады Мостафа Ишморзага җитәрәк. Күн төпле ыштан аны алырга кергән иде. «Караштырып тик тор, нык күзәт! Ул-бу сизелүгә мин ым кагармын!»

Ишморзадан җиде гаиләне читкә сөрәләр икән. Төркем-төркем кешеләр капка төпләрен саклый. Куылачак адәмнәрне авыл советы янына җыйганнар икән. Шактый ишле халык! Гаилә саен өч-дүрт бала. Бабайлар елашалар, олылар уйчан, моңсу күренсәләр дә, күзләреннән яшь чыкмады. Атларга төялеп маташкан кулакларны урап диярлек авыл активы, куштаннар, коммунистлар һәм этрәк-әләм ярлы-ябага баскан. Алар рәтеннән урын алгач кына, Мостафа үзенең ник чакырылуын аңлады, сак икән алар! Чуалыш чыкмасын, ыгы-зыгы башланмасын дип җыйганнар аларны! Мостафаның һичнәрсәгә исе китмәде. «Кулак икән – кан эчүче, кан эчүче һәр бәндә – гадел совет властеның дошманы!» дигән ышанычлы уй күңелен биләде.

Аның бер нәрсәгә генә исе китте: байтак ирләр китә, сандыклар, түшәкләр янына карт-корыны төягәннәр, хатын-кызлар ишле генә, ник берәвенең күзеннән чытып яшь чыксын! Киресенчә, үзара елмаеп-көлешеп сөйләшәләр, ярминкәгә баралармыни, бер-берсенә киңәш биреп гәпләшәләр. Шулай тын, иплә генә чыгып китте олаулар. Китүчеләр түгел, калучылар кайгыда иде шикелле. «Авылда калырга куркалармы?» – дип уйлады Мостафа.

Алып килгән ат белән аны авылына илтеп куйдылар. Кызыл күн төпле ыштан хуҗасы иптәш Муллин белән саубуллаша алмады Мостафа. Эзләп лапас астына керсә, районнан килгән кешеләр, вәкилләр дәшми-тынмый гына тарткалашып, нидер эшләп маташалар иде. Мостафаны эчкәрәк үткәрмәделәр, җилкәсеннән пар күтәрелгән милиционер аңа бер генә җикерде: «Кая, кая үрмәлисең? Чакыру бармы әллә?»

Ярты юлга җитәрәк, Мостафаның зиһене ачылып китте: «Тегеләр... мал бүлешеп ята бит! Китүчеләр таза тормышлы, хәлле кешеләр!.. Әз калмагандыр алардан мал!» Зиһене ачылды да теше сыкрады: «Эх, алдан хәстәрен күреп куясы калган. Коры кул белән кайтып барам!» – дип, юл буе сызлады күңеле. Өч көн үткәч, иптәш Муллин аңа бер бәләкәй төргәк акча калдырып үтте. Теге көнне өлешсез калган Мостафа шул кадәр рәнҗегән иде, акчаны санап тормады, күз кырые белән генә карады да сандык төбенә үк салып куйды. «Ятсын! Кирәге чыгар!»

Ясканып, комарланып көтсә дә, аны бүтән авылларга чакырмадылар. Элек тә ул авылдашлары белән аралашырга бик яратмый иде, хәзер, беркем аерып сүз әйтмәсә дә, күрше-тирәләр дә Мостафадан ерагайды. Якыннары, кардәшләре бәйрәм-сәйрәмнәрдә дә Мостафалар ихатасын читләтеп узды. Әтисе – эре сөякле, калак сөякләре калын бишмәт астыннан да калкып-шыраеп торган көмеш башлы карт улын күргәч, башын чайкый да читкә карап узып китәргә тырыша.

Кайнап торган комсомол җыелышларына барса да, иң арттагы рәткә, кеше күзеннән читкәрәк утырырга тырышты Мостафа. Кушсалар кулын күтәрде, кушсалар төшерде.

1933 елның көзендә иптәш Муллин тагын аларга килеп керде. Халисә кайдарланды, самоварга су тутырганда, чүмече кулыннан төшеп китте, үтмәс чыра пычагы белән кулын кисте. «Яхшылыкка йөрми бу бәндә, мөгаен, мине ирсез калдырырга маташадыр, мөртәт!» дип уйлады. Иптәш Муллин тирән чалбар кесәсеннән учы белән кәнфит сөйрәп чыгарды, чуклы, аллы-кызыллы кәгазьләрне өстәлгә сибеп җибәрде. Кәнфитләр күзне кыздырып яттылар, аларга кыеп үрелгән кул булмады. Дөрес уйлаган хатынның күңеле, хак сизенгән икән, атна үттеме, районнан кәгазь килеп төште, кәгазьдә Мостафага Казанга ук барырга кушылган иде. Хатыны ирен капкадан чыгармыйча, иңнәренә асылынып озак кына елады. Улы кая булса сәфәр чыкканда менеп җитә торган әткәсе бу юлы күренмәде, хатынны шул да шомландырды бугай. «Юләр, – диде Мостафа, иренен кыйгайтып, – укырга алалар!»

Ата-бабасының төшенә дә кермәгән НКВД мәктәбенә барып керде Мостафа, дәресләргә төгәл йөрде, кушканнарны җиренә җиткереп үтәде, башлыкларының авызына карап кына торды.

Аның иң яраткан дәресе тирга барып мылтык-наганнан ату иде. Мостафа гражданнар сугышында ук төз атуы белән иптәшләре арасында мәшһүр иде. Кулы нык, күзе үткен, «Казаннан торып япон императорының күзенә тидерә безнең Мостафа!» – дип мактыйлар хәзер командирлары. Тора-бара курсларның чемпионы булды Мостафа, бүләк итеп аңа кул сәгате тапшырдылар. Сәгать яңа түгел иде түгелен, мәгәр тек тә тек, дөпдөрес йөри!

Кичләрнең берсендә, дөм караңгысында, аны командиры Яков Петров кызыл почмакка чакырып кертте. Ука читле кызыл байрак янына бастырды, серле вә үтә тантаналы кыяфәт белән: «Курсант Батыршин! Сиңа чамадан тыш җаваплы бурыч йөкләнә! Күреп киләм һәм сиңа тулысынча ышанам: мин бу хакта беркайчан да, беркемгә дә сыңар сүз дә чыгарачак түгел! Илебез дошманнар чолганышында! Дошманнар безнең алга барышка таяк тыгарга тырышалар. Син бүгеннән илнең иң җаваплы яшерен эшләренә катнашасың. Мондый ышаныч белән горурлан! Бүгеннән син бөек Сталинның һәм партиянең какшамас солдаты!» – дип белдерде. Командиры күн папкасыннан бер бит кәгазь чыгарды һәм Мостафага укып кул куярга кушты. «Әйе, диелгән иде анда, миңа йөкләнгән җаваплы эшләрне намус белән үтәп чыгарга һәм кылган гамәлләрем хакында беркайда да, беркемгә дә сүз чыгармаска тантаналы төстә ант итәм».

Мостафа уйлап-уйлап торды, сул колак бөдеркәсен кашыды, малайларча борынын тартты һәм кәгазьдән ят, шикләнерлек мәгънә тапмады. Гадәтенчә, фамилиясен тулы итеп язып, хуплавын белдерде. «Батыршин «диясе урында «Бтршин» килеп чыккач, командир башын чайкады: «Синең каушаганны да күрәселәр бар икән», – диде ул, Мостафаның җанына хуҗа булып өлгергән кәгазьне күн букчасының кесәсенә шудырып. Мостафа кызарынды, аңа кыен булып калды.

Төнге унберләрдә йокымсырап әллемәлле яткан Мостафаны алып чыгып киттеләр. Черек күл ишегалдында каушап-калтырап утырган автомашина әрҗәсендә куллары бәйләнгән ике кеше яткан, аларның баш очына баскан Мостафаның взводдашы аңа өскәрәк менәргә булышты. Шофер янына Яков Петров утырды, катлы-катлы капкалар ачылып ябылды, машина тәмсез исләр калдырып тын урамнардан тиз-тиз тәгәрәде.

Командир бер нәрсә аңлатмады, төшендермәде, кая баралар икән алар? Бу адәм актыкларын кая алып баралар?.. Аларның адәм актыгы булуы хакында Мостафа бер тамчы да шикләнми иде.

Әрҗә төбендә ятучылар туңа башлады, ахрысы, кыймылдыйлар, баш калкытырга маташалар. Шәһәрнең бу шыксыз якларына чыкканы юк бугай Мостафаның. Алар шәһәрнең сүрән яктысыннан чыгып тәбәшәк, кыеш-мыеш өйләрне йоткан караңгылыкка керделәр. Машина күзе коймаларны, бикле капкаларны, юл чокыр-чакырларын капшый-капшый мырлап туктаусыз бара да бара.

Шыксыз, шәфкатьсез караңгы төн. Кар бөртекләре уйнаган җилләрдән куркып, тау-тау кара болытлар артына поскан ай бер мәлгә генә йөзен ачып дөньяга бакты, ызан-ызан юка кар яткан кырларны җансыз, суык нурга манды. Машина сөрлегеп тукталды, суыксынгандай бер-ике мәртәбә калтыранды да тынды. «Ачыгыз бортны!» диде җитез генә кабинадан чыгып җиргә төшкән командир. Ачык борттан кулы бәйләнгәннәр аска сөйрәделәр. Утлары саран гына җемелдәгән машина чокыр алдына барып туктаган икән. «Дошманнарны шунда бастырыгыз!» дип пышылдады командир, чокыр кырыен күрсәтеп. Бәйләүлеләр, үзләре үк күрсәтелгән төшкә барып бастылар.

Сүрән яктыда да аларның күгәргән күз төпләре, канап кутырлаган иреннәре аермачык күренде. Ул арада командирның пышылдаганын ишетеп алар баскан урыннарында чайкалып киттеләр, куллары бәйдә булса да, телләре иректә бит: «Балалар кала, балалар! Дүртәү бит, дүртәү!» – дип иңрәде озыны. Озынга төртеп, командир Мостафага боерды: «Монысын син аласың!» Кая, ник баруларын Мостафа юлда ук шәйләгән иде. Хәзер, төбе күренмәгән кап-кара чокыр авызында, тик кенә басып торыр хәлләре дә калмаган берсе озын, икенчесе кыска шәүләләрнең гомер юлларын кисү алдыннан, аның гәүдәсенә күтәрә алмаслык авырлык ишелде. Командирга нидер аңлатмак булды, вакыт җитмәде, «Пли!» дигән боерык яңгырады. Бармак тәтегә басты, мылтык көпшәсеннән ут бөркелде, Мостафа күзен ачып караганда, балчык таучыгы сыртында шәүләләр юк иде инде. Командир кул фонаре тотып, чокырны бер урады, ике, аска иелеп-иелеп карады да кулындагы наганнан атып та җибәрде. Чокыр эченнән «аһ!» дигән үзәк өзгеч тавыш ишетелде. Теге озыны, дүрт бала атасы татар кычкырды, ахрысы.

Мостафаның каушавы әзгә генә булган икән, кулына көрәк тотып кереп чокырны җәһәт-җәһәт күмә башлагач, ул тынычланды, чокырны җир белән тигезләгәнче калкынып та карамады. Ай китеге аларның дымлы җилкәләрен бер яктыртты да югалды.

Кайтуга, бер кайда тукталып тормыйча, подвалга төштеләр, командирның нык, ышанычлы адымнарына карап, аның бу баскычлардан бер генә үтмәгәне күренеп тора иде. Уңда, сулда суык ишекләр калды, алар тавыш чыгармаска тырышып, актыкка ишеккә кадәр бардылар. Ишек сискәндереп, тавышланып ачылды, керделәр, эчтә берәү дә юк иде. Уртада өстәл, өстәл тирәли урындыклар тезелгән, бер кырыйда яшелгә буялган шкаф утыра, пыялалы ишекләре аша кашык-калаклар, чәнечке-пычаклар таралып ятканы күренә. Түбәнге тартмада шешәләр дә, бер төрле чәркәләр дә бар икән. Утырмадылар, өстәл тирәли таралып бастылар. Командир тамагын кыра-кыра, күнегелгән җитез хәрәкәтләр белән, тамчысын да исраф итмичә, киң авызларын ачып, адәм улларына текәлгән комсыз чәркәләргә аракы койды, чәркәсен күз турына күтәреп, пыяла аша йөзләре бозылган хезмәттәшләренә карап, Мостафага эндәште.

(Дәвамы киләсе санда.)

Качу, яшеренү йоласы

Нурихан ФӘТТАХ



Өйләнешүгә кагылышлы йолалардан качу, яшеренү йоласы аеруча әһәмияткә ия. Бу йоланың эчтәлеге шуннан гыйбарәт: кыз, кияү өенә килен булып төшкәч, иренең ата-анасы белән сөйләшми һәм аларга ничек тә күренмәскә тырыша. Кияү дә кызның ата-анасы, туганнары белән сөйләшмәскә, алар белән күзгә-күз очрашмаска тырыша. Кайбер халыкларда хәтта яшь ир белән яшь хатын да баштарак бер-берсеннән качып, яшеренеп яши. Мондый качу, яшеренүләр билгеле бер вакытка кадәр дәвам итәргә, ләкин кайберәүләр өчен гомер буена сакланырга мөмкин.

Татарларда килен үзенең кайнатасына һәм иренең өлкән ир туганнарына күренмәскә тырыша. Кияү шулай ук кызның туганнары белән, бигрәк тә әбисе (хатынының әнисе) белән аралашмый.

Башкортларда кияү белән кәләшкә туйдан соң аерым өй бирелә. Кияү үзенең хатыны янына килеп йөри. Бу вакытта хатын үзенең иренә йөзен күрсәтмәскә тиеш. Кияү үзенең кайнанасына, кайнатасына да күренми. Кәләш, кияү йортына күченеп килгәч, башка ирләргә йөзен күрсәтми, алар белән бергә утырып ашамый.

Алтайларда килен үзенең кайнатасына яланбаш, ялан аяк күренмәскә тырыша, аның белән кул биреп исәнләшми.

Балкарларда, калмыкларда, бурятларда, тываларда шундый ук гадәт саклана, алар бала тугач кына битләрен ача, үзләреннән өлкәннәр белән сөйләшә башлый.

Мордваларда туй вакытында кияү бернигә катнашмый. Кыз өендә ул, башына бүрек киеп, өстәл янында утыра, ләкин ашамый, эчми, сөйләшми. Кайбер җирдә кияү туй вакытында яшеренеп тора. Килен дә өлкәннәр янына утырып ашамый. Беренче баласы тугач кына, башкалар кебек өстәл янына утырып ашый башлый.

Кабардаларда, чеченнарда һәм черкесларда кияү дә, кәләш тә бик озак вакыт дусларында яисә махсус өйдә качып яши. Гомере буена ир кеше үзенең хатыны янына бары төнлә генә килә ала, хатын үзенең ире белән бергә ашамый, ире югында, ул кайтмыйча йокларга ятмый. Бер-берсенә алар исемнәре белән эндәшми.

КАЧУ-ЯШЕРЕНҮНЕҢ МӘГЪНӘСЕ

Менә шундый качу-яшеренү сәбәпләрен этнографлар төрлечә аңлата:

1. Кияү кызны урлый, ягъни кызның атасына-анасына карата дошманлык күрсәтә; өйләнешкәч, кыз ягы белән кияү арасында дошманлык саклана.

2. Яшь хатын белән ирнең атасы һәм ир туганнары арасында, шулай ук кияү белән әби һәм бикәчләр, балдызлар арасында рөхсәт ителмәгән җенси мөнәсәбәтләр барлыкка килмәсен өчен, имеш, һәртөрле тыюлар уйлап табылган.

3. Яшь хатын да, яшь кияү дә, чит гаиләгә килеп кергәч, яңа кешеләргә тиз генә үзләшеп китә алмый. Яңа гаиләдә аларны үз итеп танымыйлар. Шунлыктан, аларның үз кеше түгел икәнлеген сиздерү өчен, имеш, төрлечә качу, яшеренү гадәтләре барлыкка килгән.

Н.А.Кисляков әлеге карашларны тәнкыйть итә һәм качу, яшеренү йоласын үзенчә аңлата. Аныңча, өйләнешкән кешеләр табигый рәвештә тартыну, уңайсызлану кичерә. Алар үзләренең яңа тормышларына һәм шулай ук яңа кешеләргә ияләшеп, күнегеп җитмәгән. Шунлыктан, имеш, менә шундый качу-яшеренүләр уйлап тапканнар.

Бу аңлатмаларның берсе дә ышандырмый. Бүген этнографларга тиешенчә аңлашылмаган әлеге сәер йолаларны, гадәтләрне бары тик кешенең бик борынгы карашлары нигезендә генә аңлатырга мөмкин. Борынгы карашларның нидән гыйбарәт икәнлеген без инде беләбез: әйтелгәнчә, хатын – ашаучы, ир – үтерүче. Димәк, өйләнешкән яшьләрнең һәр икесе беренче җенси мөнәсәбәттән соң ук «үлә» яисә үлгәнгә санала. Менә шуңа күрә дә алар беркем белән дә сөйләшми, аралашмый. Алар хәтта бер-берсеннән качып яши. Шуңа күрә дә алар башларын, чәчләрен, битләрен, аякларын тере кешеләргә күрсәтмәскә тырыша. Мәет, үле кеше, белүебезчә, явыз рухка әйләнә һәм аннан ничек тә ераграк булганың яхшы.

Кияүгә баруның үлемгә бару булып аңлашылганлыгын елату йоласы белән дә исбатлап була. Төрки халыклардан казах, кыргыз, үзбәкләрдә һәм шулай ук татарларда кыз елату йоласы сакланып калган. Татарлар яшәгән җирләрдә моны «кыз чеңләтү», «таң кучат», «сыктау», «яслату», «әтеки әйттерү» дип атыйлар. Икенче бер чыганакта «җылау» сүзе «җырлау» дип бирелгән. Әҗәл татар телендә үлем (смерть, кончина) дигәнне белдерә. Кияүгә барасы кызның әҗәлгә бару белән чагыштырылуы тикмәгә түгел, әлбәттә. Кияүгә барасы кыз «ят якка», «ят кулларга» китә, анда аны «кара төннәр» көтә, шуңа күрә дә ул үзенең кияүгә баруына сөенми – кайгырып елый.

Славян халыклары фольклорында да «кияүгә бару – үлемгә бару» мотивы киң урын ала. Халык җырларында кызның кияүгә баруы үлем белән тиңләштерелә. Кияү ягы һәрвакыт чит як, явыз як итеп тасвирлана.

Җенси мөнәсәбәт вакытында ир белән хатын бер-берсен үтерә дигән караш кайбер бүтән гореф-гадәтләрдә дә чагыла. Ассирия кешеләре турында Страбон: «Аларда мәеткә кагылганнан соң юынган кебек, җенси мөнәсәбәттән соң да юыну гадәте бар», – ди. Үзара якынлык кылган ир белән хатын, шулай итеп, мәеткә тиңләштерелә. Билгеле булганча, татарда мәетне юалар. Бу йола гадәттә мөселман дине тәэсире буларак аңлашыла. Ләкин моның мөселман диненә бернинди катнашы юк. Мәетне юу йоласы татарларның борынгы бабаларында мөселман дине кабул ителгәнче үк булган. Шушы уңайдан без башка төрле фактларны да искә төшерәбез.

Татарда кияү белән кыз өчен беренче төннән соң иртән иртүк, кеше аягы кузгалганчы, мунча ягалар. Яшь ир белән яшь хатын мунча кереп, чәй эчә. Яшьләр өчен ягылган иртәнге мунчаның үз мәгънәсе бар: якынлык кылганнан соң алар «үлә», ләкин Су (мифик ата) аларны яңадан терелтә һәм яңа көч-куәт бирә. Монда шуны да теркәп узыйк: кешенең гомумән су керү, коену, мунча керү кебек гореф-гадәтләре мифик Суның илаһи көченә, аның яңадан терелтү һәм савыктыру сәләтенә ышану нигезендә барлыкка килгән булырга тиеш.

Инде бала турында да бер-ике сүз әйтеп китик. Бала туу ул ата белән ананың үлемен раслый. Бала тугач, атаның да, ананың да нинди дер тордәге җаны балага күчә һәм ата белән ананың табигате үзгәрә. Без моны чын мәгънәсендәге (физик) үлү димибез. Хәер, борынгы кеше өчен физик үлем юк нәрсә ул. Ләкин, ни генә булмасын, борынгы карашлар буенча, бала туу белән, ата да, ана да үлә. Моннан соң хатын-кыз – фәлән баланың анасы, ир-ат – фәлән баланың атасы дип атала башлый. Исемгә карата мондый караш күп халыкларга мәгълүм. Татарларда ир белән хатын гомер буена бер-берсенә «син» дип эндәшкән һәм беркайчан диярлек бер-берсен исемнәре белән атамаган. Шундый ук гадәт борынгы заманнарда әрмәннәрдә дә булган. Ир кеше үзенең хатынына «ахчи» (кыз) дип, яисә «әй» дип кенә эндәшкән, хатын да үз иренә «мард» (кеше) дип эндәшкән.

Шулай итеп, бала туу белән атаның да, ананың да исемнәре үлгән һәм һәрбер үлене яңадан кузгату тыелган кебек үк, үлгән исемнәрне дә телгә алу тыелган.

Бер йортның язмышы

Олы Мәңгәр – электән байлар авылы саналган. Сөйләүләренә караганда, инкыйлабка кадәр монда икешәр катлы мәһабәт йортлар гына да 14 кә җиткән, алар барысы да хәлле сәүдәгәрләрнеке булган. Ут уйнатып сәүдә иткәннәр, чит илләрдән кәрван-кәрван мал ташыганнар… Хәзер шул шанлы чорларның хатирәсе булып, бай йортларының нибары берсе утырып калган, ул да булса бик кызганыч бер халәттә, ярымҗимерек. Республика дәрәҗәсендә әһәмияткә ия архитектура һәйкәле дип танылса да, дәүләт тарафыннан саклана дип саналса да, 19 йөздә салынган әлеге бина көннән-көн җимерелә, туза гына бара… Вәлиулла сәүдәгәр Бакиров утарында бу йорттан тыш, хезмәтчеләр йорты, мәчет, хуҗалык келәтләре, ясалма күл, бакча да булган. Ул чактагы җитешлек, матурлыкны хәтерләтеп, хәзер бары күле генә ялтырап ята. Анда исә кайчандыр балалар тавышыннан, зур гаиләнең бәрәкәтле тормышыннан гөр килеп торган, хәзер исә хәсрәтле иске йортның тонык шәүләсе генә чагыла. Инкыйлабтан соң әлеге йорт бинасы склад булып торган, сугыш вакытында анда Балтик буе илләреннән эвакуацияләнгән балалар яшәгән, укыган. Ә хәзер бина ятим. Аңа кыйммәтле реставрация ясау таләп ителә. Йортның тышкы ягы да тузган, ә эчке интерьеры бөтенләй сакланмаган… Кайчан бу тарихи бинага төзекләндерү чираты җитәр – Әтнәдә бу хакта беркем дә белми. Гомумән, үзенә чират җиткәнне көтеп җиткерә алырмы икән бу йорт, әллә башкалары кебек үк тарих тузанына әверелерме?..

Эльмира СИРАҖИ.
Автор фотосы

● Сарт-Нәүрүз авылы менә шушы күрсәткеч тактадан башлана.

● Сарт-Нәүрүз авылындагы яңа мәчет.

Кырмыскалы районындагы Актаныш авыллары

Татарстандагы Актаныш районы татарларының, чәчүлек җир җитмәгәнлектән, XVI-XVII гасырларда ук хәзерге Башкортстан җирләренә күченеп китүе һәм анда яңа авыллар нигезләве турында бик күп яздык инде. Татарстаннан күчкән авылларны эзләп, соңгы бер ел дәвамында гына да Башкортстанның Ярмәкәй, Зианчура, Күгәрчен, Нуриман, Иглин, Яңавыл, Балтач, Кушнаренко, Бүздәк, Әлшәй районнарына сәяхәт кылынды, аларда Исламбакты, Кызылъяр, Байкилде, Бикморза, Теңкәш, Шиде, Күгәрчен, Кормаш, Торынтаеш, Чуракай, Иске Эсләк, Богады, Байсар, Карт... авыллары нигезләнгән булуын ачыкладык, ул хактагы язмаларыбыз да дөнья күрде. Ләкин Татарстаннан элеккеге Уфа провинциясе җирләренә күченеп утырган татар авыллары санап бетергесез, тарихтагы ак таплар беленми калмасын дип, кабат-кабат ут күршеләребез мәйданына сәяхәт кылырга мәҗбүрбез.

● Сарт-Нәүрүз авылы уртасындагы һәйкәл-обелиск.

Май уртасында «Татар-информ» агентлыгы хезмәткәре Рифат Каюмов белән янә юлга чыктык. Максатыбыз ачык – Кырмыскалы районындагы Сарт-Нәүрүз һәм Сарт-Чишмә авылларын барып күрү. Алардан тыш, Иглин белән Благовещенск районнарында да Актаныш кешеләре барып төпләнгән Турбаслы атлы өч авыл бар.

Аңлатманы «сарт» сүзеннән башламыйча булмас. Гап-гади итеп әйткәндә, үзбәкләр җиреннән, Бохара каласыннан килгән кәрванчыларга, сәүдәгәрләргә бәйле рәвештә туган атама бу. Ягъни үзбәк вәкилләре килеп, тәүге нигезләрне корган авыл. Башкортстанда бу рәвешле «Сарт» исемен йөрткән авыллар – дүртәү. Сарт-Нәүрүз белән Сарт-Чишмәдән тыш, Иглин районында Сарт-Ләбәү һәм Инзер елгасы буенда тагын Сарт-Хәсән бар. Уфа белән Оренбург арасындагы Сарт-Нәүрүз авылы XVIII гасырның беренче яртысында Сарт волосте булып та йөргән, соңыннан ул олыс исемени сәбәптәндер Чиләбе өлкәсе чигенә, Инзер елгасы буена «күчеп киткән». Ә гасыр башында әлеге авыл урыны әүвәл Табын волосте җирләре булып исәпләнгән, XIX гасырда Кара-Табын олысына әверелгән.

Кырмыскалы районындагы Сарт-Нәүрүз авылының тарихы Иглин районындагы Сарт-Ләбәү авылының дәвамы шикеллерәк. Нәүрүз авылына таҗик-үзбәкләр Ләбәү авылыннан күчкән, ә Иглин районындагы Кара Шиде елгасы буена алар XVI гасыр азагында, Уфа крепосте төзелә башлагач та килгән. Килмешәк таҗик-үзбәкләр Шәйбанилар идарә иткән Урта Азиядә гомер иткәнгә күрә, аларны Себер ханы Күчем белән уртак тел табуда һәм бер үк вакытта Уфа крепостен төзүдә дә файдаланганнар. Бүгенге Иглин районының Шиде елгасы буендагы биләмәләр таҗик Арслан Юмашев исемендә булган. Ләбәү авылы белән янәшәдә генә Иске Шиде авылы да урнашкан. Ул Шидегә һәм хәзер район үзәгенә әверелгән Кызылъяр авылына 1760 елларда ук Актаныш районының Җизмыек, Иске Җияш, Аеш, Шәбез, Исәнсеф, Түке, Усы... авылларыннан «башкорт» вә типтәрләр күчеп утырган, ягъни ләбәүлеләр белән Шидегә күчкән актанышлылар әле шул чакта ук уртак тел табып өлгергән. Ә 1796 елда ул Кара Шиде елгасы буендагы биләмәне Арслан Юмашев секунд-майор Е.Иглина атлы алпавыт хатынга саткан. Тик аңа кадәр бер гасыр алда ук Ләбәүдә яшәүче сарт-таҗиклар Агыйдел елгасы буена күченеп, Сарт-Нәүрүз авылын да нигезләп өлгергән.

Кырмыскалы районындагы Сарт-Нәүрүз авылы тарихи документларда беренче тапкыр 1712 елда искә алына. Ул елның 29 августында Табын олысында гомер итүче башкорт Күчек-Көек Савельев (Сәвәләев) Сарт авылында яшәүче таҗик Сабанкол Ишмәмәтев кулыннан әсирлеккә төшкән калмык Бахунны 20 тәңкәгә сатып алган. Ә 1741 елгы икенче документта инде Нәүрүз исеме алган авылда таҗик Нәүрүз һәм аның улы Туманчының Каршин волосте старшинасы Шәрип Мораков кулыннан нәкъ 20 шәр тәңкәгә ике алаша сатып алуы турында бәян ителә. 1748 елгы документта Нәүрүз авылында бердәнбер хуҗалыкта Малыт Булатов атлы 70 яшьлек карт һәм ул тәрбиягә алган Бирдебай Әбдигиев (26 яшьтә) белән аның энесе, 11 яшьлек Баян гына яшәп ятуы билгеле.

Безнең өчен иң гаҗәбе – Нәүрүз авылында 1712 елда да, 1741 елда да ике таҗик кешесе яшәгән, димәк, авылны да шулар нигезләгән. Документ төзүчеләр үзбәкне таҗиктан аерып маташмаган, ахры, әмма авыл тора-бара «Сарт-Нәүрүз» булып киткән. Сарт-Чишмә авылында гомер иткән төбәкче Хөрмәтулла Габдерәфыйков язуынча, Сарт-Нәүрүзне XVII-XVIII гасырлар чигендә сарт-үзбәк вәкиле Нәүрүз атлы кеше нигезләгән булган («Агыйдел» журналы, 2010 ел, 2 нче сан). Ә документларга, менә, шул ук Нәүрүз таҗик булып кергән.

Берникадәр алга китеп өстик: Иглин районындагы Турбаслы авылын да Кавказ ягыннан килгән карачай-балкар вәкилләре нигезләгән икән. Алар бу якка шактый гына күпсанлы куй са-

Мосафир сәфәрдән кайтты

рыклары көтүен куып килгән, эреле-ваклы калкулыклар арасына җәелгән даланы ошатып алганнар да икенче елда инде йортлар корып, авылга да нигез салганнар. Инзер елгасы буенда калыккан Сарт-Хәсән авылына да 1717 елда Арык Иманаев атлы таҗик нигез салган. Элекке Уфа провинциясендә калмыклар килеп нигез корган авыллар да байтак. «Башкорт» җирендә мондый авылларның күбәеп китүе 1768 елда Екатерина – Әби патша төзегән Уложение комиссиясенә депутат булып сайланган Туктамыш Ишбулатов белән Базаргол Юнаевның күңелләренә бик нык үткән бугай, алар үз тәкъдимнәрендә: «Башкортлар арасында гасыр башыннан бирле яшәүче сартлар белән калмыклар да байтак. Алар безнең җиргә электән үк йә үз теләкләре белән, йә әсирлеккә эләгеп килгән, мөселманга әверелгән, аерма юкка чыккан. Шуңа күрә без килмешәк сарт белән калмыкларны да башкорт дип исәпләвегезне үтенәбез», – дип язарга онытмаган. Элек Актаныш районы урынындагы Гәрәй волостенда яшәп, соңрак Кушнаренко районына күченгән Гәрәйбаш авылында гомер итүче удмуртлар да 1855 елдан бирле «башкорт» булып санала башлаган, хәзер дә алар җанисәпкә «башкорт» булып керә. Кем Башкортстан җиренә килеп эләгә, димәк, иртәгә үк «башкорт»ка әверелә. Менә аңлашылды...

1795 елда үткәрелгән 5 нче ревизия мәгълүматлары буенча, Сарт-Нәүрүз авылындагы 30 хуҗалыкта 80 ир-ат һәм 72 хатын-кыз яши. 1860 елда авылга инде 5 ел элек тоташы белән «башкорт»ка әверелгән «өйдәшләр» килеп керә. Барысы да – бүгенге Актаныш һәм Илеш җирләрендә урнашкан Бүләр белән Кыргыз волостеннан. Тыңламас авылыннан – 46 «башкорт», 78 типтәр һәм 10 «мишәр». Төкәй авылыннан – 85, Усыдан 46 типтәр. Качкын авылыннан – 3 гаилә «башкорт», Илтимердән – 8 гаилә, Яңа Әлемнән 49 типтәр, Түке авылыннан 88 кеше. 1870 елда Сарт-Нәүрүздәге 93 йортта яшәүчеләр саны 310 ир-ат белән 273 хатын-кызга җитә. 1920 елда 198 йортта 409 ир-ат һәм 470 хатын-кыз яши.

Шул ук Агыйдел буенда, бер-берсеннән 3-4 чакрым арада Сарт-Чишмә авылы да пәйда була. Ул XVIII гасыр ахырында Сарт-Нәүрүздән аерылып чыга. Бүгенге авылның кайбер урамнары Октябрьская яки Мәҗит Гафури исемнәрен алса да, халык телендә алар Илтимер, Түке һәм Усы аты белән йөри. Димәк, Актаныштагы Илтимер, Түке, Усы авылларыннан килгәннәр, Нәүрүздән аерылып, Сарт-Чишмәгә күченә һәм һәр авыл кешеләре аерым урам төзеп урнаша, шул сәбәпле элекке авыл исемнәре хәзер урамнарга беркеп кала. 1795 елда Сарт-Чишмәдәге 20 йортта 54 «башкорт» белән 11 типтәр гомер иткән булса, күчмәннәр ярдәме белән 85 йортта яшәүче халык саны 1870 елда 478 кешегә, ә 1920 елда 952 кешегә (191 йорт) җитә.

Сүз дә юк, янәшәдәге ике авыл Бөек Ватан сугышына кадәр туганнардай бер-берсенә берегеп һәм ярдәмләшеп яши. Әмма 1941 елда ике авыл уртасына Украина җиреннән эвакуацияләнгән шикәр заводын китереп утырталар. Хәрби корал җитештерү цехлары түгел, аны кабат аякка бастыру һәм эшләтеп җибәрү 1950 елга тикле дәвам итә. Ләкин цехлар һәм җиһазлардан тыш, аларга «ияреп» күчкән украин һәм урыс вәкилләре дә бар бит. Алар өчен силикат кирпечләрдән тиз арада ике катлы йортлар үсеп чыга. Заводны да хәзер инде «Карламан шикәр һәм консервланган сөт комбинаты» итеп үзгәртәләр. Читтән урыс белгечләрен күчерү дәвам итә һәм ике Сарт авылы арасында Прибельский бистәсе үсеп чыга. Хәтта 1970 елларда да Сарт-Нәүрүздә 640 бала укыган татар мәктәбе эшләп килсә, 1980 елда аны «бина искерде», дигән сылтау белән шапылдатып ябып куялар. Яңа, әмма хәзер инде өлкән туганныкы булган урта мәктәп Прибельский бистәсендә ачыла. Нәүрүз белән Чишмә авылларында үсүче татар балалары хәзер фәкать рус мәктәбендә генә укырга мәҗбүр ителгән, чәй шикелле гел яңартып торуга күнектерелгән Төп Канун таләпләре күптән онытылган...

Ике мөселман авылының бугазына басып урнашкан Прибельскийда бүген 5500 чамасы урыс белән украин гомер итә. Ләкин хәлләре көнләшерлек түгел, 15 еллар чамасы элегрәк шикәр-консерв комбинаты да яшәүдән туктаган, аның җиһазларын, машина-тракторларын читкә таратканнар, хәтта машиналар паркына кадәр сүтеп бетергәннәр. Халыкның бер өлеше Уфа каласына, икенчеләре вахта ысулы белән Себергә йөреп эшли...

Ә табигать матур. Ике Сарт авылы да Агыйдел ярына терәлеп диярлек урнашкан, җитмәсә шушы тирәдә генә Агыйделгә Җилем елгасы да килеп кушыла икән. 15-20 чакрымдагы Җилем-Каран авылы – бөек Мәҗит Гафури ватаны бит. Бертуган апасы Сарт-Нәүрүзгә килен булып төшкән. Шул апасын күрергә дип, яшьрәк вакытта Нәүрүзгә М.Гафури үзе дә килеп йөргән. Утыз еллар чамасы элегрәк, Сарт авылларының яшьләрен дәртләндереп, Агыйдел буенча аска-өскә пароходлар да ут яндырып, музыкалар уйнатып узган әле, ләкин хакимият алышынды бит, һәр кич саен мәмләкәтләр өстен караңгылык, билгесезлек, өметсезлек сара...

Сарт халыклары барыбер дә дәртле, һич бирешми. Нәүрүз авылы уртасында мәрхүм авылдашлары истәлегенә куелган һәйкәл-обелискларын күреп хәйран калдык. 1757 елда Пруссиягә каршы яуларда катнашкан авылдашлары исемлегеннән башланып киткән, аңа 1812 елда Наполеонга каршы яуларда, 1904 елда – рус-япон, 1914 елгы Беренче бөтендөнья, 1918-1920 еллардагы Гражданнар, 1941 елда башланган Бөек Ватан сугышында катнашучыларның, һәлак булганнар һәм хәбәрсез югалганнарның, 1930 еллардагы репрессия корбаннарының тулы исемлекләре аерым-аерым рәвештә тезелгән. Мондый хәтер дәфтәре, мондый истәлек беркайда юк!..

● Сарт-Чишмә авылындагы мәчет.

Һәм шуның белән янәшәдә үк матур рәшәткәләр эченә алынган Тукай скверы! Шушы җәйдә үк Тукай һәйкәлен бастырып куярга җыеналар, пьедестал урыны әзер, һәйкәлгә дә заказ бирелгән. Башкортстан мәйданында гына түгел, хәтта Татарстанның гап-гади авылларында да бер Тукай скверын да күргәнебез юк. Яши белә, кадер белә икән сартлылар!..

Өстәргә мәҗбүрбез: Актаныштан Кырмыскалы җирләренә халык агылу 1860 еллар тирәсендә дә дәвам итә. 1855 елгы указ нигезендә элек «Башкорт» гаскәре составында булган барча татар, типтәр һәм мишәрләрне дә тулысынча «башкорт» катламына күчереп бетерәләр. Ә бу катламдагы һәрбер ир-атка 40 ар дисәтинәгә кадәр имана җире бирелергә тиеш. Бүгенге Актаныш районы мәйданында 40 ар түгел, хәтта 15 әр дисәтинә итеп өләшү өчен дә җир җитми. Шуңа Оренбургның хәрби губернаторы фәрманы белән, «Башкорт» гаскәренә элеккечә үк хезмәт күрсәтергә атлыгучы гаиләләр Уфа каласы тирәсендәге 25 нче кантон җирләренә күчереп утыртыла. Менә шушы фәрман буенча, 1861 елда Актаныштагы Югары Уръяды авылыннан 67 ир-ат һәм 69 хатын-кыз Кырмыскалы районының типтәрләрдән хасил Иске Шәрәй авылына күчеп килә. Аларга ияреп, Түбән Уръяды авылындагы 7 ир-ат һәм 3 хатын-кыз, шулай ук Буранчы авылыннан – бер, Адайдан 5 гаилә – Шәрәйгә, ә адайлы Хисмәтулла Габделҗәлилов гаиләсе Сарт-Нәүрүзгә күчә. Шул ук җир кытлыгы аркасында Шәбез авылыннан ике гаилә – Нуриман районының Кызылъяр, ә бүген Минзәлә районында саналучы Бикбаудан 12 ир-ат һәм 13 хатын-кыз Кече Шиде авылына күчеп төпләнә. Менә шушы рәвешчә саный башлагач, Башкортстанда бүген ни сәбәпле татарларның күбрәк яшәвенә гаҗәпләнәсе дә калмый.

Вахит ИМАМОВ.
Автор фотолары.



● Сарт-Чишмә күршесендәге Яңа Кыешкы авылында гомер итүче татар язучысы Риф Йөзлекбай белән.

● Сарт-Нәүрүз һәм Сарт–Чишмә авылларында безгә юл күрсәтеп йөргән Наил агай гаиләсендә.

● Күгәрчен авылының яңа мәчете.

● Күгәрчендәге «Шәфыйка» мәдрәсәсе.

БЕЗДӘН КҮЧКӘН

Балык Бистәсе районындагы Күгәрчен авылы тарихта XIV гасырдан бирле таныш. Атаклы галимебез Равил Фәхретдинов 1968 елда шушы авыл җирлегендә археологик эзләнүләр үткәргән чакта, аксакал Әгъзәм Гыйниятуллин аңа үз нәсел шәҗәрәсенең башы 1367 елга барып тоташуы турында әйтеп шаккатыра. Ә 1998 елда авылда Илгиз Гыймадиевлар яшәгән нигездән ике яклы мәрмәр мөһер дә килеп чыга. Мөһергә гарәп имлясында: «Болгар дәүләте. Мулла Мөхәммәд. 1382. Сибгатулла Котдус мулла», – дигән сүзләр чокып язылган. Мөһер авыл музеенда бик кадерләп саклана, тик әлегәчә галимнәр тарафыннан ныклап өйрәнелмәгән.

Күгәрченнең бик борынгы булуына болай да шик юк. Аны Мамадыш районының Ишки авылыннан килгән күчмәннәр нигезләгән, дип санала. Ә Күгәрчен ирләре Казан ханлыгы нигезләнгән 1438 елга кадәр үк Чаллы, Алабуга һәм Казан әмирлекләре арасында барган яуларда катнашкан. Ул яулар, мөгаен дә, 1361-1380 еллар аралыгында Алтын Урда тәхетендә 25 хан алышынган башбаштаклык чорында аеруча көчәйгәндер. Күгәрчендә XIX гасыр азагында мулла вә мөдәррис саналган Мөхәммәтҗан Зәетовның, шул ук вакытта Каюм Насыйри белән бергә Казан университеты каршындагы «Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте»ндә әгъза булып, күршедәге Шомбыт волостеның (Тәберде)-Чаллысы авылы урынында торган шәһәрчек нигезендә казу эшләре алып баруы, нәтиҗәләренең «Җәмгыять хәбәрләре»ндә 1882 елда дөнья күрүе – бу төбәктә әмирлекләр арасындагы яуларның шаулап үтүен раслый. Мөхәммәтҗан Зәетов 1860 елларда җыйган «Хаҗи-Гәрәй» дастанында Чаллы әмире Хафиз-Гәрәйнең, казанлылар тарафыннан җиңелгәч, Бохарага качып китүе хакында да бәян ителә...

Күгәрчен төбәгенең Казан ханлыгы чорында ук гөрләп торуына янә бер дәлил бар. Казан ханы Мөхәммәтәмин 1516 елда тархан Асылхуҗа Мизәк (Маҗак) улына һәм аның балалары исеменә ярлык бүләк итә, аның нигезендә Күгәрчен төбәге шушы нәселгә беркетелә. Ә 10 елдан соң яңа хан Сафа-Гәрәй дә әлеге ярлыкны өр-яңадан раслый, әмма бу юлы асылхуҗалыларга Күгәрчен төбәге генә түгел, ә Бөгелмә янындагы һәм Зәй, Сок елгасы буендагы биләмәләр дә бүләк ителә. Асылхуҗа тарханның дәвамчысы Нәдер Уразмәтов Зәй елгасы буена XVII гасыр азагында ук килеп утыра, үз исемендәге волостьны нигезли һәм Россия империясендә иң беренче булып, шушында нефть ятмасын таба һәм аны сәнәгый юл белән эшкәртергә рөхсәт сорый башлый. Әмма рус сәүдәгәрләре басымы астында аңа 30 ел буена нефть чыгару белән шөгыльләнергә рөхсәт бирмиләр, ә рөхсәт алгач, Нәдер старшина бик серле рәвештә дөнья куя, аның улы Йосыф нефть эшкәртүдән гомумән баш тарта...

Күгәрчен бу җирлектә 1724 елда үткәрелгән беренче ревизия документларына ук эләгә, ул чакта авылда 116 ир-ат исәпкә алына. Ләкин бу сан – Күгәрчен мантый алмаган яки бик тә акрын үскән, дигән сүз түгел. Чәчүлек җир җитмәү – һәр игенче өчен яман бәла. Ә аннан да куркынычрак афәт – көчләп чукындыру. Казанны аяк астына егып салганнан соң, христиан «каратун»нары бүгенге Лаеш, Балык Бистәсе, Мамадыш, Алабуга, Зәй районнарының Идел белән Кама буйларына утырган татар авыллары халкын көчләп чукындыруга керешә. Балык Бистәсе районында гына да халыкның өчтән берenә «тавык тәпие» асып чыгуга ирешәләр. Ә үз диненнән баш тартырга теләмәгән горур ирләр, сыену-терәк эзләп, бүгенге Башкортстан, кичә Татар Ватаны булып саналган Алтын Урда җирләренә кача. Шушы ук чукындыру хафасы Күгәрчен ирләренең бер өлешен моннан 400 ел элек үк, 1610 елларда Самара өлкәсенең Похвистнево районына керүче Гали авылын нигезләргә мәҗбүр итә (Бүген ул – бөтен Идел буендагы иң бәрәкәтле, иң төзек һәм үз көнен үзе күреп яшәүче үрнәк авыл!) Тарханлык ярлыгы һәм рус патшасы Михаил Федоровичның 1617 елгы указы нигезендә Күгәрчен – Тәберде Чаллысы арасындагы җирләргә ия Киләй һәм аның энесе Булат Монашевлар һәм аларның нәселеннән чыккан Сөләймановлар 1690-1691 елларда «башкорт вотчиннигы» дәрәҗәсен алуга ирешә һәм хәзерге Оренбург өлкәсенең район үзәгенә әверелгән Әсәкәй авылына да нигез сала. Шушы ук нәсел элек Кыр-Елан волостенда, бүген Башкортстанның Шаран районындагы саналучы Тархан һәм Күгәрчен-Булэк авылларына да гомер бирә. Сөләйман тарханның уллары шул ук елларда бүгенге Тукай районындагы Калмия авылын да нигезли. Бер төркем күгәрченлеләр бүгенге Мөслим районының Иске Карамалы һәм Метрәй авылларына да күчеп утыра...

Ә Кама елгасы буенда урнашкан Балык Бистәсе районы халкы, тешен кысып сыкрый-сыкрый, һаман гомер итә. 1742 елда Казан провинциясе буенча – 418, ә Балык Бистәсе районында 15 авылның мәчетен җимереп чыксалар да, Күгәрчен халкы үзенең тәүге Аллаһ йортын хәкарәт итәргә ирек бирми. Әмма халык саны 1760 елларда 500 гә якыная, күгәрченлеләргә чәчүлек җир, барыннан да бигрәк – чиркәү тәресен күрмичә, чаң шавын ишетмичә яшәү өчен ирек, хөрлек җитми. Шуңа күрә күгәрченлеләрнең яңа төркеме 1763 елда хәзерге Башкортстанга күченеп, соңыннан качакларның туган нигезе исемен алачак Күгәрчен авылын кора (язучы Мәҗит Рәфыйков шунда туган). Тагын бер төркем гаилә нигездән кузгала да, Мөслимдәге Иске Карамалыда яшәүче туганнарын да ияртеп, бүгенге Башкортстанның Зиянчура районы җирләренә күчеп китә, анда яңа авыл нигезли һәм аңа да Күгәрчен исемен бирә (Башкортстанның халык шагыйре дәрәҗәсенә ирешкән Марат ага Кәримов шул авылдан).

Балык Бистәсендәге Күгәрчен халкы нәсел орлыгын чәчкән төбәкләрне күп санадык, инде аерым рәвештә, хәтта тулы бер районга да үз исемен биргән Башкортстандагы Күгәрчен авылына тукталыйк. Без март аенда ук аңа сәяхәт итүебез турында хәбәр салган идек, үзәге Морак (революциягә кадәр исеме – Кызыл Мәчет) булган Күгәрчен районының табигатенә дә, Күгәрчен авылының үзенә дә сокланып туя алмадык.

Башта ук ачыклыйк һәм кисәтик: ошбу төбәк бернинди дә «башкорт төяге» түгел. Бүгенге Күгәрчен авылы урнашкан төбәк XVI гасыр азагына кадәр Ногай урдасының Мангыт кабиләсе җирләре булып тора. Ногай урдасы таркалгач, шушы ук төбәк XVIII гасыр уртасына кадәр казах белән башкорт ыруларының ызгыш мәйданына әверелә. 1755 елда кузгалган Батырша восстаниесе белән таныш һәрбер укымышлы кешегә мәгълүм: карагруһчы һәм мәкерле губернатор Иван Неплюев оештырган «подметный» (махсус ташланган) хатлар таратып, Оренбург хөкүмәте казах белән татар-башкорт ирләре арасында мал йөртердәй җәйләүяланнар өчен сугыш чыгара, нәтиҗәдә Җаек-Урал аркылы ике якка да күчеп дәвам иткән бәрелешләрдә тугандаш мөселман халыкларының 50 меңгә якын ирләре юк ителә, кыпчак кабиләләренең Бөрҗән ыруы тирмәләре тынычрак урынга, урман эченә кереп урнашырга мәҗбүр була. Әле бу восстаниегә кадәр үк Күгәрчен төбәгенә 1730 елларда Мургап елгасы буенда яшәгән төрекмән ырулары килеп урнашкан була, Дәүләткол исемле башлыклары хәтта үз исемендәге авыл да нигезләп өлгерә.

Башка адаш авыллардан аерылып торсын өчен, шул Дәүләткол куршесендәге Күгәрчен авылына «Җидеболак» дигән аергыч та өстиләр. Чөнки Казан төбәгеннән килгән күчмәннәр җиде чишмә бергә кушылып аккан инеш ярына урнаша, шуңа нисбәтән хәтта 1800-1850 еллар документларында да «Җидеболак Күгәрчене» булып йөри. Күгәрченне беренче булып нигезләгән кешеләр Балык Бистәсендәге Күгәрченнән 1719 елда бүген Зәй районына кергән Аксар авылына күчкән була, ә 1763 елда инде шулар ук Җидеболак елгасы буена, Сергеевка белән Уар (Богдашкино) авыллары арасына килеп утыра. Тәүге булып килгән дүрт гаиләне Әхмәт Гомәров, Салих Корбанаев, Рахманкол Искәндәров һәм Кәбир Борындыкый атлы ирләр җитәкли. Шунысын да өстик: 1744 елда патшабикә Елизавета Петровна фәрманы буенча Сакмар елгасы буенда Каргалы авылын корган чагында да, Сәгыйть Хәялин атлы сәүдәгәргә ияреп, Балык Бистәсендәге Күгәрчен авылыннан да – 4, бик ерак

● Нигъмәтулла агай безгә борынгы китаплар турында бәян итә.

● Нигъмәтулла Ваһапов хәзинәсендәге борынгы китапларның бер өлеше.

КҮГӘРЧЕН

заманада Күгәрченне нигезләгән Ишки авылыннан – 7, Тәкәнештән – 7, Казанның үзеннән һәм Байлар Сабасыннан 160 чамасы гаилә күчеп утыра.

Җидеболак Күгәрченендәге ирләр килеп төпләнүдән соң 20 ел үтүгә, 1785 елда салам түбәле йортта манарасыз гына мәчет ачып җибәрәләр. Ул вакытка Күгәрчен халкы ишәйгән, аңа Оренбург янындагы Каргалыдан – 8, якындагы Биккол авылыннан 7 гаилә килеп өстәлгән була. Ирләр нигездә ямчылык хезмәтендә йөреп көн күрә. Әмма җирле Оренбург губернасы хакимияте болар яңа гына нигезләнгән авыл, дип ташлама ясап тормый, күгәрченлеләргә дә казна өчен күмер хәзерләү, каеннан деготь ясау бурычлары җиткерелә. Күгәрченлеләр 1730 елларда ук үз исемендәге авылны нигезләгән Дәүләткол хуҗа булып алган Олы тау, Олы куак аша урманга йөрергә мәҗбүр була. Кысмыр һәм тәкәббер Дәүләткол халкына бу гамәл һич ошамый, алар Ишкилде атлы кешедән күгәрченлеләр хакында шикаять язып алдыра. 1799 елның сентябрь аенда Күгәрченгә 9 нчы кантон башлыгы Бурангол Куватов килеп төшә. Ул ике авыл халкын да Туер ермагы янына җыеп, үзара килештерүгә ирешә. Ләкин Күгәрчен халкына Оренбург губернаторы биргән яклау грамотасы гына җитми, күрәсең, авыл җыены Исмәгыйль атлы кешене, акча җыеп, Петербургтан, патша канцеляриясеннән герблы кәгазь белән расланган грамота алып кайтырга озата. Исмәгыйль, чыннан да, Петербургка җитеп, герблы кәгазь алуга да ирешә, әмма кире кайтканда ул грамотаны югалта. Ачуы чыккан Күгәрчен халкы: «Син барып тормагансың, ә акчаны үзләштергәнсең!» – дип аны кыйнап ташлый, ә сәйяхы шунда алган җәрәхәтләреннән җан тәслим кыла. Өч айдан соң губернаторга Исмәгыйль алып киткән грамотаның күчермәсе дә килеп төшә-төшүгән, мәгәр сәйяхны кире кайтарып булмый...

1800 елда Күгәрчендә мәдрәсә дә ачып җибәрәләр. Тәүге елда аңа 6 гына шәкерт керсә дә, 4 елдан соң инде 12 шәкерт белем ала башлый. Бер яктан тәкъдир гыйлемлелек белән сөендерсә, аяк астында казасы да табыла: 1805 ел кышында бүреләр өере, лапасларга кереп, гаиләләрнең 2 сыерын һәм 12 сарыгын бугазлап чыга. Андый бәлаләргә һичнинди ташлама ясап тормыйча, җирле хакимият авыл халкын староста Фәтхулла йортына җыеп, 1807 елның сентябрендә һәр кеше башына 140 себерке, һәр ир-атка дүртәр арба агач күмере, йорт башына 30 ар кило каен тузы, билгеләнгән күләмдә шәл, юкә һәм деготь әзерләргә фәрман җиткерә. Фәтхулла староста тиздән игеннән дә салым җыелачагы турында кисәтә, ә мондый талаудан ярсыган Нәҗметдин халыкны буйсынмаска чакыра. Нәкъ шул кичтә үк көчле давыл чыга да, Фәтхулла старостаның йортына ут каба, аннары берничә күрше ихатага сикерә. Фәтхулла, әлбәттә, «өемә ут төрттеләр» дип, югарыга шикаять юллый. 16 сентябрь көнне авылга земство башлыгы, 4 пүнәтәй һәм кылычлар таккан ике гаскәри килеп төшә, сорау алулар башлана. Фәтхулла шикләнгән ике ирне кулга алып, Оренбургка озаталар. Шул ике ирнең гаиләсен йортларыннан куып чыгаралар, аларга Фәтхулла староста кереп урнаша. Оренбургка озатылган ирләрнең берсенә туган тиешле Нәҗметдин бу юлы да тыелып кала алмый, ул Фәтхуллага сәнәк белән кадый. Фәтхулла өч көннән соң вафат була, ә улы Кыяметдин янә Оренбургтан гаскәриләр алып килеп, Нәҗметдинне 15 тапкыр чыбыркы белән ярдырта һәм Себергә озаттыра. Мондый фетнәгә юл куйган өчен, авыл ирләренә штраф салына һәм салым күләме икеләтә арттырыла. Мәгәр Кыяметдин дә озак вакыт тантана итә алмый, 1812 елда ул параличтан үлә.

Ләкин ул вафат булганчы, Күгәрчендә янә чуалышлар булып өлгерә. 1809 елда Уар авылы халкына җиткерелгән салым белән чагыштырып карагач, күгәрченлеләрнең икеләтә күбрәк түләргә мәҗбүр булганлыгы ачыклана. Яңа староста Сафа йортына җыелып, халык моннан ары салымның яртысын гына түләячәге турында белдерә. Сафа бу хакта Оренбургка хәбәр итә. Янә авылга 6 чиновник килеп төшә. Алар өйдән-өйгә йөреп, халыктан налог урынына самавыр, ястык-юрган, казан һәм чүлмәкләр җыеп чыга. «Нигъмәтне» каравыл йортында калдырып, үзләре йокларга староста йортына кайталар. Ә таң атса, атлары юкка чыккан, арба һәм дирбияләре теткәләнеп беткән. Ике айдан соң Оренбургтан 4 чиновник килеп аңлата. Бактың исә, Уар халкының яртысы керәшен, ә алар салымнан азат ителгән икән, янәсе. Күгәрченнең кызган халкы уарлыларның да нәкъ үзләре шикелле үк мөселман икәнлеге, аларда да мәчет эшләве, көн саен азан яңгыравы турында әйтеп сала, хәтта, чиновникларның якаларыннан сөйрәп, Уарга алып бару белән дә куркыталар. Чиновниклар баш тарткач, күгәрченлеләр каравыл йортының йозагын вата да, мендәр-ястыкларын, казан-чүлмәкләрен җыеп таралыша. Соңыннан ачыклана: чиновниклар, чыннан да, документларда Уар халкының яртысын керәшен итеп күрсәтеп, салым күләмен «кисәләренә салып» барган икән...

1812 ел язында Күгәрченгә Мамадыштагы Ишки һәм Комазан Башы авылларыннан янә 5 гаилә «туганнары» күчеп килә, ә 9 нчы кантон башлыгы Бурангол Куватов 500 сум ришвәт хакына «Үсергән башкортларының туганнары», дип аларга яңа җир бирә. Бу күчмәннәр Сүрәм елгасы буена Салих авылын нигезләп утыра, ләкин бер төркем ир Җидеболак елгасы янына «шуышып», Дәүләткол авылының җиренә басып керә. Дәүләткол губернатор исеменә шикаять юллый, ә Бурангол кантонның күгәрченлеләрне якламыйча бүтән чарасы юк. 1827 елда эш судка барып җитә һәм ул күгәрченлеләрне 12 нче кантонга кайтарырга, дигән карар чыгара. Тик 12 нче кантон башлыгы Кормый (Каһарман) Ногайбәков аларны кабул итүдән баш тарта. Ахыр чиктә бу сызгыш мәсьәләсе патша Николай I колагына да барып җитә һәм ул, аптырагач, күгәрченлеләрне Дәүләткол җирендә калдырырга рөхсәт бирә. «Каргалы, Чебенле һәм Күгәрчен авыллары, менә шулай итеп, татарларны үрчетеп һәм көче-көче белән тирә-якка таратып ятучы үзәккә әверелә» (Әкрам Бийеш).

Оренбург белән Уфа каласын тоташтырган Ногай юлындагы Күгәрчен ирләренең 1773 елда башланган Пугачев явында катнашмый калуы мөмкин түгел. Бу – фетнә кайнап торган, әле Уфа, әле Оренбург ягына фетнәче крестьян отрядлары ут уйнатып чапкан, ачык төбәк. Күгәрчен зур яу яисә отряд башлыклары үстерергә әле өлгермәгән, әмма ирләренең Ногай юлының баш старшинасы Алибай Моргазолов яисә шул ук юлдагы волость башлыгы булган Кинҗә Арсланов яки инде берәр татар отряды составында яу йөрүе мөмкин.

1812 елгы Ватан сугышыннан инде бер авыл да качып кала алмый. Чөнки ул яуга һәр 4 йорттан бер сугышчы походка чакырылган. Күгәрчен авылыннан Кәбир Корбанаев, Габделмән Исламгулов, Юлдаш Локманов, Нурдәүләт Булатов та «башкорт» полклары сафында яу йөреп кайткан, Тарутино һәм Шинграбежский калалары янында узган бәрелешләрдә катнашкан. Габделмәннең һәлак булып калуы да мөмкин, чөнки 1834 елгы җанисәп вакытында аның фамилиясе бөтенләй дә телгә алынмаган.

1814 елның 13 июнендә коточкыч җил кубып һәм яшен сугып, авылда 6 йорт каралты-куралары белән янып бетә. 1800 елда ачылган мәдрәсә дә юкка чыга. Янгыннан каза күрүчеләр җиргә землянка казып, түбәсен читән белән каплап, аларны балчык белән сылап кыш чыгарга мәҗбүр була.

1821 елда яз һәм җәй көннәрендә бер тамчы да яңгыр яумау сәбәпле, коточкыч ачлык башлана һәм авылның 26 кешесе вафат була. Ә солдатка чакыру дигәнен туктатып тормыйлар, ике егет солдатка китеп бара. Аларны һәр йорттан акча һәм сохари җыеп озаталар.

1832 елның көзендә Күгәрчендә яңа мәдрәсә төзелә һәм 20 шәкерт укый башлый. Аларга Каргалы мәдрәсәсеннән килгән хәлфәләр белем бирә.

1833 елда Күгәрченнән янә ике егет солдатка алына. Габделхалик атлысы Петербургка эләгеп, патша сараенда атлар караучы булып хезмәт итә. Падишаһка тугры хезмәт иткән өчен, аны көмеш медаль һәм яңа кафтан белән бүләклиләр. Авылга әйләнеп кайткач, салымнарын вакытында түләмичә калса һәм Оренбургтан түрәләр килеп төшсә, Габделхалик көмеш медален тагып чыга да, аңа сүз әйтергә һичкем кыймый икән. Әмма тәкъдирне алдау читен. Миче тузгач, ул күрше чуаш авылыннан бер ирне чакыра, ә тегесе Габделхаликның медале белән кафтанын урлап китә...

(Ахыры киләсе санда).

Вахит ИМАМОВ.

Автор фотолары.

Гаяз Исхакый һәм Габдрәшит Ибраһим мөнәсәбәтләре

(Дәвамы. Башы 20 нче санда).

Исхакыйның «Коммунист хаҗы» дип аталган бу мәкаләсендә сүз 1930 елгы хаҗ турында бара, бу бәлки Г.Ибраһимның соңгы хаҗы булгандыр, чөнки аңа алга таба, Төркия зарарына сөйләп йөрисең, дип, илдән чыгу тыела. Ул Бөгередәлек авылында сөрген хәлендә яши, китаплар яза, әмма аларны Төркиядә бастыра алмый. Аның янына Япония илчелегеннән килеп, Япониягә күчеп китәргә тәкъдим итәләр, Токиода яшәүче ислам лидеры, элеккеге танышы, башкорт мулласы Габделхәй Корбангалиевтән дә шунда чакырып кат-кат хатлар килә. Инде тормышына куркыныч яный башлагач, Габдрәшит хәзрәтне яхшы белгән һәм хөрмәт иткән төрек генераллары ярдәме белән, ул, 76 яшендә, ишле гаиләсен Бөгередәлектә калдырып, үзенең соңгы сәфәренә кузгала. 1933 елның августында ул Төркиядән качып китә, яшерен юллар белән Мисыр-Хиҗаз-Һиндстан-Шанхайлар аша, шул елның октябрендә Токиога килеп урнаша. Ә Габдрәшит хәзрәт белән бергә хаҗ кылып йөргән совет илчесен, Шәрык белгече Нәзир Түрәкуловны, 1936 елны Мәскәүгә чакыртып кайтаралар һәм 1937 елны «халык дошманы» дип, атып үтерәләр. Шундый ук аянычлы язмыш гарәп илендәге икенче илче, татар кешесе Кәрим Хәкимовны да көтә, аны да Мәскәүгә чакыртып кайтарып, 1938 елны атып үтерәләр. Шушы хәлләрдән соң Согуд Гарәбстаны СССР белән дипломатик мөнәсәбәтләрен өзә, ул бары тик узган гасырның туксанынчы елларында гына торгызыла.

Исхакыйның язмаларыннан күренгәнчә, алар Габдрәшит хәзрәт белән Шанхайга хәтле ай буе бер пароходта килә. Безгә аларның андагы мөнәсәбәтләре билгесез, әмма 1933 елның 2 октябрендә Шанхай диңгез портында, үзен каршы алучылар янына, таможнядан Габдрәшит хәзрәтне ул үзе алып чыга, хөрмәт белән «Рәшид әфәнде» дип яза.

«Күрешеп, янымда Рәшид әфәндENең дә булуын сөйләп, аны табып алыр өчен, мин тагын әчкә кереп киттем вә, Рәшид әфәндене кыямәт кеби улаган гүмрүек амбарыннан мең бәла берлә табып, алып чыгып күрештереп, шәһәргә таба киттек.» («Яңа милли юл», 1934, № 1.) Шанхайдагы татар мөһаҗирләре алар хөрмәтенә мәҗлес уздыра, «төрле йирләргә таралган халкыбызның хәле белән таныштыруны үтенә». «Без дә вазифаларыбызны бүлешеп алып, Рәшид әфәнде ислам берлә таныштыра. Мин, төрек дөньясы хакында гомуми бер мәгълүмат биреп, үзебезнең Идел буе мөһаҗирлеге турында озак туктыйм», дип яза Г.Исхакый. (Шунда ук.)

Исхакый бу мәкаләсенең язылу вакытын «Шанхай, 12 октябрь», дип куйган, димәк, алар әле бу вакытта Габдрәшит хәзрәт белән бергә Шанхайда була. Аннан соң Г.Ибраһим Токиога китә, Г.Исхакый анда бераз соңрак, октябрьнең 16 сында килә, аны вокзалда зурлап шәһәрнең мәхәлләи исламия әгъзалары, мөселманнарның биредәге җитәкчесе Мөхәммәд-Габделхәй Корбангалиев каршы ала. Башта Г.Исхакыйның алар белән мөнәсәбәте яхшы була, Габдрәшит хәзрәт белән бергәләп Токиода да очрашулар оештыралар. «Мәктәбе исламия»дә укучы балалар хәтта Г.Исхакыйның «Зөләйха» әсәреннән өзекләр дә күрсәтә. Токио фотоларында да әле бу өч лидер бергә. Әмма алга таба Токио мөселман мәхәлләсе рәисе Г.Корбангалиев һәм Г.Исхакый арасында каршылыклар башлана, кул астына тагын Габдрәшит хәзрәт эләгә, мөһаҗирлектәге бөтен төрки-татар дөньясын шаулатырлык вакыйгалар булып үтә.

Сүз «11 февраль вакыйгасы» булып тарихка кереп калган хәлләр турында бара. Бу хакта әдәбият галиме Зөфәр Мөхәммәтшин Г.Исхакыйның 15 нче томындагы искәрмәдә менә ничек яза: «1934 елның 2 февралендә Токио Идел-Урал төрек-татарлары мәдәни җәмгыяте оештырыла. Әмма бу вакыйга Токио «Мәхәллаи исламия» җәмгыятен һәм аның рәисе Г.Корбангалиевне борчуга сала. 1934 елның 11 февралендә, яңа оешманың җитәкчелеген сайлау көнендә, җыелышка берничә рус кешесе белән Г.Корбангалиев тә килә. Алар, тавыш куптарып, көтмәгәндә Г.Исхакыйга ташлана. Бер төркем хатын, яшьләр сугышны туктатып кала. Япония полициясе җыелышны ябарга мәҗбүр була. Г.Исхакыйга каршы оештырылган һөҗүм шул дәрәҗәгә күтәрелгән ки, ул «11 февраль вакыйгасы» буларак кына искә алынып калмыйча, мөһаҗирәттәге татар матбугатында нәфрәтнәмәләр басылуга сәбәпче булган.» (Г.Исхакый. Әсәрләр. 11 том. – Казан, 2011, 304 б.)

Бу күңелсез вакыйгаларда Г.Ибраһимның катнашу-катнашмавы билгеле түгел, сиксәне белән барган дини ил карты алай таяк күтәреп сугышып йөрмәс. Әмма ул Г.Корбангалиевкә дә каршы китмәгәндер, үзен Япониягә чакырып китергән өчен генә түгел, ә аның белән уртак дини һәм мәгариф эшләре булганга, ул бу мәгънәсез бәхәстә үзгыш-талаш ягында булмагандыр. Ә каршылык, кайберәүләр язганча, ике хәзрәтнең Япониядә ислам байрагын күтәрүдә, ә Г.Исхакыйчыларның милли байрак күтәрүендә генә түгел. Төп мәсьәлә – милек мәсьәләсе, ә ул Корбангалиев кулында була, Токиодагы мәчет-мәктәп бинасы да, милли матбугат та аның шәхси милке булып санала, чөнки Япония законнары буенча аларны рәсми рәвештә танылмаган дин оешмасы артында теркәтә алмыйлар. Г.Исхакый һәм аның тарафдарлары бу милекне «милләт малы» дип игълан итә, чөнки бу биналарда татар җәмәгатьчелегенең дә, хәтта японнарның да өлеше була. Япониядәге төрек-татарларның 1934 елның 9-12 маенда Кобе шәһәрендә үткән беренче корылтаенда дини мәктәп һәм милли матбаганы Корбангалиев кулыннан көчләп тартып алу буенча, «милләт малын милләткә кайтару өчен», 6 кешелек комитет төзелә, «милли хокукларны кайтару өчен», корылтай Япония юстициясенә мөрәҗәгать итә. Г.Исхакый үзенең «Япониядә төрек-татарларның беренче корылтае» дип аталган мәкаләсендә язуынча, «...корылтай Корбангалиев вә иярченнәренә нәфрәт һәм милли бойкотны игълан итте.» (Шунда ук, 21 б.) Корылтай карарында әйтелгәнчә, делегатлар япон хөкүмәтеннән Корбангалиев һәм журнал хезмәткәре Г.Ибраһимовны «авызлыклау»ны һәм чыгышларын туктатуны сорый. Г.Исхакый югарыда телгә алган мәкаләсендә бу шәхесләрне, исемнәрен әйтмичә генә, «милли дошманнар вә аларның аҗаннары (шымчылары, шпионнары), милли хаиннар, шарлатаннар, болганчык суда балык тотучылар», дип атый. Эшләр бик тирәнгә китә, ямьсез төс ала, Япониядәге, бигрәк тә, Токиодагы милли һәм дини җәмгать икегә аерыла, татарларның бер өлеше Г.Исхакый, икенче өлеше Корбангалиев ягына баса һәм бу каршылык гомер буе бара.

Әле бу корылтайга кадәр үк, 14 февральдә, Г.Исхакыйга каршы һөҗүмне оештыручыларны хөкем итү өчен, Токио һәм Кобе шәһәрләренә яшәүче татарлардан 11 кешелек Милли мәхкәмә төзелә, алар Г.Корбангалиевкә һәм «Яңа япон мөхбире» журналына бойкот игълан итә. Милли мәхкәмәнең бу карары «Яңа милли юл»ның 1934 елгы 5 нче санында басылып чыга, анда Г.Исхакыйга һөҗүм итүчеләрнең (карарда «кыйнаучылар» диелгән) исемнәре дә язылган, алар арасында Г.Ибраһим юк. (Шунда ук, 306 б.) Әмма Г.Исхакыйның 1934 елның 14 мартында, Япония тышкы эшләр министрына язган хатында ул Г.Ибраһимны да Корбангалиев белән янәшә куя, аны «сообщник» («иярчене»), дип атый. Шунысы игътибарга лаек, Г.Исхакыйның бу рәсми хаты инде сәяси төсмер алган, анда 11 февраль вакыйгалары юк, кыйнау-сугышулар язылмаган, ә Корбангалиев белән Г.Ибраһимов русларга, Россиягә хезмәт итүдә гаепләнгән, Г.Исхакый япон хөкүмәтен алар белән эш итмәскә чакырган («Гасырлар авазы» – «Эхо веков». 2001, №3-4, стр.78-80.) Шулай итеп, Г.Исхакый белән Габдрәшит хәзрәт арасында күперләр гомерлеккә яндырыла...

Хәер, Г.Исхакый моның белән генә дә тынычланмый, «Казан китүгә 383 ел үтте» дигән мәкаләсендә тагы Г.Ибраһимны начар яктан искә ала, бу юлы ул аны «Шаһгали варислары» исемлегенә кертә. Аның язуынча, Казан алынганнан бирле милләт икегә – Олуг Мөхәммәд һәм Сөембикә юлын дәвам итүче бәйсезлек көрәшчеләренә һәм русларга сатылган, аларга хезмәт иткән «Шаһгали варислары»на аерылган икән, Габдрәшит хәзрәтне ул соңгысына кертә. «Илебездә большевикларның милләтебезне, динебезне җимерү өчен корган планына хезмәт итүче Сәедгалиевләр, Баембәтовлар, Нәзир Түрәкуловлар, Г.Ибраһимовлар – шул ук Шаһгалинең бүгенге гаскәрләреде, шул ук хыянәтне эшләүче фасикъләрдыр. ...Шаһгали балалары, руслар белән бер саф булып, төрек-татарның милли байрагына һөҗүмдә рус балтасына тугрыдан-тугры сап булалар. ... Русларның бу озын сөрген золымнарын вә төрле-төрле Шаһгали балаларының хыянәтләрен милләтнең ләгънәте берлә тарих битенә атачакбыз» («Яңа милли юл». 1935, 11 нче сан; Хатыйп Миңнегулов. Г.Исхакыйның мөһаҗирлектәге иҗаты. – Казан, 2004, 210-214 бб.); Г.Исхакый. Әсәрләр. 11 том. – Казан, 2011, 87-91 бб.)

(Дәвамы киләсе санда).

Фәүзия БӘЙРӘМОВА.

Татарча язу машиналары тарихы

Язу машиналары – җәмгыять үсешенең бер этабы. Төрле гасырларда бер-берсеннән бәйсез рәвештә язу җайланмалары булдыру очраклары билгеле. Әмма язу машиналарын XIX гасырның икенче яртысыннан гына сериялэп эшләп чыгара башлыйлар. Шул вакытларда Германиядә, Америка Кушма Штатларында «Империал», «Мерседес», «Ундервуд», «Континенталь», «Ремингтон» кебек данлыклы язу машиналары җитештерелә.

Россия империясендә язу машиналары җитештерелмәү сәбәпле, чит илләрдән сатып алынган машиналар кулланыла. Әлеге машиналарның үрнәкләре Татарстан Республикасы Милли музеенда да саклана һәм аларны музейның төрле экспозиция мәйданчыкларында күрергә мөмкин.

XX гасыр башында татар җәмгыяте житди үзгәрешләр кичерә. Бу бигрәк тә техник яктан алга киткән илләргә тартылуда чагыла: Европача киенү, татар мәдәниятенә сәнгатьнең яңа төрләрен кертү, фән-техника казанышлары белән уртаклашу. XIX гасыр ахыры – XX гасыр башында күп кенә татар зыялылары, эшмәкәрләр, галимнәр, язучылар Европага сәяхәт итә, тәҗрибә уртаклаша, җитеш-фирмаларының язу машиналарына гарәп шрифтын көйләү уңышлы булмый: алар зур, авыр һәм бик акрын баса, шунлыктан Шәрыкта кулланылыш тапмый.

Т.Туганов белән Г.Мадьяров клавиатураның үлчәмнәрен үзгәрешсез калдырып, билгеләрне алтмышка кадәр кыскартуга ирешә. Әлеге язу машинасында гарәп язуы үз рәвешендә сакланып кала.

Язу машинасы Мәскәүгә китерелә һәм рәсми рәвештә экспертлар, мөселман язуы белгечләренең уңай бәяләмәләрен ала. Язу машинасында башкорт, кыргыз, үзбәк, татар һәм төрек, гарәп, фарсы, азәрбайҗан һәм хәзерге һинд телендә язарга мөмкин.

Язу машинасының эшләнелеш теориясен командир Г.Мадьяров, ә гамәгән язу машинасын һәм полиграфия сәнәгатендә яңа алымнарны кулланылышка кертүче киңкырлы галим-практик. Беренче бөтендөнья сугышы алдыннан гади, матур һәм уку өчен уңайлы хәреф булдыру проблемасы белән шөгыльләнә. Бу турыда үзенең автобиографиясендә дә яза: «В 1914 – 1915 годах занимался гравировкой новых татарских шрифтов по своему проекту и применением татарского алфавита к пишущей машине «Гаммонд»» [Автобиография М.Идриси]. Әмма сугыш бу эшне читкә куеп торырга мәҗбүр итә.

1917 елда М.Идрисов Казанда хәреф кою эшен оештыра: Көнчыгыш халыклары бик озак көткән гадиләштерелгән конфигурацияле гарәп хәрефләре коела. М.Идрисов хәрефләренең яңа гарнитурасын алу өчен, хәтта Урта Азия һәм Казахстаннан да киләләр.

Истәлекләрдән күренгәнчә, 1926 елның февралендә М.Идрисов Америкада эшләнгән язу машинасы сатып ала һәм шунда ук, татар шрифтларын клавиатурага яраклаштырып, яңа принципка нигезләнгән язу машинасы эшли. М.Идрисовның яңалыгы шунда: ул чит илдән

терүнең яңа алымнарын үзләштерә. Әлеге тенденция китап басу эшчәнлегендә дә чагылыш таба. И.Харитонов, М.Идриси, Ф.Кәрими, Ә.Хәсәни һ.б. басмаханәләр эшчәнлегендәге яңа алымнарны Германия предприятияләрендә өйрәнәләр.

Татар җәмгыятенең алга үсеше тәэмин итү өчен, язу машиналарын «татарча» яздыру ихтыяҗы туа. Бу эшчәнлек өч яссылыкта бара: беренчесе – татар теленең орфографиясен камилләштерү, икенчесе – язу машиналары татар язуына хас булган калыпларга җайлаштыру һәм өченчесе – шрифтларны клавиатурага яраклаштыру.

Әлеге эшчәнлекнең нәтиҗәсе – 1929 елдан Советлар Союзында беренче язу машинасын – «Яңалиф»не сериялэ җитештерә башлау. «Яңалиф» маркалы Казанда җитештерелгән язу машиналары Милли музейда да саклана. Алар икәү: берсе – латин графикасында, икенчесе – кириллицада. «Яңалиф»нең татарча кириллицада булуы, әлеге маркалы язу машинасының XX йөзнең 40 нчы елларында да җитештерелүе турында сөйли.

Союз күләмендә беренче язу машинасын уйлап табуда Г.Алпаров, Г.Мадьяров, Ә.Шәйхгали, М.Идрисов кебек татар галимнәренең, һәвәскәрләрнең эшчәнлеге ята.

«Жизнь национальностей» газетасы 1922 елның 26 апрель санында редакциядән яңалыклар рубрикасында татарча язу машинасы уйлап табылу һәм аның авторлары турында мәкалә бастыра. Анда түбәндәге юллар бар:

«Башкорт кызыл армия солдатлары Т.М.Туганов һәм командир Г.Г.Мадьяров гарәп шрифтында язу машинасы уйлап таптылар. Башкорт Үзәк Башкарма комитеты язу машинасын «Башкурдистан» (Башкирия) дип атарга һәм шул исем астында патент алырга тәкъдим итте.

Билгеле булганча, якынча 150 знаклы гарәп шрифтын язу машиналарында куллану мөмкин түгел диярлек. Европа ли-техникасын кызыклармеец Т.Туганов башкара» [Печатная машинка... № 8].

Патентка гариза 1922 елның 9 сентябрендә бирелә (Таныклык №75838) һәм 1924 елның 20 ноябрендә унбиш елга исәпләнгән патент алына.

Бу елларда Казанда да язу машиналарын татар алфавитына яраклаштыру һәм аларны үзебездә җитештерә башлауга әзерлек эшләре бара. Бу өлкәдә Әскәр Шәйхгали эшчәнлеге игътибарга лаек. Ул 1924 елның октябрендә язу машиналары остаханәсе мөдире итеп билгеләнә. Ә.Шәйхгали эшләгән язу машинасы, читтән кертелгән машина конструкциясен сүтеп, яңадан татар шрифты, татар язуы үзенчәлекләре белән тулыландырылып җыела.

1928 елда чит ил язу машиналарының төрле механизмнарын татар язуына яраклаштыруга, Казанда эшләнгән язу машинасы «Яңалиф»нең үрнәк экземплярлы Мәскәүгә җибәрелә һәм хөкүмәт тарафыннан югары бәяләнә. Шуннан соң Союз күләмендә производство масштабларында җитештерелә башлый. Бу – илебездә ясалган беренче язу машинасы. Ә.Шәйхгали турында, Казанда язу машиналары җитештерүче завод тарихы, аның казанышлары хакында Казан исәп-хисап техникасы тарихы музее директоры М.Бәдретдинова һәм Г. Галимуллина хезмәтендә язылган [Бадрутдинова, Галимуллина, с. 92 –106].

Әмма машиналарны «җимерү», беренчедән, аларның сыйфатына зыян китерә, икенчедән, бәяләрен арттыра. Ә бу исә тормыш шартлары авыр булган халык, дәүләт өчен хәлиткеч роль уйный.

Гомерен полиграфия сәнәгатен фәнни, техник, сәнгати яктан үстерүгә багышлаган талантлы шәхес Мөхәммәд Идрисов әлеге өлкәдә туган мәсьәләләрне чишүне үз өстенә ала.

М.Идрисов глобус, географик атамалар татарча бирелгән дөнья картасы эшли. Ул – хәрефләрне сулдан уңга җыюга көйлән-килгән машинаны «җимерми» генә, аның клавиатурасына татар шрифтларын урнаштыра. Машинаның эшләү механизмы үзгәртелмәү аркасында, читтән кайтарылган машина ике көндә «татарча» яза башлый. Шунысы да әһәмиятле: М.Идрисовнең машиналарын башка төрки халыклар да, гарәпләр дә куллана ала.

Татар алфавиты реформасы буенча киңәшмәдә М.Идрисовның 37 билгеле шрифт проекты югары бәяләнә. Ул эшләгән хәрефләр Мәскәүдә Үзәк китап фабрикасы нәшриятында кулланылышта йөри, башка илләргә дә җибәрелә.

Соңрак М.Идрисов үзенең эшчәнлеген Мәскәүдә дәвам итә. Ул гарәп хәрефе белән файдаланучы төрле милләтләр әдәбиятында бер төрле хәрефләрнең кабатлану ешлыгын билгели. Шуннан чыгып, яңа набор кассаларының, язу һәм хәреф җыю машиналарының клавиатуралары проектын эшли. Бу турыда М.Идрисовның Мәскәүдә Бөтенсоюз Үзәк Комитеты тәкъдиме белән эшләгән буклетлары аша танышырга мөмкин [Идрисов, 12439-56 М., 12439-54 М.].

М.Идрисов эшләгән язу машинасының клавиатурасы ун бармак белән тоемлап текст җыюга корылган, ягъни дөньякүләм стандартлар таләпләренә туры килә. Ул уку йортларында гамәли сынау үтә һәм уңай яктан бәяләнә. М.Идрисов стенография курсларында дәресләрне үзе дә алып бара.

Татар телендә басучы язу машинасы җитештерү – күп елларга сузылган эш нәтиҗәсе. Алфавитлар алышу белән, язу машиналары да үзгәртелә. Бу өлкәдә Г.Мадьяров, Ә.Шәйхгали, М.Идриси кебек милләтәшләребезнең эшчәнлеге зур игътибарга лаек. Әйе, язу машиналарының «вакыты узды», әмма алар үз заманында җәмгыятьне алга җибәргән бер корал булды.

Нурия МИФТАХЕТДИНОВА.

Айга кырын карама

Халык медицинасы чаралары белән дәвалануга керешкәнче, табиб белән киңәшү зарур!

3 июнь (шимбә). ***Зөлкагдә аеның 14 нче көне. 16 нчы Ай тәүлеге. Ай Чаян йолдызлыгында, 20.51 сәгатьтә калка. 2 нче фаза. Көн озынлыгы 17.13 сәгать.***

Тыныч, иҗади, уңышлы көн. Һәрнәрсәдә гармониягә омтылу, җан тынычлыгын саклау мөһим. Дулкынландыргыч очрашулар булырга мөмкин. Килешүләр төзү уңай нәтиҗә бирә. Кан авырулары кискенләшә. Беркемгә дә үпкә сакларга ярамый.

Ай дәвасы (1)

Дару үләннәре, бәлзәм, ванна, җиңелчә массаж һәм башка дәва чаралары, Айның кайсы билгедә булуына карап, төрле әгъзаларга төрлечә тәэсир итә. Ай Кучкарда чакта баш, күз, баш мие, сизү әгъзаларын; Үгезбозауда вакытта – баш арты, теш, урт, муен, колакны; Игезәкләрдә чакта – үпкә, җилкә, кул, бронхлар, төрле бизләрне; Кыслада вакытта – күкрәк читлеге, бавыр, үт куыгы, корсак, нервларны; Арысланда чакта – йөрәк, арка, диафрагма, кан әйләнеше системасын; Кызда вакытта – ашкайнату әгъзаларын, ашказаны асты бизен, талакны дәвалау яхшы нәтиҗә бирә.

4 июнь (якшәмбе). ***Зөлкагдә аеның 15нче көне. 17 нче Ай тәүлеге. Ай Укчы йолдызлыгында,22.20 сәгатьтә калка, 3.17 сәгатьтә бата. 6 сәгать 42 минуттан тулы Ай. Көн озынлыгы 17.15 сәгать.***

Мәхәббәт, иҗат, яшәү шатлыгы көне. Бернәрсә дә планлаштырмыйча, теләгән нәрсәне генә эшләү яхшы. Нерв һәм эндокрин системаларга, күзгә игътибарлырак булу сорала. Үпкәләшкән кешеләр белән дуслашыр вакыт. Яшелчәләрне күбрәк ашау файдалы.

Ай дәвасы (2)

Ай Үлчәүдә чакта – бөер, бәвел куыгы, аякны; Чаянда вакытта – җенес әгъзаларын, туры эчәкне; Укчыда чакта – кан тамырлары, билне; Кәҗәмөгездә вакытта – тез, сөяк, буыннар, тирене; Сукоярда чакта – балтыр, тубык, кан тамырларын; Балыклар йолдызлыгы астыннан үткәндә – аяк табаны һәм бармакларын, балтырны дәвалау уңышлы.

5 июнь (дүшәмбе). ***Зөлкагдә аеның 16нчы көне. 18 нче Ай тәүлеге. Ай Укчы йолдызлыгында, 23.30 сәгатьтә калка, 3.54 сәгатьтә бата. 3 нче фаза. Көн озынлыгы 17.16 сәгать.***

Алдашу, ялганга бай көн. Безләр системасы, бил, бөер, тире, сукыр эчәк зәгыйфь. Мунчага бару, массаж ясату, ач тору, төрле дәвалану чараларын куллану файдалы. Кәеф төшәргә мөмкин.

Керәнле бал

Кан басымын нормага китерү өчен, керән тамырын кырып, шуның 2 аш кашыгын 1 стакан кайнаган суга салалар да, 1 тәүлек төнәтеп, сөзәләр. 1 әр стакан кишер һәм чөгендер согы, 1 лимон согы, 1 стакан бал кушалар, яхшылап болгатып, суыткычта саклыйлар. Көненә 2-3 тапкыр, ашаганнан соң 2-3 сәгать үткәч яки ашарга 1 сәгать кала, 1 әр аш кашыгы кабалар.

(Дәвамы 18 нче биттә).

Айга кырын карама

6 июнь (сишәмбе). ***Зөлкагдә аеның 17нче көне. 18 нче Ай тәүлегенең дәвамы. Ай Кәкҗәмөгез йолдызлыгында, 0.19 сәгатьтә калка, 4.54 сәгатьтә бата. 3нче фаза. Көн озынлыгы 17.18 сәгать.***

Алдашу, ялганга бай көн. Бизләр системасы, бил, бөер, тире, сукыр эчәк зәгыйфь. Мунчага бару, массаж ясату, ач тору, төрле дәвалану чараларын куллану файдалы. Кәеф төшәргә мөмкин.

7 июнь (чәршәмбе). ***Зөлкагдә аеның 18нче көне. 19 нчы Ай тәүлеге. Ай Кәкҗәмөгез йолдызлыгында, 0.48 сәгатьтә калка, 6.17 сәгатьтә бата. 3 нче фаза. Көн озынлыгы 17.20 сәгать.***

Авыр энергетикалы көн. Күп аралашмаска, күз тиюдән, чит тәэсирләрдән сакланырга кирәк. Бурычка алырга да, бирергә дә ярамый. Нерв системасы, эчәклек, арканың өске өлеше зәгыйфь.

Чәч коелганда

Чәч артык күп коела башласа, атнасына 1 тапкыр баш тиресенә әчегән сөт сөртәләр, полиэтилен башлык киеп, 20-30 минут тоткач, җылы су белән юалар. Яисә юылган чәчкә җылы әрекмән мае сөртеп, резин башлык кияләр, 30 минуттан соң шампунь белән юалар. Атнага 2-3 тапкыр кабатлыйлар. Болай дәвалангада, көнено 3 тапкыр, ашаганнан соң, 1 әр чәй кашыгы җитен мае да эчәргә кирәк.

8 июнь (пәнҗешәмбе). ***Зөлкагдә аеның 19 нчы көне.20 нче Ай тәүлеге. Ай Сукояр йолдызлыгында,1.05 сәгатьтә калка, 7.54 сәгатьтә бата. 3 нче фаза. Көн озынлыгы 17.22 сәгать.***

Үз-үзеңне танып-белү, уйлану, буйсыну, кичерү көне. Өйдә булырга тырышырга, гаиләгә игътибарны арттырырга кирәк. Тәкәбберлек күрсәтергә ярамый. Яңа белем җиңел үзләштерелә. Нерв системасы, сизү әгъзалары, кан тамырлары, ашказаны зәгыйфь.

Миомадан дәва

Миоманы дәвалау өчен, даруханәдә сатыла торган гинекологик җыелманың (аңа ромашка чәчәге, каз (бәбкә) үләне, мелисса, меңъяфрак, мәтрүшкә үләннәре, кычыткан яфрагы керә) 2 аш кашыгын ярты литр кайнар суга салып, сәгать ярым төнәтәләр, көненә 3 тапкыр, ашарга ярты сәгать кала, яртышар стакан эчәләр. Барлыгы 200-300 грамм гинекологик җыелма кирәк булачак.

9 июнь (җомга). ***Зөлкагдә аеның 20нче көне. 21 нче Ай тәүлеге. Ай Сукояр йолдызлыгында,1.18 сәгатьтә калка, 9.34 сәгатьтә бата. 3 нче фаза. Көн озынлыгы 17.23 сәгать.***

Сәяхәткә чыгу, теләсә нинди эш башлау өчен айның иң кулай көне. Кеше хәлиткеч карарлар кабул итәргә сәләтле. Физик эш белән шөгыльләнү, җәяү йөрү, чыныгу файдалы. Саф һавада күбрәк булу, табигать белән хозурлану кәефне күтәрә. Умырткалыкның аскы өлеше, әвернә сөяк, аяк зәгыйфь.

Витаминлы салат

Иммунитетны ныгыта торган салат бу. Пешкән тавык итен юка телемләп турап, яшел салат һәм шпинат яфраклары, кырылган кишер, вак итеп туралган яшел укроп һәм петрушка, алма, әфлисун кушалар, тоз сибәләр. Лимон согы һәм зәйтүн мае сибеп, болгаталар.

Хәмер һәм комарның тыелуы

Билгеле булганча, хәмер һәм комар (отышлы уеннар) турындагы хөкемнәр исламның беренче елларында әйтелми, аерым бер шартлар белән соңгарак калдырыла. Хәмернең хәрәм дип билгеләнүе түбәндәге этаплардан соң тормышка ашырыла:

1. Мәккәдә: «Хөрмә һәм йөземнән исерткеч хәмер дә, яхшы ризыклар да ясый аласыз. Шөбһәсез, монда акылын кулланучы затлар өчен алыр сабак бар», – аяти кәримәсе («Ән-Нәхел», 67) индерелә. Бу аятьтә хөрмә һәм йөземнән, яхшы ризыклардан аермалы буларак, исерткеч матдә дә ясалуы белдерелә. Шул рәвешле исерткеч тәэсир бирә торган нәрсәләрнең күркәм һәм дин тарафыннан кабул ителерлек эчемлек саналмаганлыгын сиздереп, аның киләчәктә тыелачагына ишарә ясала. Мәккә чорында хәмер турында башка аять индерелми.

2. Мөхәммәд Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм Мәдинәгә һиҗрәт кылгач, кешеләрнең сораулары белән бәйле рәвештә Аллаһ Тәгалә болай дип ачыклый: «Синнән хәмер һәм комар турында сорарлар. Әйт: «Аларда зур гөнаһ та, кешеләр өчен бер өлеш файдалар да бар. Ләкин икесенең дә гөнаһы файдаларыннан зуррак…» («Әл-Бәкара», 219).

Әлеге аять иңгәч, мөселманнарның күпчелеге хәмерне ташлый, бер өлеше исә эчүен дәвам итә.

3. Әсхәбе кирамнан берәү, ахшам намазын алып барганда, бер аятьне мәгънәсе бозылырлык дәрәҗәдә ялгыш укый. Шуннан соң: «Әй иман ияләре! Сез исерек икән, ни сөйләгәнегезне белә башламыйча, намазга якын килмәгез!..» – дигән («Ән-Ниса», 43) аять иңә.

Әнә шуннан соң мөселманнар арасында хәмер эчүчеләр шактый азая. Намаз укыр вакыт җиткәч, Аллаһ Рәсүленең сөрәнчесе: «Сәрхушләр һичничек намазга якын килмәсен!» – дип кычкыра. Мөселманнар инде хәмернең катгый рәвештә тыелачагын аңлыйлар һәм моңа әзер булалар.

4. Ахыр нәтиҗәдә мөселманнарның күп өлеше хәмерне ташлый. Кайберләре исә хәмер аркасында үзләре тарыган тискәре хәлләрдән интеккән була. Хәзрәти Гомәр радыйаллаһу ганһе: «Аллаһым! Хәмер турында безгә анык һәм катгый бер аңлатма бир!» – дип дога укый. Ниһаять, бер хәмер мәҗлесеннән соң купкан бәхәс-ызгыш белән хәмернең начарлыгы тагын да ачыкланып, бу мәсьәләдәге тыю бик җиңел аңлатып бирү өчен нигез тапкач, әлеге вәзгыять аять иңү өчен бер сәбәпкә әйләнеп, илаһи тыю барлыкка килде. Аллаһ Тәгалә: «Әй иман ияләре! Шәраб, комар, бастырылган ташлар (потлар), фал һәм бәхетле очрак уклары – шайтан эше, әшәкелек ул. Болардан ерак булыгыз, бәхеткә тиенерсез. Шайтан хәмер һәм комар юлы белән бары арагызга дошманлык һәм ачу кертергә; сезне Аллаһны зикер итүдән һәм намаздан аерырга тели. Инде баш тарттыгыз түгелме?» – аятьләрен («Әл-Маидә», 90-91) иңдерә.

Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм хәзрәти Гомәрне чакырып, аңа шушы аятьләрне укый. «Инде баш тарттыгыз түгелме?» дигән өлешенә җиткәч, Гомәр: «Баш тарттык! Баш тарттык, йә Раббы!» – дип әйтә. Хәзрәти Гомәр радыйаллаһу ганһе генә түгел, барлык мөселманнар да: «Инде хәмердән, комардан баш тарттык, йә Раббыбыз!» – диләр.

Бу аятьләр иңгәч, Рәсүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм кушканча, аның бер сөрәнчесе: «Белеп торыгыз, хәмер хәрәм кылынды!» – дип хәбәр сала. Турсыкларны тишеп бушатылган, кувшиннарны ватып түгелгән хәмерләр Мәдинә урамнарында сәлләр сыман ага!..

Хәмер эчүче мөселманнар әлеге тыю аятеннән соң кулларындагы шәрабләренең барысын да юк итәләр. Башка бер тапкыр да эчмиләр. Соңрак Әфәндебез: «Һичшиксез, Аллаһ хәмерне, аны хәзерләүчене, ул хәзерләнә торган җирне, эчүчене, эчерүчене, ташучыны, сатучыны, сатып алучыны, шуны сатып алган акчага һәм шуннан алган керемгә ашап-эчүчене ләгънәт кылды!» – дип белдерә.

Әнәс радыйаллаһу ганһе болай дип тапшыра: «Әбү Тальха өендә кешеләргә шәраб салган чагымда хәмер хәрәм кылынды. Аллаһ Рәсүле бер сөрәнчегә әмер бирде, ә ул исә кешеләргә хәбәр итте. Без өйдә вакытта сөрәнче тавышы ишетелде. Әбү Тальха: «Чыгып кара әле, нинди тавыш ул?» – диде. Чыгып күз салдым һәм: «Бер нидачы: «Игътибар, игътибар: хәмер хәрәм кылынды!» – дип сөрән сала», – дип әйттем. Миңа: «Алайса бар, моны түк!» – диде. Шул мизгелдән башлап Мәдинә урамнарыннан хәмер акты».

Әлеге вакыйга – әсхәбе кирамның Аллаһ Тәгалә кушканга буйсынудагы үз-үзләренә карата таләпчәнлегенә бик матур бер үрнәк. Бернинди дә протест һәм кирелек белдермичә, сылтау-аклану эзләмичә, кулларындагы хәмер кувшиннарын һәм турсыкларын шундук түгәләр, бу илаһи әмергә карата бик зур буйсынучанлык һәм ихлас итагатьлек күрсәтеп, Аллаһ ризалыгын алырга ашыгалар.

﴿ يَٰٓأَيُّهَا ٱلَّذِينَ ءَامَنُوٓاْ إِنَّمَا ٱلۡخَمۡرُ وَٱلۡمَيۡسِرُ وَٱلۡأَنصَابُ وَٱلۡأَزۡلَٰمُ رِجۡسٞ مِّنۡ عَمَلِ ٱلشَّيۡطَٰنِ فَٱجۡتَنِبُوهُ لَعَلَّكُمۡ تُفۡلِحُونَ ٩٠ إِنَّمَا يُرِيدُ ٱلشَّيۡطَٰنُ أَن يُوقِعَ بَيۡنَكُمُ ٱلۡعَدَٰوَةَ وَٱلۡبَغۡضَآءَ فِي ٱلۡخَمۡرِ وَٱلۡمَيۡسِرِ وَيَصُدَّكُمۡ عَن ذِكۡرِ ٱللَّهِ وَعَنِ ٱلصَّلَوٰةِۖ فَهَلۡ أَنتُم مُّنتَهُونَ ٩١ ﴾ (المائدة/٥: ٩١-٩٠)

Ислам тәблигы һәм миссионерлык

Исламда тәблигъ һәм туры юлга кертү максаты – хак диннең кешеләргә җиткерелүе. Кешеләрне көч белән һәм теләсә нинди юл кулланып мөселманлаштыру күз уңында тотылмый.

Нәсара миссионерлыгы исә адресатларының теләсә нинди очракта да христианлашуын һәм чукындырылуын максат итеп куя. Миссионерлар үрнәк итеп алган Павел бер хатында эш-гамәл рәвешен менә болай тасвирлый: «Мин ирекле зат, һичкемнең колы түгелмен. Әмма тагын да күбрәк кешене яулап алыйм дип, һәркемнең колы булдым. Яһүдиләрне яулап алу өчен, яһүдиләргә яһүди кебек мөнәсәбәт күрсәттем. Үзем шәригатьне үтәмәсәм дә, шәригатьчеләрне яулап алу өчен, аларга, имеш, үземне шәригатькә буйсынган кебек тоттым. Гайсә Мәсих кануннарына ияртмәвемә карамастан, канунсызларны яулап алу өчен, үземне канунсыз зат кебек тоттым. Зәгыйфьләрне карату өчен, алар белән бергә зәгыйфь булдым. Ничек тә кайберләрне коткару өчен, һәркем белән һәр төрле рәвешкә кердем». («Коринфлеләргә хат» I, 9:19-22.)

Күренгәнчә, максатына ирешү өчен, Павел һичбер кагыйдә һәм чикләрне белмичә, һәр төрле ысул-чара куллануны дөрес дип тапкан. Ә исламда дини максатларда шәригатькә каршы килә торган чаралардан файдалану тыела. Христиан дине шундый ялгыш ысулны үз итә, ягъни гавамнарга илаһи хәбәрләрне ирештерү бәрабәренә, нинди бәһага булса булсын, диннең асылы бозылуга, юкка чыгуга китерә, илаһи хәбәр килгән һәр җирдә аңа үзгәреш кертелеп, бу үзгәртүләр акрынлап диннең шул тирәдәге аерым төркемнәргә әйләнүенә сәбәп була.

Христианлаштыру эшендә миссионерларның иҗтимагый һәм сәяси күзлектән авыр хәлдә булган гавамнарга, фәкыйрь кешеләргә, мөһаҗирләргә, азчылык халыкларга, сугыш һәм табигый афәтләргә тарыган кешеләргә якынаеп, бу бәндәләрнең матди һәм рухи авырлыкларын нәсара дине файдасына кулланып, аларның иманнарын чын-чынлап сатып алырга тырышуы күзәтелә.

Икенче яктан миссионерлыкның империализм белән ага-эне кебек якын булуы, максатның динилектән бигрәк сәяси эчтәлек алуы да билгеле. Миссионерлар максат итеп алган дәүләткә килеп, шунда мәктәпләр, чит тел курслары һәм башка шундый эшчәнлек артына яшеренеп, кешеләрне христианлаштырырга тырыша.

Төрле дини агымнарга, секталарга өндәүче хәзерге заман миссионерлары «кыланып эш йөртә», ягъни асылда кем буларын яшереп, адресатына ошаячак бер кыяфәттә күренүне нигез итеп ала. Мәсәлән, дингә тарту максаты куеп, мөселманнарга хуш, яхшы булып күренү өчен, Коръәннән аятьләр уку, мөселман киемнәрен киеп йөрү, «атакай» кебек атамалар урынына – «оста», «хуҗа»; «чиркәү» урынына – «мәчет» кебек ислами терминнар куллану кебек ысуллардан файдаланалар. Кешеләрне диннәреннән яздыру һәм үзләренә карата яхшы мөнәсәбәт уяту өчен, бик күп төрле алдауларга баралар.

Рәсми нәсара диненә һич катнашы булмаган андый миссионерларның бу кадәр актив, кызу эш йөртүенә каршы мөселманнар да үзләрен һәм балаларын тәрбияләүгә әһәмият бирергә, исламны иң күркәм рәвештә өйрәнеп, шуның белән яшәргә һәм башка кешеләргә дә җиткерергә тырышырга тиеш. Диннәрен таратыр өчен шундый тырышлык сарыф иткән миссионерлардан мөселманнарның, иң ким дигәндә, гыйбрәт алуы, хак ислам дине белән яшәп тәблигъ эшенә көч салуы кирәк. Чөнки түләп бетерә алмаслык ислам нигъмәтен тәблигъ кылу җаваплылыгы турында онытмау зарур.

Үрнәк затларыбыз – янәшәдә

Нинди дә булса телнең юкка чыгуы кешелек мирасы кисәкчәләрен югалту, дигән сүз ул. Бу өлкәдә язучыларыбыз, мәдәният хезмәткәрләре, укытучылар гаять зур эшләр башкара. Мин шуларның берничәсенә тукталып үтәсем килә. Соңгы биш елда (2018 елдан) Рафаил Газиз исемендәге төбәкара әдәби конкурс уздырыла. Конкурсны оештыручылар – Татарстан Язучылар берлеге, Мамадыш муниципаль районы һәм районның мәдәният бүлеге, мәгариф бүлеге, Мамадыш районы үзәкләштерелгән китапханәләр системасы.

Укучылар яшь категорияләре буенча проза, поэзия, әкиятләр, драма номинацияләрендә көч сынашты. Конкурсның максаты: укучыларның иҗади сәләтләрен үстерү, туган телебезгә, туган җиребезгә мәхәббәт тәрбияләү һәм балаларның иҗатын пропагандалау.

Төрле төбәктән конкурска килгән укучы балаларның иҗади эшләре белән танышканнан соң күңел сөенә. Киләчәк буында очкын бар. Кабызып кына җибәрергә кирәк. Яр Чаллы, Казан, Балык Бистәсе, Бөгелмә, Алабуга, Зәй, гомумән, Татарстанның һәр почмагыннан дип әйтерлек эшләр булуы куандырды. Әҗюри составында Факил Сафин, Вахит Имамов, Вәрис Гали кебек мәртәбәле язучылар. Районыбыздан Кече Кирмән мәктәбе укучысы Әмир Фархуллинның, Бөгелмә лицей-интернатында белем алучы Энҗе Садриева, Дүсмәт мәктәбеннән Инзилә Салихова, Энҗе Мөбәрәкҗанова, Диләрә Нафикова, Көек-Ерыксадан Искәндәр Зиннуров, Алинә Сәхәбиева, Алсу Нуриева... Һәркем Тукай, Галимҗан Ибраһимовлар биеклегенә ирешә алмас, билгеле. Ләкин иҗади сәләте белән аерылып торучыларга аны үстерү юнәлешен күрергә, калганнарга сәнгати иҗатларына ярдәм итми калмас.

Якташыбыз Рафаил Газизов – татар халкының сөекле улы. Шагыйрь – чын татар ир-егете. Ул татар булуы белән горурлана, халкы язмышы өчен борчыла. Бу – укучылар фикере, халкым фикере. Гомере буе туган җирендә яшәп иҗат итүче шагыйрь. Татарстанның атказанган мәгариф һәм мәдәният хезмәткәре, Россия халык мәгарифе отличнигы, 45 ел буе балаларга белем бирде. Мәктәп директоры вазыйфаларын башкарган шәхес. Әсәрләрен укый башласаң, тиз генә аерылырмын димә. Димәк, яшь буынга үрнәк шәхес.

Якташ язучыбыз Вәрис Галинең иҗади мирасын өйрәнү, пропагандалау максатыннан, «Вәрис Гали укулары» да гөрләп узды. Укучыларны, укытучыларны, гомумән, райондашларыбызны фәнни-тикшеренү эшенә тарту, матур әдәбият аша туган илгә, туган телгә, милләтебезгә хөрмәт тәрбияләү алгы планга куелган иде. Катнашучыларның географиясе районыбыз белән генә чикләнмәде. Урта Кирмән, Көек-Ерыкса, Дүсмәт, Кече Кирмән, Үсәли, Түбән Кама, Алабуга, Шәмәк, Түбән Ушма, Казан, Балык Бистәсе һәм башка төбәкләрдән укучылар, укытучылар, китапханәчеләр катнашты. Укулар Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты раслаган нигезләмә нигезендә үткәрелде. Гран-прига Урта Кирмән укытучысы Ринат Хәйруллин лаек булса, Көек-Ерыксадан Гөлзирә Гыйләҗева, Гөлназ Гәрәева, Югары Ушмадан Ленуза Мөхәрләмоваларның эшләренә сокланмый мөмкин түгел. Кече Кирмән, Дүсмәт, Үсәли мәктәбе укучыларының эшләре югары бәяләнде.

Кече Кирмәннең үз юлыннан баручы асыл ир-егетләреннән берсе – Вәрис әфәнде. Менә ничә еллар үз халкына армый-талмый хезмәт итә. «Яхшылык эшлә дә суга сал, халык күрмәсә балык күрер», – ди халык. Һәр туар таңны шатланып каршылый ул. Кешеләргә ярдәме тисә, сөенә. Игътибар иткәнем бар: тыйнак кына йөзеннән елмаю балкып китә. Бу – күңел халәте. Шапырынмый да, мактанмый да, сөйләнми дә...

Рафаил Газиз, Вәрис Гали кебек туган туфрагына гашыйк һәм аннан аерылмыйча халкына хезмәт итүче затларыбыз күбрәк булса иде!

Рәсимә ГАЛИЕВА,
Мамадыш районының
Яңа Комазан авылы.

● **Мамадыш районының «Балалар һәм яшүсмерләр йорты» өстәмә белем бирү учреждениесе сайтыннан алынды.**

Г.КАМАЛ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ АКАДЕМИЯ ТЕАТРЫ

2 июнь – «Болганчык еллар. Мөһаҗирләр» (М.Галәү).
3 июнь – 15.00 Шәрык клубында – Балалар өчен рәсем буенча осталык дәресе. 18.00 – «Сөясеңме, сөймисеңме...» (Ф. Бүләков).
4 июнь – «Көл» (К.Митани).
5 июнь – «Школа драматического искусства» театрының «Вишневый сад» спектакле (А.Чехов).
6 июнь – 14.00 – Үзбәкстанның Сырдарья музыка драма театрының «Анам кыры» спектакле (Ч.Айтматов). 19.00 – «Рәшә» (Ә.Еники).
7 июнь – 16.00 – Кыргызстанның Нарын шәһәреннән М.Рыскулов исемендәге музыка драма театрының «Беренче мөгаллим» спектакле (Ч.Айтматов). 19.00 – Х.Нурадилов исемендәге Чечен дәүләт театрының «Таулардан биегрәк» спектакле (М.Әхмәдов).
8 июнь – Шәрык клубы янында ачык һавада «Яңа» театр оркестры концерты. Зур залда – Тыва республикасының В.Кок-оол исемендәге музыка драма театры башкаруында «Шаман кызы» спектакле (С.Монгуш). Кече залда – М.Гафури исемендәге Башкорт драма театры башкаруында «Җиде буын. Яшьләр» спектакле.
9 июнь – «Болганчык еллар. Мөһаҗирләр» (М.Галәү).

М.ҖӘЛИЛ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ОПЕРА ҺӘМ БАЛЕТ АКАДЕМИЯ ТЕАТРЫ

4 июнь – «Любовный напиток» (Г.Доницетти).
9 июнь – «Севильский цирюльник» (Дж.Россини).

К.ТИНЧУРИН ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ДРАМА ҺӘМ КОМЕДИЯ ТЕАТРЫ

2 июнь – «Хыялый» (С.Әбүзәров).
4 июнь – «Эх, алмагачлары!» (Ш.Фәрхетдинов).
5 июнь – «Яратам! Бетте-китте!»
6 июнь – Адыгея Республикасы Майкоп шәһәреннән театраль берләшмәнең «Бәхет җайдагы» спектакле (Т.Дербе).
7 июнь – Дагстанның А.Салаватов исемендәге Кумык музыка драма театры башкаруында «Диңгез буеннан чапкан ала эт» спектакле (Ч.Айтматов).
9 июнь – «Идегәй» (халык дастанына нигезләнгән).

Г.КАРИЕВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ЯШЬ ТАМАШАЧЫ ТЕАТРЫ

6 июнь – Алтай Республикасының П.Кучияк исемендәге милли драма театры башкаруында «Көймәче» спектакле (А.Мамадаков).
7 июнь – Казахстанның Астана шәһәреннән «А.И.» театры башкаруында «Сад» (А.Чехов).
8 июнь – Кабардино-Балкариянең Нальчик шәһәреннән К.Кулиев исемендәге Балкар дәүләт драма театры башкаруында «Антигона» спектакле.
9 июнь – «Йосыф» (Кол Гали).

«ӘКИЯТ» ТАТАР ДӘҮЛӘТ КУРЧАК ТЕАТРЫ

2 июнь – 11.00 – «Страна чудес Алисы» (Л.Кэрролл әкиятенә нигезләнгән).18.30 зур залда – «Әлдермештән Әлмәндәр» (Т.Миңнуллин). 19.00 кече залда – «Макбет» (У.Шекспир) (курчак театры артисты белгечлегенә укучы студентларның диплом спектакле).
3 июнь – зур залда – «Волшебник Изумрудного города» (А.Волков). Кече залда – «Су анасы» (Г.Тукай).
4 июнь – Фойеда – «Бобровый пруд». Зур залда – «Гуси-лебеди» (Л.Кожевников). Кече залда – «Камыр батыр» (С.Хөсни).
5 июнь – «Адәмнәр» (Г.Ибраһимов).
6 июнь – «Сказка о царе Салтане» (А.Пушкин).
7 июнь – «Бахром и Дилором» (А.Нәваи).
8 июнь – «Волшебная свирель Ацамаза».
9 июнь – 12.00 – «Три солнца». 18.30 – «Адәмнәр» (Г.Ибраһимов).

Г.ТУКАЙ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ФИЛАРМОНИЯСЕНЕҢ КОНЦЕРТ ЗАЛЫ

2 июнь – «Васса» спектакле.
6 июнь – Ольга Кабо катнашында «Мастер и Маргарита» спектакле.

С.СӘЙДӘШЕВ ИСЕМЕНДӘГЕ ДӘҮЛӘТ ЗУР КОНЦЕРТ ЗАЛЫ

2 июнь – Татарстан Республикасы дәүләт симфоник оркестры концерты. Дирижер – А.Сладковский. Солистлар – Д.Алиева һәм Б.Давронов.
3 июнь – М.Горький хикәяләре һәм Э.Григ әсәрләренә нигезләнгән «Кешенең туусы» исемле концерт-тамаша. Катнашалар – Е.Миронов, Ю.Башмет, А.Урсуляк, «Солисты Москвы» һәм «Комонь» ансамбльләре.

Иң катлаулы ун тел

Хәзер дөньяда 6 мең төрле тел бар. Аларның кайберләре өйрәнү өчен бик җиңел, кайсылары исә бик катлаулы. Мәсәлән, Амазонка бассейнында яшәүче туюка һиндиләре телендә исемнәрнең 50 дән 140 кадәр классы бар, анда бер сүз тулы бер гыйбарәне аңлатырга мөмкин. Абхаз телендә нибары өч сузык, 58 тартык, бзыб диалектында исә 67 тартык аваз бар. Африканың көньягындагы Калахари чүле янәшәсендә яшәүче койсан халкы – 370 мең кеше - үзара тел шартлатып сөйләшә. Фин телендәге унбиш килешне һәм фигыльнең йөздән артык төрле формасын истә калдыру да бик катлаулы. Алар әле фигыльне исем кебек төрләндерә дә! Әмма җиңелләкләр дә бар: сүз ничек әйтелә, шулай языла да; басым һәрвакыт беренче иҗеккә төшә; фигыльнең киләчәк заманы юк. 1994 елда төзелгән кытай теле сүзлегенә исә 85 568 иероглиф кертелгән. Укырга өйрәнер өчен, кимендә 1500 иероглифны ятларга кирәк. Аларның кайберләренең язылышы бик катлаулы. Мәсәлән, “томау төшкән борын”ны аңлаткан “нан” билгесендә 36 сызык, “лыгырдавык”ны аңлаткан “се” иероглифында 64 сызык бар! Америкадагы фигыль формалары 6 меңнән артыграк булган чиппева һиндиләре телендәге ике сүзне без дә беләбез – вигвам һәм тотем нәкъ шул халыктан күчкән. Эскимос телендә хәзерге заманның 63 формасы, гади исемнәрнең 252 флексиясе бар. Дагстандагы табасаран телендә 44-52 килеш, 54 хәреф һәм 10 сүз төркеме исәпләнә. Америкадагы навахо һиндиләренең берничә тонлы теле Бөек Ватан сугышы вакытында шифрланган хәбәрләр җибәрүдә кулланылган, мәсәлән, Гитлерны алар “поса-таи-во” – “акылдан язган ак кеше” дип атаган. Баск телендә исә хәзер якынча 700 мең кеше сөйләшә. Ул агглютинатив тел – яңа сүзләр суффикс һәм префикслар ярдәмендә ясала, аларның һәркайсы берәр генә мәгънәгә ия.

(“The Local”).

Келәмнәр патшасы

Дөньяда иң зур келәмнең мәйданы 5627 квадрат метр тәшкил итә. Аны Иранда 1200 тукучы бер ел буе кулдан тукыган, аларның һәркайсына 1 миллион 160 шар мең төен ясарга туры килгән. Иңе – 48, буе – 133 метрлы искиткеч матур йон келәмнең авырлыгы 48 тоннага тәңгәл. Аны Берләшкән Гарәп Әмирлекләренең Әбү-Даби шәһәрендәге берьюлы 7 мең кеше сыйдырышлы Зәед мәчете өчен махсус тукыганнар. Тугыз аерым кисәкне самолетта алып килеп, бизәкләрен туры китереп, мәчет эчендә бер-берсенә теккәннәр. Келәм 8,2 миллион долларга төшкән, тукучыларның барысына бергә 2 миллион 300 мең доллар акча түләнгән, алар аны тигезләп бүлгән. Фарсы келәмнәре дөньяда иң матурлардан санала, планетадагы барлык келәмнәрнең дүрттән өчесе Иранда җитештерелә. Гигантлык белән мавыгучы гарәп шәехләре исә тагын берничә зур келәмгә заказ биргән. Тарихта мондый гигант тукучылык җәүһәрләре мәгълүм инде: берничә тонна авырлыктагы легендар “Язгы” келәм фарсыларның римлеләрне җиңеп Гарәп ярымутравын яулавы хөрмәтенә иңе – 30, буе 122 метрлы итеп тукылган булган. Уникенче гасыр уртасында Персиягә гарәпләр һөҗүм иткәч, солдатлар, затлы келәмне кискәләп, ганимәт (трофей) итеп үзләре белән алып киткән.

(“Goldengod.ru”).

Көн саен – 30 тәмәке

Непалдан Батули Ламичхане 17 яшендә тартырга өйрәнгән һәм 112 яшендә бакыйлыкка күчкәнче һаман паровоз кебек төтәткән. Батули эшкәртелмәгән тәмәкене хөрмә яфрагына төреп, көн саен 30 тәмәке-биди ясый һәм шуны тәүлек буена тартып бетерә торган булган. Биди төтенендә никотин һәм сумала гади тәмәкедәгедән күбрәк, тик бу карчыкны бер дә куркытмаган. “Мин 95 елдан артыграк тартам инде. Диетаның һәм тәмәкенең гомер озынлыгына бер катнашы да юк. Иң мөһиме – стрессыз яшәү. Активрак булырга, картайгач та күп хәрәкәтләнергә кирәк. Әгәр син һәрвакыт бәхетле икәнсең, димәк, гомерең дә озын була”, – дигән Батули соңгы әңгәмәләренең берсендә.

(“Fishki.net”).

● «Ариан-5» ракета йөрткече космоска «JUICE»зондын чыгара.

Юпитерны өйрәнәчәкләр

Юпитер – Кояш системасындагы иң зур һәм авыр планета. Радиусы Җирнекеннән 11 тапкыр озынрак һәм 71 мең километр тәшкил итә, массасы 318 тапкырга авыррак. Шул ук вакытта ул Кояштан 1050 тапкырга җиңелрәк. Әгәр массасы 50 тапкырга артыграк булса, ул үзе дә көрән кәрлә йолдыз булыр иде. Үз күчәре тирәсендә Юпитер башка планеталардан тизрәк әйләнә, анда көн озынлыгы 9 сәгать 50 минут 30 секунд тәшкил итә. Кояш тирәсендә исә акрын әйләнә, андагы ел Җирдәге 12 елга тәңгәл. Магнит кыры Җирнекеннән 20 мең тапкырга куәтлерәк. Юпитерның 79 иярчене бар. Быел 14 апрельдә Европа космос агентлыгы Юпитерга JUICE планетаара станциясен җибәрде. Ул аның орбитасына 2031 елда барып җитәчәк һәм 2034 елга кадәр әлеге планетаның дүрт иярченен – Ио, Европа, Ганимед һәм Каллистоны өйрәнәчәк.

(“Живой Космос”).

● «JUICE» зондының төп антеннасы.

Һәр көнен хәтерли

Калифорниядә яшәүче 45 яшьлек Джилл Прайс искиткеч хәтере белән таң калдыра. Ул үзенә 12 яшь тулганнан бирле гомерендәге һәр вакыйганы хронологик тәртиптә хәтерли. Датаны атауга, хатын-кыз аның атнаның кайсы көне икәнен әйтә, аннары шул көнне булган нәрсәләрне бөтен вактөяге белән – дөньяда ниләр булган, телевизордан нинди программа караган – тәфсилләп сөйләп бирә. Күп кеше әлеге суперхәтергә кызыкса да, бу бер дә көнләшерлек сәләт түгел – инде күптән булган вакыйгаларны кабат-кабат яңадан кичерү дә бик алҗыта икән, әмма табибләр Джиллга берничек тә ярдәм итә алмый.

(“Лента.ру”).

Гипноз көче

16 яшеннән бирле үз-үзен гипнозлау белән шөгыльләнүче инглиз Алекс Ленкей, традицион наркоздан баш тартып, остеоартриттан хирургик операция ясатканда үз-үзен гипнозлаган. 83 минут дәвам иткән операция вакытында Алексның беләген ярып, чикләвек зурлыгындагы сөяген кисеп алганнар, сеңерен теккәннәр. Ул бу вакытта хирург сөйләгәнне дә, сөяк кискән тавышны да ишеткән, әмма берниндиә дә авырту сизмәгән. Элегрәк Алекс Ленкейны гипнозлап бүсерен алган булганнар инде, бервакыт исә ул, улының кулы сынгач, аны гипнозлап, авыртуын баскан.

(“Интересно.cc”).

Газета өчен Алсу ЗӘЙДУЛЛИНА әзерләде.

Дүшәмбе

5 июнь

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Онытa алмыйм...» 12+
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 16+
6.00, 7.10 «Манзара». 16+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 16+
8.10 «Здравствуйте!» 16+
9.00, 16.30 «АК ЧӘЧӘКЛӘР». 16+
10.00, 23.00 «ЛЕСТНИЦА В НЕБЕСА». 16+
11.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 16+
11.30, 21.00 «Заман көзгесе». 6+
12.00, 22.10 «СЕБЕР КИЯВЕ». 16+
13.00 «Семь дней». 16+
14.00 «Закон. Парламент. Общество». 16+
14.45 «Музыкаль мәйдан». 16+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә». «Акыл батл».
16.00 «Переведи!» 6+
17.30 «Татарстан без коррупции». 16+
19.00, 0.25 «Таяну ноктасы». 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112». 16+
20.15 «Күчтәнәч».

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.00 «Мәңгелек... Ирек... Хисләр...» Ирек Баһманов турында телеочерк. 16+
6.00, 13.05 «Манзара». 16+
8.00, 0.40 «Үткәннәр сагындыра». 12+
8.40, 18.20, 23.10 «Башваткыч». 12+
9.50 «Семь дней». 16+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 16+
11.30 «Туган җир». 12+
12.05 «Җилдергән җитез җилләрдә». Илдар Хәйруллин турында телеочерк. 16+
15.25 «Әдәби хәзинә». 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
16.30 «Адымнар». 16+
17.00, 19.10 «Музыкаль мәйдан». 16+
17.30 «Яшьләр тукталышы». 6+
19.30 «Калеб». 6+
20.00 «Заман көзгесе». 6+
20.30 «Таяну ноктасы». 16+
21.25 «Әниемнең җылы кочагы». 16+
22.15 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 12+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «ТАКАЯ РАБОТА - 2». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30 «ОСТРОВ ИСПРАВЛЕНИЯ». 12+
11.00 «Наукограды». 12+
11.30 «АКАДЕМИЯ». 12+
12.30, 18.30 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.45 «ИСЧЕЗНУВШАЯ». 16+
14.45 «Пять причин поехать...» 12+
15.00 «Ядовитые твари». 12+
15.30 «Шифры нашего тела. Неизвестные органы. Гипоталамус. Гипофиз. Эпифиз». 12+
16.20 «ПРАКТИКА-2». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
18.50 «Короче говоря». 16+
20.00 «РАСПЛАТА». 12+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
9.55 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 16.50, 18.20 Информационный канал. 16+
16.00 «Мужское/Женское». 16+
19.50 «Куклы наследника Тутти». 16+
21.00 «Время».
22.00 «ТРЕЙДЕР». 16+
23.00 «Большая игра». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
16.30 «Малахов». 16+
21.20 «ПАРОМЩИЦА. ДОЛИНА МЕЧТЫ». 12+
23.25 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30, 7.00, 10.00, 12.30, 17.00, 19.30 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 Невский ковчег. Теория невозможного. Граф Валентин Зубов.
7.30 «Игнатий Стеллецкий. Тайна подземных палат».
8.10 «Забытое ремесло».
8.25 «Жизнь и судьба».
8.50 «ГДЕ ВЫ, РЫЦАРИ?»
10.15 «Наблюдатель».
11.10 XX век. «Клуб путешественников. Замоскворечье».
12.10, 17.15 Книжный фестиваль «Красная площадь».
12.45 Новости. Подробно. АРТ.
13.00 «Царскосельская мечтательница».
13.30, 22.10 «И ЖИЗНЬ, И СЛЕЗЫ, И ЛЮБОВЬ».
15.10 Острова. Николай Губенко.
15.55 «Агора».
17.35 «Небесные ласточки». Моя милая Бабетта! Странно это, странно это!»
18.15 Российские пианисты XXI века. Александр Гиндин.
18.50 Цвет времени. Илья Репин. «Иван Грозный и сын его Иван».
19.00 «Почерк эпохи». «Сергей Образцов. «Бибабо».
19.45 Главная роль.
20.05 «Правила жизни».
20.30 «Спокойной ночи, малыши!»
20.45 Больше, чем любовь.
21.30 «Сати. Нескучная классика...»
23.50 «Магистр игры». «Заратустра НЭПа. Откровения и откровенность Остапа Бендера».

«НТВ»

5.00 «МОСКВА. ЦЕНТРАЛЬНЫЙ ОКРУГ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня».
8.25, 10.35 «ЛЕСНИК. СВОЯ ЗЕМЛЯ». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.50 «За гранью». 16+
17.55 «ДНК». 16+
20.00 «ВОЕННАЯ ПОЛИЦИЯ». 16+
22.15, 0.00 «РЕАЛИЗАЦИЯ». 16+

Сишәмбе

6 июнь

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Онытa алмыйм...» 12+
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 16+
6.00, 7.10 «Манзара». 16+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 16+
8.10 «Здравствуйте!» 16+
9.00, 17.00 «АК ЧӘЧӘКЛӘР». 16+
10.00, 23.00 «ЛЕСТНИЦА В НЕБЕСА». 16+
11.00 «Фолиант в столетнем переплёте». 16+
11.15 «Память сердца». 16+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00, 22.10 «СЕБЕР КИЯВЕ». 16+
13.00 «Туган җир». 12+
13.30 «Юлчы». 16+
14.00 «Путь». 16+
14.15 «Не от мира сего...» 16+
14.45 «Музыкаль мәйдан». 16+
15.15 «Төймә».
16.00, 21.00 «Ватандашлар». 16+
18.00 «Әдәби хәзинә». 16+
19.00 «Таяну ноктасы». 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112». 16+
20.15 «Күчтәнәч».

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
6.00, 13.05 «Манзара». 16+
8.00 «Үткәннәр сагындыра». 12+
8.40, 18.20, 23.10 «Җырлыйк әле!» 12+
9.40 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 16+
10.30 «Заман көзгесе». 6+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 16+
11.30 «Нәсыйхәт». 16+
12.05, 21.25 «Ком сәгате». 16+
15.25 «Әдәби хәзинә». 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
16.30, 20.30 «Таяну ноктасы». 16+
17.00, 19.10 «Музыкаль мәйдан». 16+
17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
20.00 «Халкым минем». 12+
22.20 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 12+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «ТАКАЯ РАБОТА - 2». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «РАСПЛАТА». 12+
11.30 «АКАДЕМИЯ». 12+
12.30, 18.30 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.45 «ИСЧЕЗНУВШАЯ». 16+
14.45 «Пять причин поехать...» 12+
15.00 «Ядовитые твари». 12+
15.30 «Шифры нашего тела. Неизвестные органы. Селезёнка. Тимус». 12+
16.20 «ПРАКТИКА-2». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
18.50 «Короче говоря». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
9.55 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 16.50, 18.20 Информационный канал. 16+
16.00 «Мужское/Женское». 16+
19.50 «Куклы наследника Тутти». 16+
21.00 «Время».
22.00 «ТРЕЙДЕР». 16+
23.00 «Большая игра». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
16.30 «Малахов». 16+
21.20 «ПАРОМЩИЦА. ДОЛИНА МЕЧТЫ». 12+
23.25 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30, 7.00, 10.00, 12.30, 17.00, 19.30 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 Легенды мирового кино.
7.30 «Легенды и мифы - величайшие тайны человечества. Великий потоп».
8.25 «Жизнь и судьба».
8.45, 22.10 «МЕТЕЛЬ».
10.15 «Наблюдатель».
11.15 XX век. «Взлет продолжается. 50-летию конструкторского бюро имени С.В.Ильюшина посвящается...»
12.20 Цвет времени. Николай Ге.
12.45 Новости. Подробно. Книги.
13.00 «Я женат и счастлив».
13.25 «Пушкин и судьбы русской культуры. Сказка о золотом петушке».
13.55 «Сказки Пушкина». Читает Олег Борисов.
14.55 «Пушкин и судьбы русской культуры. Пушкин и Петербург».
15.30 А.С. Пушкин. «Медный всадник». Читает Михаил Козаков.
16.00 «Пушкин и судьбы русской культуры. 19 октября».
16.30 «Секреты живой клетки».
17.15 «Эрмитаж».
17.45 «Звезда Фаины Раневской». Рассказывает Агриппина Стеклова.
18.00 Российские пианисты XXI века. Алексей Мельников.
18.50 Цвет времени. Павел Федотов.
19.00 «Почерк эпохи». «Рина Зелёная. За кадром...»
19.45 Главная роль.
20.05 «Правила жизни».
20.30 «Спокойной ночи, малыши!»
20.45 «Арам Хачатурян. Танец страсти».
21.25 «Белая студия».
23.25 Константин Райкин читает Александра Пушкина.
23.55 «Легенды и мифы - величайшие тайны человечества. Сокровища нибелунгов».

«НТВ»

5.00 «МОСКВА. ЦЕНТРАЛЬНЫЙ ОКРУГ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня».
8.25, 10.35 «ЛЕСНИК. СВОЯ ЗЕМЛЯ». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.50 «За гранью». 16+
17.55 «ДНК». 16+
20.00 «ВОЕННАЯ ПОЛИЦИЯ». 16+
22.15, 0.00 «РЕАЛИЗАЦИЯ». 16+

Чәршәмбе

7 июнь

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Онытa алмыйм...» 12+
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 16+
6.00, 7.10 «Манзара». 16+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 16+
8.10 «Здравствуйте!» 16+
9.00, 17.00 «АК ЧӘЧӘКЛӘР». 16+
10.00, 23.00 «ЛЕСТНИЦА В НЕБЕСА». 16+
11.00, 0.00 «Каравай». 6+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00, 22.10 «СЕБЕР КИЯВЕ». 16+
13.00 «Җырлыйк әле!» 12+
14.00 «Туган авылым». 12+
14.15 «Если хочешь быть здоровым». 16+
14.45 «Музыкаль мәйдан». 16+
15.15 «Бергәләп өйрәник».
15.45 «Татар сүзе». 6+
16.00 «Переведи!» 6+
18.00 «Халкым минем...». 12+
19.00, 0.50 «Таяну ноктасы». 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112». 16+
20.15 «Күчтәнәч».
21.00 «Чёрное озеро». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05, 8.40, 18.20, 23.10 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
6.00, 13.05 «Манзара». 16+
8.00 «Үткәннәр сагындыра». 12+
9.40 «Ирекле күбәләкләр». Луара Шакирҗанова турында телеочерк. 16+
10.40 «Туган авылым». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 16+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05, 21.25 «Кунак БИТ Шоу». 16+
15.25 «Әдәби хәзинә». 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
16.30, 20.30 «Таяну ноктасы». 16+
17.00, 19.10 «Музыкаль мәйдан». 16+
20.00 «Гаилә учагы». 16+
22.20 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 12+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «ТАКАЯ РАБОТА - 2». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «РАСПЛАТА». 12+
11.30 «АКАДЕМИЯ». 12+
12.30, 18.30 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.45 «ИСЧЕЗНУВШАЯ». 16+
14.45 «Пять причин поехать...» 12+
15.00 «Ядовитые твари». 12+
15.30 «Шифры нашего тела. Печень». 12+
16.20 «ПРАКТИКА-2». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
18.50 «Короче говоря». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
9.55 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 16.50, 18.20 Информационный канал. 16+
16.00 «Мужское/Женское». 16+
19.50 «Куклы наследника Тутти». 16+
21.00 «Время».
22.00 «ТРЕЙДЕР». 16+
23.00 «Большая игра». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
16.30 «Малахов». 16+
21.20 «ПАРОМЩИЦА. ДОЛИНА МЕЧТЫ». 12+
23.25 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30, 7.00, 10.00, 12.30, 17.00, 19.30 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 Легенды мирового кино.
7.30 «Легенды и мифы - величайшие тайны человечества. Сокровища нибелунгов».
8.25 «Жизнь и судьба».
8.45 «ПРИКЛЮЧЕНИЯ ТОМА СОЙЕРА И ГЕКЛЬБЕРРИ ФИННА».
10.15 «Наблюдатель».
11.10 XX век. «Творческий вечер Аркадия Арканова».
12.45 Новости. Подробно. Кино.
13.00 Поедем в Царское Село. «Плыть хочется».
13.25 Искусственный отбор.
14.05, 22.10 «9 ДНЕЙ ОДНОГО ГОДА».
15.50 «Татьяна Лаврова. «Я - чайка... Не то. Я - актриса».
16.30 «Секреты живой клетки».
17.15 «Библейский сюжет».
17.45 «Звезда Нины Алисовой». Рассказывает Екатерина Гусева.
18.00 Российские пианисты XXI века. Юрий Фаворин.
19.00 «Почерк эпохи». «Серж Лифарь. Бог танца».
19.45 Главная роль.
20.05 «Правила жизни».
20.30 «Спокойной ночи, малыши!»
20.45 Абсолютный слух.
21.30 «Я - чайка... Не то. Я - актриса».
23.55 «Армия строителей Древнего Рима».

«НТВ»

4.50 «МОСКВА. ЦЕНТРАЛЬНЫЙ ОКРУГ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня».
8.25, 10.35 «ЛЕСНИК. СВОЯ ЗЕМЛЯ». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.50 «За гранью». 16+
17.55 «ДНК». 16+
20.00 «ВОЕННАЯ ПОЛИЦИЯ». 16+
22.15, 0.00 «РЕАЛИЗАЦИЯ». 16+

Пәнҗешәмбе

8 июнь

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Онытa алмыйм...» 12+
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 16+
6.00, 7.10 «Манзара». 16+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 16+
8.10 «Здравствуйте!» 16+
9.00, 17.00 «АК ЧӘЧӘКЛӘР». 16+
10.00, 23.00 «ЛЕСТНИЦА В НЕБЕСА». 16+
11.00 «Каравай». 6+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00, 22.10 «СЕБЕР КИЯВЕ». 16+
13.00 «Кәмит Җәвит». 16+
14.00 «Туган авылым». 12+
14.45 «Музыкаль мәйдан». 16+
15.15 «Шома бас» һәм «Алты хәреф».
15.45 «Татар сүзе». 6+
16.00, 21.10, 0.50 «Соотечественники». 16+
18.00 «Юлчы». 16+
19.00, 20.00 «Точка опоры». 16+
21.00 «Погружение на 100». 12+
22.00 «Вызов 112». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
6.00, 13.05 «Манзара». 16+
8.00 «Үткәннәр сагындыра». 12+
8.40, 23.10 «Кәмит Җәвит». 16+
9.40 «Гаилә учагы». 16+
10.40 «Туган авылым». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 16+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05, 20.00 «Әниемнең җылы кочагы». 16+
15.25 «Әдәби хәзинә». 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
16.30 «Таяну ноктасы». 16+
17.00, 19.10 «Музыкаль мәйдан». 16+
18.20 «Кунак БИТ Шоу». 16+
21.25 «Кырыс җилле дала гөле». Гөлсем Исәнгулова турында телеочерк. 16+
22.20 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 12+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «ТАКАЯ РАБОТА - 2». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «РАСПЛАТА». 12+
11.30 «АКАДЕМИЯ». 12+
12.30, 18.30 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.45 «ИСЧЕЗНУВШАЯ». 16+
14.45 «Пять причин поехать...» 12+
15.00 «Ядовитые твари». 12+
15.30 «Шифры нашего тела. Сердце». 16+
16.20 «ПРАКТИКА-2». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
18.50 «Короче говоря». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
9.55 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 16.50, 18.20 Информационный канал. 16+
16.00 «Мужское/Женское». 16+

19.50 «Куклы наследника Тутти». 16+
21.00 «Время».
22.00 Специальный репортаж. 16+
23.00 «Большая игра». 16+

«РОССИЯ»
5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
16.30 «Малахов». 16+
21.20 «ПАРОМЩИЦА. ДОЛИНА МЕЧТЫ». 12+
23.25 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»
6.30, 7.00, 10.00, 12.30, 17.00, 19.30 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 Легенды мирового кино.
7.30 «Армия строителей Древнего Рима».
8.25 «Жизнь и судьба».
8.50 «ПРИКЛЮЧЕНИЯ ТОМА СОЙЕРА И ГЕКЛЬБЕРРИ ФИННА».
10.15 «Наблюдатель».
11.15 XX век. «Кинопанорама. Булат Окуджава».
12.15, 23.35 Цвет времени. Валентин Серов.
12.45 Новости. Подробно. Театр.
13.00 «Царскосельский арсенал».
13.30 Абсолютный слух.
14.10 «ПРОСТИ-ПРОЩАЙ».
15.25 Цвет времени. Караваджо.
15.45 Больше, чем любовь.
16.30 «Секреты живой клетки».
17.15 Моя любовь - Россия! «Песня - душа казака».
17.45 «Звезда Зои Фёдоровой». Рассказывает Катерина Шпица.
18.00 Российские пианисты XXI века. Николай Луганский.
19.00 «Почерк эпохи». «Валентин Катаев. Комедия положений...»
19.45 Главная роль.
20.05 «Правила жизни».
20.30 «Спокойной ночи, малыши!»
20.45 «Осенний марафон». Хорошо сидим».
21.30 «Энигма. Динара Алиева».
22.10 «ЗАПАСНОЙ ИГРОК».
23.50 «Неаполь. Жизнь на вулкане».

«НТВ»
4.55 «МОСКВА. ЦЕНТРАЛЬНЫЙ ОКРУГ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня».
8.25, 10.35 «ЛЕСНИК. СВОЯ ЗЕМЛЯ». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.50 «За гранью». 16+
17.55 «ДНК». 16+
20.00 «ВОЕННАЯ ПОЛИЦИЯ». 16+
22.15, 0.00 «РЕАЛИЗАЦИЯ». 16+

Җомга

9 июнь
«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»
5.35 «Оныта алмыйм...» 12+
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 16+
6.00, 7.10 «Манзара». 16+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 16+
8.10 «Здравствуйте!» 16+
9.00, 17.00 «АК ЧӘЧӘКЛӘР». 16+
10.00 «Йөрәктән - йөрәккә». 16+
11.00 «Нәсыйхәт». 16+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00 «Ком сәгате». 16+
13.00 «Башваткыч». 12+
14.00 «Актуальный ислам». 16+
14.15 «Здоровая семья: мама, папа и я». 12+
14.45 «Музыкаль мәйдан». 16+
15.15 «Тизрәк! Алга! Җитезрәк!» һәм «Алты хәреф».
16.00 «Әдәби хәзинә». 6+
18.00 «Туган җир». 12+
19.00 «Таяну ноктасы». 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112». 16+
20.15 «Көчтәнәч».
21.00 «Юлчы». 16+
22.10 «ПАРАЛЛЕЛЬНЫЕ МИРЫ». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА
5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
6.00, 13.05 «Манзара». 16+
8.00 «Үткәннәр сагындыра». 12+
8.50, 18.20, 23.10 «Ком сәгате». 16+
9.50, 16.30, 0.15 «Нәсыйхәт». 16+
10.30 «Яшьлектә калыйк әле». Зөлфия һәм Җәвит Шакиролар концерты. 6+
11.00, 15.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 16+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05, 21.25 «Уроки истории». 6+
15.25 «Әдәби хәзинә». 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
17.00, 19.10 «Музыкаль мәйдан». 16+
18.00 «Яңалыклар». 12+
20.00 «Туган җир». 12+
20.30 «Таяну ноктасы». 16+
22.10 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 12+

«ЭФИР»
5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «ТАКАЯ РАБОТА - 2». 16+
9.25, 11.25, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30 «РАСПЛАТА». 12+
11.30 «АКАДЕМИЯ». 12+
12.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00, 23.45 «ЗА КУЛИСАМИ». 16+
14.30 «Ученые люди». 12+
15.00 «Ядовитые твари». 12+
15.30 «Шифры нашего тела. Смех и слезы». 12+
16.20 «ПРАКТИКА-2». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
18.20 «Fam TV». 16+
18.50 «Короче говоря». 16+
20.00 «ОСТРОВ ВЕЗЕНИЯ». 12+
21.25 «Один день в городе». 12+

«1 НЧЕ КАНАЛ»
5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
9.55 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 16.50 Информационный канал. 16+
16.00 «Мужское/Женское». 16+
18.40 «Человек и закон». 16+
19.45 «Поле чудес».
21.00 «Время».
21.45 «Прими «Вызов» - почувствуй силу!» 12+

«РОССИЯ»
5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.15 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
16.30 «Прямой эфир». 16+
21.30 «Удивительные люди. Новый сезон». 12+
23.55 «Истории Большой Страны». 12+

«КУЛЬТУРА»
6.30, 7.00, 10.00, 12.30, 17.00, 19.30 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 Легенды мирового кино.
7.30 «Неаполь. Жизнь на вулкане».
8.25 «Жизнь и судьба».
8.45 Цвет времени. Карандаш.
8.50 «ПРИКЛЮЧЕНИЯ ТОМА СОЙЕРА И ГЕКЛЬБЕРРИ ФИННА».
10.15 «ДОНЕЦКИЕ ШАХТЕРЫ».
12.00 «Белоруссия. Коссовский замок».
12.45 Власть факта. «Накануне Петра».
13.30 «Счастливые дни счастливого человека».
14.10 «ЗАПАСНОЙ ИГРОК».
15.35 «Забытое ремесло».
15.50 «Энигма. Динара Алиева».
16.30 «Секреты живой клетки».
17.15 Письма из провинции.
17.45 Российские пианисты XXI века. Денис Мацуев.
18.45 «Царская ложа».
19.45 «Смехоностальгия».
20.15 К юбилею Ольги Свибловой. Линия жизни.
21.10 Искатели. «Почему не падает Невьянская башня?»
22.00 «2 Верник 2».
22.50 «МОСКВА, ЛЮБОВЬ МОЯ».

«НТВ»
4.55 «МОСКВА. ЦЕНТРАЛЬНЫЙ ОКРУГ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00 «Сегодня».
8.25, 10.35 «ЛЕСНИК. СВОЯ ЗЕМЛЯ». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.50 «ДНК». 16+
17.55 «Жди меня». 12+
20.00 «ВОЕННАЯ ПОЛИЦИЯ». 16+
22.15 «РЕАЛИЗАЦИЯ». 16+

Шимбә

10 июнь
«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»
5.35 «Оныта алмыйм...» 12+
6.00 «Йөрәктән - йөрәккә». 16+
7.00 «Сиңа Миннән Сәлам». 16+
9.00 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
10.00 «Кайнар хит». 16+
11.00 «Туган авылым». 12+
11.20 «Сула!» Ришат Төхвәтуллин концерты. 12+
12.00 «Каравай». 6+
12.30 «Видеоспорт». 16+
13.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 16+
13.30 «Гаилә учагы». 16+
14.00 «Шәрәфле Шәрәфи». Равил Шәрәфиевнең юбилей кичәсе. 12+
16.40 «Уроки истории». 6+
17.30 «Әдәби хәзинә». 6+
18.00 «Кәмит Җәвит». 16+
19.00 «Халкым минем...» 12+
19.30, 21.30 Новости в субботу. 16+
20.00 «Адымнар». 16+
20.30 «Җырлыйк әле!» 12+
22.00 «КунакБит-шоу». 16+
23.20 «ДОМИК В СЕРДЦЕ». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА
5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
6.00 «Кырыс җилле дала геле». Гөлсем Исәнгулова турында телеочерк. 16+
7.00, 15.00 «Сиңа Миннән Сәлам». 16+
9.00 «Җилдергән җитез җилләрдә». Илдар Хәйруллин турында телеочерк. 16+
10.00 «Кайнар хит». 16+
11.00, 18.15 «Башваткыч». 12+
12.05, 19.05 «Җырлыйк әле!» 12+
13.00 «Туган авылым». 12+
13.20 «Кайда сез, яшьлек еллары». Зөһрә Шәрифуллина концерты. 16+
17.15 «Казаннан казанга». 16+
17.45 «Халкым минем». 12+
20.00 «Адымнар». 16+
20.30 «Гомерләрне үлмәс җыр итәек». Хәния Фәрхи концерты. 16+
22.25 Спектакль «Балакаем». 16+

«ЭФИР»
5.00, 14.35 «Ученые люди». 12+
5.30 «Великие полководцы». 16+
6.00 «Легенды кино». 16+
6.30 «Наукограды». 12+
7.00 «Супер МЯУ».
7.30 «Фиксики».
8.00 «Тайные механизмы природы». 12+
8.30 «География вкуса». 12+
8.45 «КРЫЛЬЯ». 12+
12.00, 20.00 «Fam TV». 16+
12.30, 20.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00 «45 СЕКУНД». 12+
15.00 «Удиви меня». 12+
15.45 «ГРАЖДАНКА КАТЕРИНА». 12+
19.00 «Город». 16+
21.00 «МОЙ ДРУГ МИСТЕР ПЕРСИВАЛЬ». 6+
22.40 «ДОВОЛЬНО СЛОВ». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»
6.00 «Доброе утро. Суббота».
9.00 «Умницы и умники». 12+
9.45 «Слово пастыря».
10.00, 12.00, 18.00 Новости.
10.15 «Все звезды русского космоса». 12+
11.15 «До небес и выше». 12+
12.15 «ВЫСОТА».
14.00 «ВЕРНЫЕ ДРУЗЬЯ».
16.00 «ЖЕНЩИНЫ».
18.20 «Кто хочет стать миллионером?»
19.20, 21.35 «Сегодня вечером». 16+
21.00 «Время».
22.30 «Эннио. Маэстро». 12+

«РОССИЯ»
5.00 «Утро России. Суббота».
8.00 Вести. Местное время.
8.20 Местное время. Суббота.
8.35 «По секрету всему свету».
9.00 «Формула еды». 12+
9.25 «Пятеро на одного».
10.10 «Сто к одному».
11.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.40 «Доктор Мясников». 12+
12.45 «ЛИКВИДАЦИЯ». 16+
18.00 «Привет, Андрей!» 12+
21.00 «НЕВИДИМАЯ НИТЬ». 12+

«КУЛЬТУРА»
6.30 «Пешком...»
7.05 Мультфильмы.
8.05 «ИСПЫТАНИЕ ВЕРНОСТИ».
10.00, 19.30 Новости культуры.
10.15 Исторические курорты России. «Сочи. Русская Ривьера».
10.40 «ДЕВУШКА БЕЗ АДРЕСА».
12.10 «Эрмитаж».
12.35 «Козероги - акробаты скалистых гор».
13.30 Письма из провинции.
13.55 «Вся Россия». Фестиваль фольклорного искусства.
14.40 «Рассказы из русской истории». Владимир Мединский.
15.30 «Русский Медичи. Савва Мамонтов».
16.25 «Тайна двух океанов». Иду на погружение!»
17.00 «ТАЙНА ДВУХ ОКЕАНОВ».
19.45 65 лет Сергею Урсуляку. Линия жизни.
20.45 «Песня не прощается... 1971-1972».
21.35 «СТАРИКИ-РАЗБОЙНИКИ».
23.00 Гала-концерт звёзд «Под сказочным небом «Геликона».

«НТВ»
5.00 «Жди меня». 12+
5.45 «БЕРЕГОВАЯ ОХРАНА». 16+
7.25 «Смотр».
8.00, 10.00, 16.00 «Сегодня».
8.20 «Поедем, поедим!» 16+
9.20 «Едим дома».
10.20 «Главная дорога». 16+
11.00 «Живая еда». 12+
12.00 «Квартирный вопрос».
13.00 «Модный vs Народный». 12+
14.20 «Своя игра».
15.20 «Игры разумов».
16.20 «ЧП. Расследование». 16+
17.00 «Следствие вели...» 16+
19.00 «Центральное телевидение».
20.20 «Ты не поверишь!» 16+
21.25 «Секрет на миллион». 16+
23.25 «Международная пилорама». 18+

Якшәмбе

11 июнь
«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»
5.35 «Оныта алмыйм...» 12+
6.00 «Гомер - татлы мизгел». Рәяз Фасихов концерты. 12+
8.00, 13.00 «Адымнар». 16+
8.30 «Полосатая зебра».
8.45 «Әти һәм мин».
9.15 «Тамчы- шоу».
9.45 «Яшьләр тукталышы».
10.15 «Ачыктан ачык». 16+
11.00 «Туган авылым». 12+
11.30 «Тархан». 12+
12.00 «Каравай». 6+
12.30 «Закон. Парламент. Общество». 16+
13.30 «Погружение на 100». 12+
13.40 «Риваять» төрки-татар этникасы ансамбле концерты. 12+
15.00 «Әниемнең җылы кочагы». 16+
16.00, 0.50 «Ком сәгате». 16+
17.00 «Видеоспорт». 16+
17.30 «Соотечественники». 16+
18.00 «Башваткыч». 12+
19.00, 22.00 «Семь дней». 16+
20.00 «Заман көзгесе». 6+
20.30 «Болгар радиосы» концерты. 12+
21.00 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
23.00 «НОВАЯ ЖИЗНЬ АМАНДЫ». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА
5.05, 12.35 «Халкым минем». 12+
5.30 «Нәсыйхәт». 16+
6.00 «Заман көзгесе». 6+
6.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 16+
7.00 «Адымнар». 16+
7.30 «Түгәрәк бәхет». Айдар Тимербаевның иҗат кичәсе. 16+
9.00 «Йөрәктән - йөрәккә». 16+
10.00 «Әдәби хәзинә». 6+
10.30 «Калеб». 6+
11.10 «Тамчы-шоу». 6+
11.40 «Бергәләп өйрәник». 6+
12.05, 0.45 «Яшьләр тукталышы». 6+
13.00 «Туган авылым». 12+
13.20 «Гаилә учагы». 16+
13.50 «Саф күңелле каласы иде...» Вил Усманов концерты. 16+
15.45 «Йөрәктән-йөрәккә». Харис Нигъмәтҗанов турында телеочерк. 16+
16.20 «Кәмит Җәвит». 16+
17.15 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
18.10 «Әниемнең җылы кочагы». 16+
19.05 «Ком сәгате». 16+
20.00 «Семь дней». 16+
21.00 «Күңел эретерлек сүзләр бар». Гөлүсә Шаһбанның иҗат кичәсе. 16+
23.00 «КӨТЕГЕЗ, БЕЗ КИЛӘБЕЗ». 16+

«ЭФИР»
5.00 «Ученые люди». 12+
5.30 «Великие полководцы». 16+
6.00 «Легенды кино». 16+
6.30 «Наукограды». 12+
7.00 «Супер МЯУ».
7.30 «Фиксики».
8.00 «Тайные механизмы природы». 12+
8.30 «География вкуса». 12+
8.45 «ГРАЖДАНКА КАТЕРИНА». 12+
12.00, 20.00 «Fam TV». 16+
12.30, 20.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00 «МУЖ СЧАСТЛИВОЙ ЖЕНЩИНЫ». 12+
14.30 «Пять причин поехать...» 12+
14.45 «Блин. Ком». 16+
15.45 «КРЫЛЬЯ». 12+
19.00 «Город». 16+
21.00 «РЫЖИЙ ПЕС». 16+
22.30 «ИТАЛЬЯНСКИЕ КАНИКУЛЫ». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»
6.00, 10.00, 12.00, 18.00 Новости.
6.10 Подкаст.лаб «Антропология». 16+
6.55 «Играй, гармонь любимая!» 12+
7.40 «Часовой». 12+
8.10 «Здоровье». 16+
9.20 «Мечталлион». 12+
9.40 «Непутевые заметки». 12+
10.15 «Жизнь своих». 12+
11.10 «Повара на колесах». 12+
12.15 «Правительство США против Рудольфа Абеля». 12+
14.20 «МЕРТВЫЙ СЕЗОН». 12+
17.00. «Специальный репортаж». 16+
18.30 «Эхх, Разгуляй!» 16+
21.00 «Время».
21.30 «ОДИННАДЦАТЬ МОЛЧАЛИВЫХ МУЖЧИН». 12+
23.45 «Ловцы солнца». 12+

«РОССИЯ»
5.55 «ПРОДАЁТСЯ КОШКА». 12+
8.00 Местное время. Воскресенье.
8.35 «Когда все дома с Тимуром Кизяковым».
9.25 «Утренняя почта с Николаем Басковым».
10.10 «Сто к одному».
11.00, 17.00 Вести.
11.40 «Большие перемены».
12.45 «ЛИКВИДАЦИЯ». 16+
18.00 «Песни от всей души». 12+
20.00 Вести недели.
22.00 Москва. Кремль. Путин.
22.40 «Воскресный вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»
6.30 Мультфильмы.
7.40 «ТАЙНА ДВУХ ОКЕАНОВ».
10.10 Исторические курорты России. «Железноводск. Воды железные, они же целебные».
10.35 «СТАРИКИ-РАЗБОЙНИКИ».
12.05 Невский ковчег. Теория невозможного. Михаил Хилков.
12.35 «Почему светится клюв?»
13.15, 17.10 «Первые в мире».
13.30 Письма из провинции.
13.55 «Вся Россия». Фестиваль фольклорного искусства.
14.40 «ИСПЫТАНИЕ ВЕРНОСТИ».
16.30 «Картина мира с Михаилом Ковальчуком».
17.25 «Пешком...»
17.55 Парад победителей телевизионного конкурса юных музыкантов «Щелкунчик».
19.30 Новости культуры.
19.45 «Застава Ильича». Исправленному не верить».
20.25 «ЗАСТАВА ИЛЬИЧА».
23.40 «Русский Медичи. Савва Мамонтов».

«НТВ»
4.50 «БЕРЕГОВАЯ ОХРАНА». 16+
6.35 «Центральное телевидение». 16+
8.00, 10.00, 16.00 «Сегодня».
8.20 «У нас выигрывают!» 12+
10.20 «Первая передача». 16+
11.00 «Чудо техники». 12+
11.55 «Дачный ответ».
13.00 «НашПотребНадзор». 16+
14.05 «Однажды...» 16+
15.00 «Своя игра».
16.20 «Человек в праве с Андреем Куницыным». 16+
17.00 «Следствие вели...» 16+
18.00 «Новые русские сенсации». 16+
19.00 Итоги недели.
20.20 «Ты супер! 60+». 6+
23.00 «Звезды сошлись». 16+

Сабантуйларда туган тел югала

Әстерхан өлкәсенең Җәмәле (Три протока) авылында XIII Бөтенроссия авыл Сабан туе артистлар, сәнгать коллективлары, әдипләр, рәссамнар, җырле ансамбльләр, үзешчән сәнгать осталары катнашында узды.

Татарстан Рәисе Р.Миңнеханов Сабан туе бәйрәменең мәдәниятне, милли үзенчәлегебезне күрсәтү мәйданы булуы турында искәрткән иде. Җәмәле авылында узган Сабан туе да бик матур сәнгати чыгышлар белән башланды һәм гүзәл тамаша булып хәтердә калды. Анда кызларның кышкы кичләрдә Сабан туе батырына бүләккә биреләчәк сөлге, кулъяулык чигүләре дә, язгы сабанга чыгуы да, карга боткасы белән сыйлану, бүләк җыю күренешләре дә җыр-биюләр, артистлар чыгышы аша бөтен тулылыгы белән күрсәтелде.

Әстерханлыларны һәм кунакларны Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов, Әстерхан өлкәсе губернаторы Игорь Бабушкин, мәртәбәле кунак – Пермь крае губернаторы Дмитрий Махонин сәламләде. Мәйданга җыелган халыкның исә иге-чиге юк. Ул, бәлки, иң күп халык катнашында узган Бөтенроссия авыл Сабан туе булып хәтерләрдә калыр.

Бәйгеләр барлык мәйданчыкларда берьюлы башланды, берничә сәхнәдә концерт барды, һөнәрчеләр шәһәрчеге дә бай һәм төрле иде. Кукмаралар корган татар авылы һәркемне сокландырды. Төп мәйданда 100 гә якын көрәшче бил алышты. Аларның унысы – Татарстаннан, дагстанлылар да хәтсез. Сабан туеның баш батыры булып Теләче районы үстергән Раил Нургалиев калу сөендерде. Аңа симез тәкә һәм «Лада-Гранта» автомобиле бүләк иттеләр.

Әстерхан өлкәсе авылларында Сабан туе ел саен үткәрелә. Бәйрәмнең үзенчәлекләре дә бар. Шома колгага читек алырга менү, велосипедта биек баганаларга тарттырылган баудан узу, дөяләр ярышы һ.б. Соңгысы калкулыкның икенче ягындагы ипподромда үтте. Бередә шулай ук Әстерхан сәнгать коллективлары концерты барды. Ипподромга бару юлында бу як хайваннары һәм авыл хуҗалыгы машиналарыннан күргәзмә дә эшләде.

Әстерхан өлкәсе Авыл хуҗалыгы һәм балык сәнәгате министрлыгының бүлек башлыгы Алексей Шишкин төбәк биләмәләрендә өч меңгә якын дөя асралуы, ә узышта катнашу өчен, Калмыкия республикасыннан да килүләрен искәртте. Дөяләр һәм атлар чабышка әзерләнгән арада, ипподромда ат өстендә оста йөрү буенча күрсәтмә чыгышлар үтте. Егет-кызлар ат өстендә аякларын өскә күтәреп тә, башларын аска салындырып та, 400 метр араны, кылыч белән багана башына куелган сулы шешәләрне кисеп, арбалеттан атып, ике ат өстенә берьюлы басып та чаптырып узды. Чабышларда 22 дөя, 10 ат катнашты. Дөяләр узышында Калмыкиядән Дамир Дюсенбаев җиңүче булды. Аның Лада исемле дөясе 2 чакрым араны 4 минут 5 секунд эчендә үтте. Иң җитез дөя хуҗасы 200 мең сум акча белән бүләкләнде.

Атлар тынгысызланды, бернечәсе ярыш юлыннан да чыкты. Борис Ванджаев иярләгән ат иң җитезе – ул 2400 метр араны 2.54 минутта үтте. Ат хуҗасына губернатор И.Бабушкин «Лада Гранта» автомобиле бүләк итте.

Бөтенроссия Сабан туе турында фикерләр дә сораштык. Татарстанның халык артисткасы Гөлзада Сафиуллинаның мондый Сабантуйда икенче тапкыр катнашуы. Владивостокта узганында аңа алданрак барып, Артем, Находка, Владивосток, Уссурийск шәһәрләрендә фольклор ансамбльләрен оештырырга туры килгән. Анда 5 яшьлек балалардан алып 80 яшькәчә әбиләргә кадәр катнашкан. Ул чакта бәйрәм стадионда узган. Әстерханда җырчыны күргәзмәләрнең, һөнәрчеләрнең, ризыкның төрлелеге хәйран калдырган. «Кукмаралылар төзегән авылның мәчете дә, капкалары, тәрәзә йөзлекләре, милли бизәкле өйләр, тәмле коймаклар пешерелә торган миче дә гаҗәеп. Җыелган халык югары профессиональ сәнгатьне дә күрә. Татарстаннан 10 сарык салып пешерерлек казан алып килгәннәр. Шунда аш, пылау пешереп, бик күп халыкны туендырдылар», – ди ул.

● Сабан туеның баш батыры Раил Нургалиев.

● Кукмара районы Өлге авылыннан Миләүшә Сәләхованың кул эшләре.

Татарстанның халык рәссамы, педагог **Мөдәрис Миңһаҗев** сөйли:

– Мондагы татарларыбызга ярдәм кирәк иде. Бу Сабан туе алар күңелендә үз милләтләре белән горурлык хисләре тудыра. Бай эчтәлекле, югары сәнгати корылган милли бәйрәмебез булды ул. Аннары күп кенә гореф-гадәтләребез искә төшерелде. Рәссамнәр үзләренең затлы иҗатын күрсәтте. Халыкның картиналарыбызга сокланып каравын күрдек. Кукмараларның җитештергән итекләре, чигүле башмаклары, курткалары, таба-казаннары, чигеп бизәлгән сөлгеләре теләсә кем кызыгырлык.

Язучы, филология фәннәре кандидаты **Рәфкать Шаһиев**:

– Җирле халыкның кунакларга мөнәсәбәте уңай булды. Безнең Татарстаннан килүебезне белүгә, йөзләр тагын да яктыра, юллар ачылып китә торды. Кичә бер казах таксисты, вакытын калдырып, акча да алмыйча, безгә шәһәрне күрсәтеп йөрде... Әмма бәйрәмдә татарлыгыбыз азрак чагылган, телебез азрак яңгыраган Сабан туена ак яулыклы әбиләребез җитмәгән кебек тоелды. Бәйрәм күбесенчә рус телендә барды. «Праздник плуга» түгел бит, Сабан туе! Аннары Татарстан делегациясе составындагы кешеләрнең каян булуы киемнәрдәме, бейджиклардамы чагылдырылырга тиеш иде кебек.

Шагыйрь **Рифат Сәлах**:

– Казаныбызга 1500 чакрым ераклыктагы төбәктә безнеке кебек үк тормыш бара. Аларның туган телләрен онытып барулары, әлбәттә, бик кызганыч. Бу хәл Россиянең барлык төбәкләрендә яшәүче татарларга, хәтта казанлыларга да хас. Безгә, аралар ерак булса да, күрешеп, борчыган мәсьәләләрне уртага салып сөйләшеп, киңәшеп торырга кирәктер.

Сабан туе үзебезнең милләтебезнең эшчән, булдыклы икәнен күрсәтү, татарларның монда яшәгән башка халыклар каршында дәрәҗәсен күтәрү дә булды. Губернатор да татарларның шундый югары сәнгати дәрәҗәдә бәйрәмнәр үткәрә алуын, шул ук вакытта бер-беребезгә терәк булуыбызны күрде. Аннары бу – милли мәдәниятебезне күрсәтү дә. Уйланып бетмәгән яклары да булды. Татарстаннан Газинур Морат, Фирүзә Җамалетдинова, Рәфкать Шаһиев, Амур Фәләхов кебек язучы-шагыйрьләр килгән икән, аларга сүз бирергә кирәк иде. Мондагы халык өчен татар әдәби сүзе яңгыраса, тагын да күркәмрәк булыр иде. Россиянең төрле төбәкләренә барганыбыз бар. Әйтик, Екатеринбург өлкәсенә килгәч, язучыларны төрле авылларга тараттылар, шунда берьюлы дистәләгән авылда очрашулар үткәреп кайттык. Ул кичәләрдә катнашкан балалар инде үсеп буй җиткерде, әмма алар күңелендә шул көндәге татарлык белән горурлану хисе калды, аларның кайберләре белән хәзер дә аралашабыз. Бәйрәмдә, телебезне арткы планга калдырып, игътибарны үзебезне күрсәтүгә генә юнәлтү дөрес түгел. Әйтик, язучы да күбрәк премия алуга гына омтылып, иҗатның үзенә игътибар итми башлый икән, бу – зур югалту. Монда да күңелебездә миллилек, татар сүзен ишетәсе килү ташып торырга тиеш. Милли үзаң тәрбияләү хәзер арткы планга күчеп бара, халкыбыз күбрәк тышкы кыяфәткә, ялтыравыкларга, хәтта байлыкка корылган нииндидер бер тормышка кызыгып, шушы юнәлешкә тартыла кебек. Әчке рух, милли үзаң, әби-бабаңнар юлын дәвам итү хисләре югала баруы бик кызганыч.

Сөембикә КАШАПОВА.
Автор фотолары.

Мәдәни җомга

Тойгилденең күн остасы

Шәһәрдә яшәүчеләргә һөнәр өйрәнү әллә ни кыен түгел. Осталарның исемнәре билгеле. Үзеңә кирәген эзләп тап та, сораштыр. Китапханәдә кул эшләренә өйрәткән китаплар бар. Әледән-әле милли һөнәрчеләрнең кул эшләреннән күргәзмәләр оештырылып тора. Авылда гомер итеп тә, күңелеңдә иҗат уты дөрләсә нишләргә?

Җаны теләгән – елан ите ашаган, диелә халык мәкалендә. Оста куллы Нурия Флүр кызы Бәхтегәрәева белән танышкач, шушы сүзләрнең дөреслегенә тагын бер кат инандык. Мөслим районы Югары Табын авылында туып үскән Нурия ханым, Алабугада мәдәни-агарту училищесының китапханәчеләр бүлеген тәмамлаганнан бирле, Тойгилде авылында китапханәче булып эшли. Сабыр, тыйнак, затлы бу ханымда китапларда сырланган аксакаллар акылы барлыгын сөйләшә башлагач ук сизеп аласың. Кеше үз һөнәрен табу бәхетенә ирешә икән, аның эше дә җырлап бара, нәтиҗәләр дә югары була. Нурия ханымның күңеленә якын һөнәрне табуын Татарстан Мәдәният министрлыгы һәм Милли китапханә дипломнары, мактау кәгазьләреннән үк чамаларга була. Н.Бәхтегәрәева яратып эшләмәсә, Тойгилде авылы китапханәсе «Һәр авылга – үрнәк мәдәният учагы» республика бәйгесендә өч ел рәттән икенче урын яуламас иде.

Нурия ханым бәйләү, чигү белән дә чын-чынлап мавыга. Үзе мавыгып кына калмый, байтак еллар бу һөнәргә мәктәп яшендәге кызларны да өйрәткән. Үзенең милли бизәкләр белән чиккән намазлык, сөлгеләре күз явын алырлык матур.

Ә бервакыт китапханәдә сәнгать белгече Лилия Саттарованың «Казанская узорная кожа» китабын актарып утырганда борынгыдан килгән күн сәнгатен өйрәнү уе килә. Бирәм дигән колына, чыгарып куяр юлына, диләрме әле? Китапханәче үзенә кирәкле мәгълүматны каян белә? Газета-журналдан, әлбәттә. Шулай бервакыт «Ватаным Татарстан» газетасында Казанда Илдар Шәйхетдиновның читекләр чигүе һәм һәр теләүчене бу һөнәргә өйрәтергә әзер булуы турында мәкалә укый. Эшне озакка сузмыйча, Нурия ханым Казанга бер баруында читекләр остасы белән

күрешә һәм шуннан Апанай мәчетенә осталык дәресләренә йөри башлый. Мөслимнән!.. Н.Бәхтегәрәеваның һөнәр өйрәнү теләгенең никадәр көчле булуын шуннан гына да чамаларга була. Юл йөргәндә әллә нинди кызык хәлләр чыгып куя. Шулай бервакыт Казанга килеп кенә җитә, телефоннан Нурия ханымның ире Газинур абый шалтыратып, сыер бозаулады, кайт, ди икән. Осталык дәресен онытып торып, кире хуҗалыкка кайтып китәргә туры килә...

Чын күңелдән нидер теләсәң, галәм үзе хыялны тормышка ашырырга ярдәм итә диләрме әле? Нурия ханым айлар-еллар Мөслим-Казан юлын таптагач, читекче Илдар Шәйхетдинов элек яшәгән Алабуга шәһәренә кайта. Ни дисәң дә, Алабуга Мөслимгә якынрак. Ара якынайган саен, белем-күнекмә дә ныгый бара. Шулай итеп, Нурия ханым авылда яшәп тә бик матавыклы, әмма гаҗәеп матур, бүтән бер халыкта да булмаган каюлы күн сәнгатен өйрәнә. Бүген аның осталыгы турында авылдашлары гына түгел, бөтен район белә. Мәдәният министрлыгы Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнехановның ярдәмендә үткәргән «Татарстанның мәдәни башкаласы» бәйгесенә, үз осталыгын күрсәтү өчен Казанга мөслимлеләр килгәч, районның иң оста пешекчеләр, һөнәр ияләре арасында Нурия Бәхтегәрәева да бар иде. Аның белән танышуыбыз да шунда булды.

Нурия Флүр кызының кул эшләре арасында ниләр генә юк. Чигүле кәвешләре бик уңайлыга ошаган. Авыл халкы тикмәгә генә ябырылып алмый торгандыр. Авылдагы әби-бабай өчен күзлек савытлары да бик кирәкле нәрсә. Остакулның үзенә артлары каюлы күн ысулы белән бизәлгән урындык иң кадерлесе дигән тәэсир калды. Урындык бизәкләрен сыйпап-назлап сөйләгәндә карашыннан якты сагыш сизелә иде. Бу урындыклар икәү икән. Н.Бәхтегәрәева аларны ике оныгына бүләк итеп эшләгән. «Минем төсем итеп сакларлар», – диде...

Миләүшә ГАЛИУЛЛИНА.

ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ – «ТАТМЕДИА» АКЦИОНЕРЛЫК ҖӘМГЫЯТЕ

«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы директоры – баш мөхәррир

Вахит Шәих улы ИМАМОВ

Җаваплы сәркатип Илгизәр ЗӘКИЕВ

Шылтыратыгыз:

222-09-83 (1562) – кабул итү бүлмәсе;

222-05-47 (1560) – җаваплы сәркатип, компьютер үзәге;

222-05-47 (1561) – иҗтимагый-сәяси тормыш, мәгариф һәм фән, сәнгать бүлекләре; хатлар һәм социаль көнкүреш, тәрҗемә бүлекләре;

222-09-84 (1266) – бухгалтерия.

Реклама хезмәте телефоны: (843)222-05-47 (1560)

Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләр өлкәсенә күзәтчелек итү федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2019 елның 9 октябрендә ПИ №ФС 77–76961 нче санлы теркәү таныклыгы алды

Индекс П2355

Авторлар фикере редакция фикере белән аваздаш булмаска да мөмкин

Редакциянең рәсми оешмаларда юллаучы булып йөрү мөмкинлеге юк

Хатлар, кулъязмалар, фотографияләр, рәсемнәргә бәяләмә бирелми һәм алар кире кайтарылмый

© Газетада чыккан материалларны күчереп бастырганда редакциядән язмача рөхсәт алу мәҗбүри

Реклама һәм белдерүләрнең төгәллеге өчен реклама бирүчеләр үзләре җаваплы

Безгә иганәлек ярдәме күрсәтергә теләүчеләр өчен редакциянең исәп-хисап счеты:

ИНН 1655144950 КПП 165802012
ПАО «АК БАРС» банк,
г. Казань
р/с 40702810600020010312
к/с 30101810000000000805
БИК 049205805 ОГРН 1021600000124

НӘШЕР ИТҮЧЕ – «ТАТМЕДИА» АҖ

420097, Казан, Академия урамы, 2

Редакция, гамәлгә куючы һәм басмаханәнең адресы:
420066, Казан, Декабристлар урамы, 2
E-mail: m-jomga@mail.ru

«Мәдәни җомга» газетасы Интернетта: www.madanizhomga.ru

Басмаханә гаебе белән җибәрелгән сыйфат җитешсезлекләре хакында 562-10-61 номерлы телефон буенча шылтыратырга

Газета һәр атнаның җомга көнендә чыга. Бу санның чыгу көне 02.06.2023

График буенча бу санга 15 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 14 сәгать 30 минутта.

«Татмедиа» АҖ филиалы – «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды

Газетаның сатудагы бәясе ирекле

Тираж – 2600 данә

Заказ 2620

16+